Слово "чай" имеет большое значение и историю как в Китае. Сравнивая значения слова "чай" в китайском и русском языках, можно выявить некоторые различия. В русском языке чай символизирует радушие, гостеприимство и тепло. В китайских пословицах чай в основном используется для выражения времени посадки чайных листьев, управления чайными деревьями и употребления чая для здоровья. Например, русские пословицы: Выпей чайку – забудешь тоску. (Выражает мысль о том, что, когда дела идут не очень хорошо, не стоит терять самообладание и торопить события. Нужно сесть с чашкой чая и успокоиться, чтобы вынести рациональное решение.)； Распивать чаи (пить чай не спеша, как способ скоротать время или просто как дополнение к разговору. Оно также может использоваться в негативном смысле для описания человека, который более ленив)；и тосты с чаем – не думайте, что я их прогоняю! (Произносится принимающей семьей, когда они подают чай своим гостям, существует этикет, который не нужно говорить, но его понимают. (Конец чаепития – конец вечеринки). В русских пословицах и культуре "чай" используется как символ счастья, отдыха, спокойствия и расслабления, а также гостеприимства. В России чай стал важной частью вечеринок и банкетов.

Существует ряд китайских пословиц о чае, связанных с его посадкой и выращиванием. Эти пословицы представляют собой описание посадки и сроков выращивания чая. До сих пор существует множество правил выращивания чая, которые продолжают использоваться, а также множество пословиц, связанных с использованием чая в качестве лекарства. Например: 茶叶是时辰草，早采三天是宝，迟采三天是草。(Чайный лист подобен утренней траве; соберите его в первые три дня, и он станет сокровищем, но если вы соберете его на три дня позже, он станет сорняком.)；采摘多留叶，来年多增产。（При сборе чайных листьев необходимо оставить как можно больше неповрежденных листьев, чтобы урожай чая в следующем году был больше.）；茶为万病之药。(Большинство болезней можно предотвратить с помощью чая. Это также свидетельствует о том, что в Китае чай может использоваться в качестве лекарства.)；土厚栽桑，土酸种茶。(Выращивание чайного дерева требует знания почвы и лучшего роста в правильной почве.)

Русские и китайские пословицы о чае дают представление о разнице в направленности смыслов, представленных в китайских и

русских пословицах о чае. В русском языке большинство из них связано с развлечениями и увлечениями. В китайских пословицах большинство из них связано со временем посадки, почвой и здоровьем. Таким образом, можно сказать, что пословицы – это самый быстрый и точный способ узнать о культуре и обычаях. Понятия культурных и языковых явлений занимают важное место в поисках специфики национальных языков. Эти «представляют собой знание повседневного языка».

**Литература**

1. Смирнов С.В. Китай: история и современность = China: history and contemporary: материалы X международной научно-практической конференции Екатеринбург, 3-5 октября 2016 г. / отв. ред. С.В. Смирнов. – Екатеринбург: Изд-во Уральского ун-та, 2017. – 288 с.

2. Щичко В.Ф. Китайский язык. Теория и практика перевода. – 4-е изд. – М.: ВКН, 2020. – 226 с.

3. Лихачёв Д.С. Концептосфера русского языка // Сер. лит. и яз. – 2022. – Т. 52. – № 1. – С. 3–9.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ДИАЛОГИК СӨЙЛӘМНЕ ҮСТЕРҮ

*Васикова А., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәгъдиева Р.К.*

Сөйләм – кеше эшчәнлегенең бер төре, һәм ул тел нормаларын үзләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Татар телен чит тел буларак укытуның төп бурычы – татар телен аралашу чарасы буларак кулланырга өйрәтү. Дәрес барышында укучылар татар телендә сөйләмне дөрес кабул итәргә (аудирование), сөйләшүдә (диалогик сөйләмдә) катнашырга, күргәннәре һәм ишеткәннәре турында сөйләргә (монологик сөйләм), татар текстларын укырга һәм аңларга, шулай ук татар телендә грамоталы язу күнекмәләрен үзләштерергә өйрәнергә тиеш.

Диалог – ике яки аннан да күбрәк катнашучылар арасында булган сөйләм формасы. Минемчә, аралашканда диалогик сөйләм күбрәк кыенлыклар тудыра. Диалог алып бару осталыгы уңышлы аралашуның мөһим өлеше булып тора. Шуңа күрә татар телен укытканда өстенлекне шушы сөйләм төренә бирергә кирәк.

Диалогик сөйләм диалогта катнашучыларның икесенә дә бәйле, шуңа күрә аны планлаштыру авыррак. Диалогик сөйләмдә сөйләшү тиз бара, һәм бу тел материалын белүне, сүзлек запасының күп булуын таләп итә. Диалогта төрле тулы булмаган җөмләләр һәм сүзләрне ирекле кулланырга мөмкин.

Диалогка өйрәтү беренче дәресләрдән үк үткәрелә. Диалогка түбәндәге үзенчәлекләр хас:

- диалогта катнашучылар өчен бер кызыклы теманың булуы,
- ике һәм аннан да күбрәк әңгәмәдәш булу;
- материалны ирекле сөйләү мөмкинлеге;
- капма-каршы элемтә булу һ.б.

Диалогик сөйләмне өйрәнүдә билгеле бер эзлеклелек булу бик мөһим. Диалог өстендә эшнең түбәндәге төп этапларын билгеләргә мөмкин: диалогик үрнәкне тыңлау һәм аңлау, диалогик үрнәкне төрле дәрәҗәләрдә кабатлау: истә калдыру юлы белән, ситуация эчендә үзгәрешләр белән һ. б. Татар телендә диалогик сөйләмне тыңларга һәм аңларга, диалог репликаларын дөрес сөйләргә, үрнәккә охшаш диалог төзергә, диалогны үзеңә төзергә мөмкин.

Укучыларга диалогик сөйләм күнекмәләрен яхшыртырга ярдәм итәр өчен төрле ысуллар һәм алымнар бар.

Уен алымы

Уен – татар телендә диалогик сөйләмне өйрәтүнең иң нәтиҗәле ысулларының берсе. Укучылар рольле уеннар уйный алалар, анда алар

төрле персонажлар ролен үз өсләренә алалар һәм төрле ситуацияләр турында фикер алышалар. Мәсәлән, «кунаклар очрашуы» уенын үткәрергә мөмкин, анда укучылар кунакларны сәламләргә, аларга сораулар бирергә һәм аларның сорауларына җавап бирергә тиеш.

Аудио һәм видео материаллар белән эшләү

Аудио һәм видео материалларны куллану диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен дә файдалы булырга мөмкин. Укучылар сөйләмне ишетү һәм диалогта катнашу өчен татар телендә мульфильмнар яки кинолардан өзекләр карый ала. Шулай ук видео дәресләр кулланырга мөмкин, анда укучылар татар телендә диалоглар тыңлый һәм алар турында фикер алыша ала. Материаллар укучыларга өйрәнелә торган телнең мәдәнияте һәм традицияләре белән танышырга ярдәм итә.

Төркемнәрдә эш

Тагын бер мөһим алым – төркем белән эш. Төркем эшендә укучылар бер-берсен тыңларга, һәр катнашучының фикерен исәпкә алырга, үз позицияләрен дәлилләргә һәм компромисска килергә өйрәнәләр. Төркем биремнәре билгеле бер теманы тикшерүгә, проблеманы чишүгә, мәгълүмат эзләүгә һ. б. юнәлдерелә ала.

Шулай ук диалогик сөйләмгә өйрәтүдә түбәндәге биремнәрне кулланырга мөмкин:

1. Репликаны дәвам итегез, җавапны языгыз;
2. Үрнәк буенча яңа ситуацияле диалог төзегез;
3. Терәк сүзләрне кулланып диалог төзегез;
4. Кирәкле репликалар өстәп диалогны укыгыз;
5. Диалогик сөйләмне монологик сөйләмгә үзгәртегез;
6. Диалогны рус теленә тәрҗемә итегез;
7. Диалогтагы фигыльләрнең заманын үзгәртеп языгыз һ. б.

Әлеге төр күнегүләр укучыларга башка укучылар һәм укытучылар белән аралашу күнекмәләрен үстерергә ярдәм итәләр, укучыларны лексика белән таныштыралар, ярдәм итәләр.

Шулай итеп, татар теле дәресләрендә диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү уен технологияләре, аудио һәм видео материал белән эшләү, төркемнәрдә эш һәм башкалар кебек төрле алымнар кулланырга мөмкин. Шуны истә тотарга кирәк: диалогик сөйләмнең уңышлы үсеше өчен дәрестә уңай атмосфера тудырырга, укучыларның активлыгын үстерергә һәм аларны татар телендә аралашырга этәрергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы.– Казан: Раннур, 2000. – 167 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Хәтер, 2001. – 432 б.

3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 302.

# ТЕЛ ЯЗМЫШЫ – МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

*Вахитова Л.Р, Чувашия Республикасы, Батыр муниципаль округы, беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәбе, X сыйныф*
*Фән. җит. – татар теле һәм әдәбият укытучысы Мтеева З.Ш.*

Татарлар борынгы заманнан ук тарихка билгеле халык. XIX йөз татар галиме Ризаэддин Фәхретдин “Болгар вә Казан төркиләре” дигән хезмәтендә “без татарлар, төрки милләтеннән, бик борынгы һәм шөһрәтле, дөньядагы авырлыкларга түземле һәм чыдамлы, төпле һәм нык торучан бер халык,”- дип язган.

Әйе, туган халкымның узган тарихы фаҗигале вакыйгаларга бай. Шуларның иң афәтлесе, әлбәттә, Казан ханлыгының Явыз Иван тарафыннан яулап алынуы һәм Рус дәүләте составына кертелүе булган.

Халкым күпме изелсә дә үзенең ана телен саклап калды. ә милләтнең саклануы турыдан- туры телгә бәйле.

Мин үзем Татарстан белән читтәш булган Чуашия җирлегендә яшим. Чуаш Республикасы 18 мең 300 кв. км. җир били. ә татарлар саны 3% чамасы. Башкалабыз Чебоксар шәһәреннән алып төрле авыл һәм районнарда безнең милләттәшләребез яши. Ә үзебезнең Батыр районнында саф татар авыллары җидәү: Шыгырдан, Кыр Бикшеге, Озын Куак, Кзыл – Камыш, Татар Согыты, Кызыл Чишмә һәм Татар Тимәше.

Бу авылларда милләтебезнең матур гореф – гадәтләре, телебез сакланып калган. Ләкин шулай да милләт язмышы хакында уйланулар бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Татар милләтенең киләчәге бармы? Ул өметлеме? Чуваш җирлегендә адашып калган милләттәшләребез үз ана телләрен югалтмасылармы? Чуваш халыклары белән беррәттән татар халкы лаеклы урын алырмы? Менә шушы мәсьәләләр бүгенге аек акыллы яшь буынны, шул исәптән мине дә, борчый.

Бүгенге көндә телне саклау проблемалары үзенә зур игътибар таләп итә. Кайсыбер ата-аналар нәрсәгә соң ул татар телен белергә, яшьтән үк чит телне өйрәнә башларга кирәк, дип уйлыйлар. Мин бу фикер белән килешмим. Чөнки бала ана телендә аң, белем һәм тәрбия ала, шул телдә төпле генә иттереп фикер йөртә. “Кешене ана теленнән аеру, яңа туган баланы ана сөтеннән аерып ясалма сөт белән тукландыруга тин”, - дип фикер йөртә Айдар Халим.

Тагын бер актуаль проблема катнаш гаиләләр булып тора.

Милләт язмышы проблемасы элек-электән язучыларыбыз, шагыйрьләребез, драматургларыбыз иҗатында киң чагылыш тапкан. Мин бүген үземнең чыгышымда Г.Исхакый һәм Зариф Бәшири иҗатларында күтәрелгән актуаль проблемалар турында язып китәсем

килә. Г.Исхакыйның бер гасыр элек үк “Әүвәл әхлак бозыла, икенче – тел бетә, аннан соң халык үзе дә юкка чыга”, дип милләт язмышын кайгыртып әйткән сүзләре бүгенге көндә дә актуаль булып кала. Г.Исхакый милләтебезнең руслашып юкка чыгу ихтималының зур булуын күреп борчыла, сәбәбен катнаш никахларда күрә. Бу проблеманы “Ул әле өйләнмәгән иде” әсәрендә тулы һәм эзлекле яктырта. Повестьның төп герое укымышлы, рус мәдәнияте йогынтысында тәрбияләнгән егет – Шәмси һәм алдынгы фикерле, тәҗрибәле хөр хатын Анна арасындагы мәхәббәт тасвирлана. Шәмсинең сөю хисләре дини- милли традицияләр белән каршылыкка керә. Ир белән хатын уртак тормыш итәләр, уртак балалар үстерәләр, ә үзләре ике ярда торган ике кеше, ике рухият белән яшиләр.

Ә.Еникиның “Әйтелмәгән васыятен”дә дә шул ук тема чагылыш таба. Акъәби башкорт балалары үстерә. Озын тормыш юлы үтеп, зур тәҗрибә туплаган, башкорт халкының акыл – зиһенен үзенә сеңдергән, илгә күп белгечләр үстереп биргән Ана күңел байлыгы, балаларына үзеннән соң калдыра торган мирас турында уйлана. Олы улы Суфиянның марҗага өйләнүен бик авыр кичерә. “Ирләр тән булса, хатын – кыз җандыр” дигән мәкальне искә төшердем. Катнаш никахта аналары марҗа булганлыктан, балалары да урыс була. Исемнәре дә русча, җитмәсә “ана сөте белән салынган” телләре дә русча. Менә Акъәби каршында башкортча “ярты кәлимә” сүз дә әйтә алмаган оныгы Суфиян улы басып тора. Буыннар җебе өзелә.

Мине кызыксындырган, шул ук катнаш никах мәсьәләсен күтәргән тагын бер әсәр Зариф Бәширинең татар һәм чуаш телендә язылган “Чуваш кызы Әнисә” исемле әсәре.

Татар егете Зариф Униссене бер күрүдә үк ошата. Васек дәдәй Униссене татар гаиләсенә асрамага бирә. Тик кыздан чуваш динен саклавын үтенә, татар гаиләсендә яшәгәндә Униссенең исемен Әнисәгә алыштыралар.

Тора-бара Заркай белән Әнисә арасында мәхәббәт җебе сузыла. Ләкин боларга бик динчел, христианчыл булу белән бергә, үзенең чуашлыгын тирән бер фанатизм белән саклый, аны изге бернәрсә иттереп саный торган дәдәсе һәм егетнең мулла этисе киртә булып тора.

Вакытлар уза, Заркай шәһәргә укырга китә. Әнисә дәдәсе өенә күчә. Зариф шәһәрдә яшәсә дә, күңеле белән Әнисәсе янында була. Бер кызга да күз салмый үзе, ләкин Әнисәгә дә минеке бул дия алмый. Әнисә үзенең мәхәббәтенең киләчәге юклыгын белеп, агу эчеп үлә.

Менә шундый тетрәнгеч язмыш. Мондый язмыш мине уйландырды.

Әйткәнемчә, катнаш никах – бүгенге көн кадагына суккан мәсьәлә. Йөзләгән, меңләгән татар егетләре һәм кызлары башка милләт вәкилләрен якын итәләр. Заман таләпләренә буйсынып, алар үз диннәрен, телләрен югалтып, катнаш гаиләләр коралар. Кеше бәхетен мәхәббәттән башка карау мөмкин түгел, ә мәхәббәт чикләрне белми.

Катнаш никахлар бүген гадәти хәлгә әверелде. Мәхәббәт күңелләргә иңгәч, сөйгән кешеңнең нинди диндә булуын уйлап тормыйсың. Иң мөһиме – бер – береңне ярату кебек тоела.

Әмма мондый катнаш никахларның күбесе телне бетерүгә китерә. Бала ата – ана тәэсиренә дучар булып, чит ил телендә аралашырга мәҗбүр була.

Телне без иң камил бер аралашу коралы, кешелек дөньясын алга әйдәүче бер прогресс чарасы дибез. Тел – ул буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән иң мөкатдәс бер мирас. Менә шул байлыкны, хәзинәне кадерләп саклап калу безнең бурычыбыз. Әмма Татарстаннан читтә, башка төбәкләрдә, өлкәләрдә, чит илләрдә яшәп яткан телләрен, гореф-гадәтләрен югалтмаган татарлар, үзләренең мирасын яшь буынга тапшыра алырмы? Шул буын кешеләре динне, телне саклый алырмы?

Без бит һаман татар теленең, туган телебезнең киләчәге тагын да матур булыр дигән өмет белән яшибез. Тик бу өметләр бик үк акланмаслар, ахры.

Чөнки мәктәптә югары сыйныф укучыларының татар теле һәм әдәбияты дәресләре укыту сәгатьләренең саны кыскарды. Бу мәсьәлә дә татар теленең үсешенә бик зур киртә булып тора.

Күз алдына китерик: үзенең туган татар телен белмәгән кеше бөек Тукай, герой-шагыйрьләр әсәрен уку бәхетеннән мәхрүм.

Әгәр татар телен бетерүгә юл куйсак, тора-бара туган телебез бөтенләй юкка чыгачак. Ә тел белән бергә тарих та, мәдәният тә һәм тел белән бәйле булган башка нәрсәләр дә юкка чыгачак.

Шундый ук актуаль проблема булып татар мәктәпләренең юкка чыгарылуы. Үзебезнең Батыр районында гына ике татар мәктәбе ябылды. Кзыл-Чишмә һәм Татар Тимәш авыл балалары күрше чуваш авылларына укырга йөрергә мәҗбүр ителделәр.

Ә мин үзем татар баласы, барлык телләргә дә хөрмәт белән карыйм. Рус телендә әйбәт сөйләшәм, инглиз, чуваш телен өйрәнәм. Ә туган телем – татар телем, анам теле булганы өчен ул миңа аеруча якын. Мин аның киләчәге өчен һич тә битараф була алмыйм. Ул миңа тудырган анам кебек, туган җирем кебек якын. Шуңа күрә аның киләчәге матур буласына ышанам.

Телне үстерүче, кадерләп саклап торучы безнең укытучыларыбыз булганда, чуваш халкы арасында яшәгән татарларның теле, гореф-гадәтләре, йолалары һичкайчан югалмас дип өметләнәм.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: тел – милләт сакчысы. Тел бетсә – милләт тә бетә. Минемчә, татар теленең киләчәге бары тик бездән генә тора. Минем уйлавымча, безнең аңа карашыбыз битараф булмас. Чөнки туган телебез – үзе бер сихри дөнья. Туган телебез – безнең тарихыбыз. Без һичшиксез, әлеге тарихны дәвам итүчеләр, ана телен саклаучылар булырбыз. Чөнки без туган телебезне яратабыз.

# “КЕЧКЕНӘ ИПТӘШЛӘР” ЖУРНАЛЫНЫҢ (1924-1928) ЖАНР ҺӘМ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Вәгыйзова А., КФУ, II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Юсупова Ә. Ш.*

1924 елда «Татарстан» газетасында Муса Җәлилнең 9-14 яшьлек балалар өчен журнал чыгарырга кирәклеге турында мәкаләсе басылып чыга. Шул ук елның 20 мартында Мәскәүдә «Кечкенә иптәшләр» дип аталучы балалар журналының беренче саны дөнья күрә

«Кечкенә иптәшләр журналы – 1924 елның мартыннан Мәскәүдә чыгучы яңа советчыл татар журналы. Журнал гарәп язуында була.

«Тәрбиятел-әтфаль», «Ак юл», «Балалар дөньясы» яшь буынны милли һәм динле итеп тәрбияләү, чын татар җанлы кешеләр үстерү максатын куйсалар, «Кечкенә иптәшләр» белән татар балалар матбугатында бөтенләй үзгә, икенче чор башлана, милләт һәм дин төшенчәләре югала, интернационализм сыйнфый тәрбия алгы планга чыга, яшь буынны яңа җәмгыять — социализмны актив төзүчеләр итеп әзерләү бурычы куела. Журнал комсомол карамагына алына.

Ф. Кәримнең “Хәзер сезнең белән” исемле беренче шигыре “Кечкенә иптәшләр” журналының 1927 елгы икенче санында дөнья күрә.

Басмада Г.Мохтар, Х.Садыйков, М.Парсин, Н.Нәбиуллин составындагы редакцион коллегия эшли. Берара мөхәррире булып М. Уразмөхәммәтев, 1926 елдан Х. Курмаев, 1927 елның 11 нче саныннан журналны Муса Җәлил җитәкли.

Революцион энтузиазм белән канатланып журналга яшь каләмнәр килә. Күтәренке интонацияле шигырьләр күбәя. Күп кенә яшь татар әдипләре журналда үзләренең иҗади эшчәнлекләрен башлап җибәрәләр. Актив авторлар арасында Зәйнәп Бәширова, Н.Гыйбадуллин, А.Мөхтәров, Мөхәммәт Парсин, Н.Рубцова, Х.Садыйков, Т.Салихов, М.Уразмөхәммәтов, Ю.Усманов, И.Юманкуловлар була.

Журнал үзенең максаты итеп укучы яшьләр тормышын төрле яклап яктыртуны куя.

Редакция пионерлар, комсомол эшчеләр, укытучылар арасында хәбәрчеләр челтәре төзү буенча актив эшчәнлек алып бара. Ил буенча басманың барлык саннары турында фикер алыша торган «Кечкенә иптәшләр» журналы дуслары түгәрәкләре барлыкка килә; аның битләрендә яшь хәбәрчеләр җибәргән язмалар даими урын ала.

«Кечкенә иптәшләр»нең эшчәнлеген бәяләп, (ВЛКСМ ҮК) Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр берлеге «журнал үзенең

эшчәнлегенә татар-башкорт эшче һәм крәстиян балаларын актив җәлеп итә», дип яза.

Журналның эчтәлегенә килгәндә, балаларның көндәлек тормышына кергән яңа сүз – пионер сүзе басманың үзәгенә менә.

Й.Госмановның «Канлы көннәр хатирәсе (Кызыл Армиянең җиде еллыгына багышлана)» Г. Мохтарның «Штабтагы кечкенә Габбас», «Ил баласы Шака», Г. Баембитовның «Бүре баласы кайткан», К. Зәйдуллинның «Көтүче Кәшфи» хикәяләре дә ирек һәм бәхетнең авыр көрәшләрдә яулап алынганлыгы, бу көрәшкә кечкенәләрнең дә катнашуы турында сөйлиләр. Журналда дөнья күргән хикәя һәм шигырьләрнең күбесе әдәби эшләнешләре ягыннан әллә ни югары тормасалар да, татар совет балалар әдәбиятының башлангыч үрнәкләре булу ягыннан игътибарга лаек.

Редакция сан саен диярлек юлбашчыларның рәсемнәрен биреп бара. 1924 елның 23 маенда (XIII съездда) пионер оешмасына В.И. Ленин исеме бирелүне зур бәйрәм итеп билгеләп үтә.

Журнал 1925 елның 5 нче саныннан «Октябрятлар почмагы» ача. Монда нәниләр өчен вак-вак хикәяләр, шигъри тезмәләр басыла.

1928 елдан «Кечкенә иптәшләр» латин графикасына күчеп, «Октябрь баласы» дип атала башлый. 1933 елда журнал Казанга кайта, «Пионер каләме»нә әверелә. 1941 елда, сугыш башлангач, журнал чыгудан туктала. Сугыш беткәч, 1952 елда ул «Пионер» исеме белән янә дөнья күрә. Ә 1957 елда, илдә «Пионер» исемле журналлар артык күбәеп китү сәбәпле, журнал исеме «Ялкын»га үзгәртелә.

**Әдәбият**


1. https://tt.wikipedia.org/wiki/Кечкенә_иптәшләр
2. https://tatarica.org/ru/razdely/sredstva-massovoj-informacii/periodicheskie-izdaniya/kechkene-iptehshlyar
3. “Кечкенә иптәшләр” 1927 ел, (42) 10нчы сан

ЛИЧНЫЕ ТАТАРСКИЕ ИМЕНА, ЗАИМСТВОВАННЫЕ ИЗ АРАБСКОГО ЯЗЫКА

*Гайнутдинов Р., РИИ, студент I курса*
*Науч. рук. – стар преп. Замалиева Г.Х.*

Именование не рассматривается людьми как обычное событие. С точки зрения тюркской культуры, создание семьи, рождение детей и их наречение всегда имело большое значение. Средняя Азия, родина тюрков, является основой верований и традиций, укоренившихся в подсознании тюркских общин, а также источником традиции именований. Начиная с памятников Орхана, которые считаются первыми письменными произведениями тюркской истории, в енисейских надписях и в книге Деде Коркута, имеется много сведений о значении, которые тюрки придают именам [1].

Имена отражают их социальную личность или принадлежность к социальной структуре, а также содержит указания и пожелания на будущее ребенка. Следовательно, имена тщательно выбираются, чтобы сделать человека счастливым, успешным, благородным, сильным и хорошим. Имена, связанные с религией, историей или природой, также входят в число древнетюркских традиций. Многие из этих традиций до сих пор сохраняются во многих тюркских общинах.

В тюркской мифологии такие животные как, лев, лошадь, бык, барс, верблюд, олень, тигр, козел, овца, собака, волк, леопард, сокол, орел, журавль, лебедь и другие, занимают важное место в связи с кочевничеством. Кроме того, большое значение в верованиях имеет как сама природа, так и предметы в ней: день (көн), луна (ай), звезда (йолдыз), небо (күк), заря (таң), гора (тау) и море (диңгез) железо (тимер), золото (алтын) и другие. Данные особенности также отражены в именах: Тимур, Тимербике, Чулпан, Айнур, Айсылу, Тансылу, Алтырчура, Танюлдыз, Юлдус и другие [2: 186-188].

После того как тюрки приняли ислам, под влиянием религии произошли значительные изменения в выбранных именах и практике присвоения этих имен детям. Вследствие того, что исламская религия и культура, которые легко адаптируются к тюркской социальной структуре, поскольку ее принципы вполне совместимы с эмоциональной и мыслительной структурой тюркской нации, составляют важную часть тюркской национальной идентичности и сознания. Таким образом, в тюркской культуре стали предпочитать имена, связанные с религией ислам, однако, не забывая свои традиционные имена. В последующие изменения появились общие имена, которые соединяли в себе как арабскую, так и тюркскую.

Касательно чисто арабских заимствований, то их можно разделить на две подгруппы:

1) Имена религиозного значения;
2) Имена светского значения [3: 10-12].

В первую подгруппу относятся имена, имеющие ярко выраженную религиозную основу. В женских именах в основном имена, являющие родственников пророка Мухаммада: Амина, Хадиджа, Гайша, Рукыя, Зайнап, Фатыма и др. Также имена, связанные с религиозным праздником: Гаетсылу (от праздника Гает), Маулида (от названия месяца Маулид) и др. Встречаются также имена имеющие отсылку к религии: Саима (женщина соблюдающая пост), Каусария (священный родник в раю), Мадина (город пророка Мухаммада) и др.

Мужские имена, в основном относящиеся к религии: Динислам, Габдулла (раб Божий), Гайнутдин (богатый верой), Иман (вера), Муслим (мусульманин), Насретдин (тот, кто помогает религии) и другие [1; 2.]

Во вторую подгруппу относятся женские имена, относящие к понятиям обаяние и изящества. Газиза (милая, дорогая), Нафила (подарок), Сагадат (удача, счастье), Джамиля (красивая), Рана/Рания (красивая), Суфия (чистая) и др. Кроме того имеются имена, со словами, которые подчеркивают красоту женщин: бәнат (девушка), камал (без изъяна), ниса (госпожа), нур (луч), җамал (красавица), камәр (луна), шәмс (солнце). Например: Нурджамал (лучезарная красавица), Нурия (лучезарная), Нурбанат (лучезарная девушка), Шамсегаян (приветливое как солнце), Шамсия (солнце), Камарсылу (красивая, изящная как луна), Камария (красивая) и др. [1; 2.]

Мужские имена относящие к понятиям твердости, героизма, главы государства, защитник и т.д. Например: Агзам (возвышенный), Азамат (рыцарь), Азиз (могучий), Амин (честный), Бакир (изучающий), Забир (твердый, сильный), Зуфар (победитель), Мулат (желанный), Камил (совершенный), Латыф (человек с открытым взглядом), Надир (редкостный), Раиль (основатель), Салим (здоровый), Фарид (бесподобный, единственный) и др. [1; 2]

Имена, которые соединили в себе и тюркские и арабские компоненты: Амирхан (правитель), Ильсаф (земная непорочность), Инсаф (самый чистый), Кайсура (герой), Акназар (светлый, лучистый взгляд), Ишморат (желанный друг), Котлыниса (счастливая девушка), Татлыбанат (сладкая девушка), Уразман (обладатель удачи, счастья), Ташмат (прославленный камень), Тимергали (возвышенное железо), Даулатбай (богатое государство), Фаезхан (милосердный, щедрый хан), Асмабика (главная девушка), Колахмат и другие [3: 11].

Взаимосвязь культур отражалась на обоих народов, что приводило к употреблению заимствованных имен, которые оставляли след в истории. В современном мире у СМИ преобладает эффект влияния, в связи с чем общество предпочитает имена героев фильмов, сериалов или самих актеров. От данной тенденции не остались в стороне и арабский мир, в связи распространением турецких сериалов, многие арабы стали предпочитать тюркские имена, например в списке лидеров следующие имена: Барыш, Мерьем, Халит, Берен, Серенай, Кыванч [5]. Хотя ранее арабы по различным причинам сторонились заимствованных имен, но, несмотря на это многие уже употребляли иностранные имена. Например, имена, имеющие тюркские корни: Айлин آيلين (лунный ореол), Айнур آينور (лунный свет), Айтен آيتن (белоснежная как луна), Айтадж آيتاج (лунная корона), Альма ألمى أو ألما (яблоко), Джейлян جيلان (газель), Инджи إنجي (жемчуг), Мераль ميرال (священная гора), Назли نازلي (супруга), Нурай نوراي (луч луны), Тулай تولاي (яркий, как луна), Туркан توركان (турецкий герой) и другие [4].

В данной работе приведена лишь малая часть арабских имен, которые вошли в обиход татарской культуре. Несомненно, в современности у многих семей в определении предпочтений имен стали элементы электронной культуры, такие как телевидение и интернет, используемые большими массами в 21 веке. В результате повлияло на современность и отразилось на предпочтении имен. Однако не следует забывать, что явление, называемое культурой, представляет собой не фиксированную структуру, а динамическую структуру, которая может обновляться в соответствии с эпохой.

**Литература**

1. Аникеева Т.А. «Китаб-и дедем Коркут» как памятник книжного эпоса // Шаги/Steps. 2015. №2. [Электрон. Версия]. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/kitab-i-dedem-korkut-kak-pamyatnik-knizhnogo-eposa (дата обращения: 13.01.2024).

2. Кусимова Т. Исемдәр донъяһында. Башҡорт исемдәре һүҙлеге, башҡорт һәм рус телдәрендә. – Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1991. – 192 б.

3. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 256 б.

4. Ahmad Mustafa Halimah. Translating Arabic proper names: a foreignising approach.// International Journal of English Language and Linguistics Research. Vol.4, No.2, 2016. – pp.1-16. Электрон. версия. URL: https://eajournals.org/wp-content/uploads/Translating-Arabic-Proper-Names-A-Foreignising-Approach.pdf (дата обращения: 02.01.2024)

5. Hurriyet Daily News. Newborns in Middle East named after Turkish TV stars. [Электрон. Версия]. URL: https://www.hurriyetdailynews.com/newborns-in-middle-east-named-after-turkish-tv-stars--95828 (дата обращения: 02.01.2024)

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ БЕР ТӨРЕ БУЛАРАК ТЫҢЛАП АҢЛАУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Гарифуллина Г., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Мөгътәсимова Г.Р.*

Тыңлап аңлау хәзерге дөньяда мөһим күнекмә булып тора һәм ул тормышның төрле өлкәләрендә: мәгарифтә, эштә һәм көндәлек аралашуда таләп ителә.

Тыңлап аңлау – ул үзләштерелә торган авазларны аңлау, аларны мәгънәви комплексларга берләштерү, истә калдыру, мөмкин булганча алдан уйлап кую күнекмәләре. Кешеләр мәгълүматның күп өлешен ишетү каналы буенча ала. Димәк, тыңлап аңлау бәйләнешле сөйләм барлыкка килү процессында мөһим роль уйный. Шуңа күрә теләсә кайсы телне үзләштерү бу бүлектән башлана.

Тыңлап аңлау – сөйләм эшчәнлегенең рецептив төре буларак бер үк вакытта сөйләмне ишетү һәм аны аңлауны үз эченә ала. Ул сөйләм эшчәнлегенең мөстәкыйль төре дип санала.

Үз туган телләрендә сөйләшкән башка кешеләрне нинди очракларда тыңларга туры килергә мөмкин? Әлбәттә, әңгәмә вакытында, шул телдә төрле тапшырулар караганда, дәресләр, лекцияләр барышында укытучыны яки сөйләүчене тыңлаганда һәм башка бик күп очракларда. Шуңа күрә тыңлап аңлауга өйрәнү барышында укучылар тормыш-көнкүрештә әйтелгән мәгълүматларны дөрес ишетергә өйрәнергә тиеш.

Татар теле дәресләрендә дә тыңлап аңлау күнекмәсен ныгытырга кирәк дип саныйбыз. Бу бүлеккә өйрәтү берьяктан, укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыруга булышлык итсә, икенче яктан, дөрес эчтәлекле сайланган текстларны тыңлау укучыларга әхлакый, эстетик һәм мәдәни тәрбия бирә.

Телдән сөйләм китап теленнән аерыла һәм ул түбәндәге үзенчәлекләр белән характерлана:

1. кыска сөйләм кисәкләре хасил булу;
2. сүзлекләрдә күрсәтелгән фонологик әйтелешнең аерылып торуы;
3. еш кына сүзлек түгел, ә сөйләм лексикасы кулланылуы;
4. артык мәгълүмат булу. Сөйләүче еш кына темага кагылышлы булмаган сүзләрне кулланырга мөмкин, мәсәлән, минемчә, ээ һ.б.

Сөйләм эшчәнлеге төре буларак тыңлап аңлау бүлеге дә үзенә хас үзенчәлекләргә ия:

1. Пассивлык. Сөйләшүдән яки язудан аермалы буларак, тыңлап аңлау сөйләм эшчәнлегенең пассив төре булып тора. Кеше нәрсәдер

тыңлаган вакытта телдән тапшырыла торган мәгълүматны кабул итә һәм аны аңларга тырыша.

2. Вакыт белән чикләнгәнлек: артка кайтырга һәм текстны яңадан укырга мөмкин булган укудан аермалы буларак, тыңлап аңлау барышы реаль вакытта башкарыла. Бу тыңлаучыларга игътибарлы булырга һәм мәгълүматны тиз арада эшкәртә белү күнекмәсенен яхшыртырга таләп итә.

3. Шау-шу булу, ягъни сөйләм барышында аңа бәйле булмаган чит тавышлар ишетелү: машиналар тавышы, арткы фондагы башка кешеләрнең сөйләшүе.

4. Игътибарлык таләп ителә. Тыңлап аңлау барышында тыңлаучыдан җитдилек таләп ителә. Аңа сөйләүче сөйләмен игътибар белән тыңларга, ә чит тавышларны һәм читкә юнәлтә торган факторларны игътибарсыз калдырырга өйрәнергә кирәк.

5. Сөйләмнең кабатланмас булуы. Телдән сөйләм табигате белән бертөрле булмаска мөмкин. Сөйләшүчеләр төрле интонацияләр, акцентлар, сөйләм тизлеге һәм хәтта диалектлар кулланырга мөмкин. Тыңлап торучыга мондый аерымлыкларга әзер булырга һәм аңа сөйләмнең төрле стильләренә яраклашу күнекмәләрен булдыру мөһим. Тагын шуны да истә тотарга кирәк: чын тормышта җөмлә бер тапкыр әйтелә һәм, әгәр тыңлаучы тарафыннан соралмаса, кабатланмый. Кабатлап әйткән очракта да теге текстка абстолют туры килмәскә мөмкин. Мәсәлән, “Мин кичә энигә шалтыраттым һәм озаклап аның белән сөйләштем” җөмләсен сөйләүчү “Мин кичә эни белән сөйләшеп алдым” дип үзгәртеп әйтергә мөмкин.

6. Мәгълүматның чикләнгән булуы. Телдән сөйләм вакытында кайбер мәгълүматләр булмаска, әйтелмәскә мөмкин. Тыңлаучы бушлыкларны тутыра һәм булган мәгълүматларга нигезләнеп нәтиҗәләр ясый белергә тиеш.

7. Сөйләүче белән тыңлаучының үзара бәйләнеше. Әңгәмә вакытында сөйләүче, кагыйдә буларак, тыңлаучының үзенчәлекләрен, аның кызыксынуларын һәм ниятләрен исәпкә ала. Тыңлаучы сораулар бирергә, сөйләүченең сүзләрен төгәлләштерергә яисә аңа җавап бирергә әзер булырга тиеш.

Тыңлап аңлауны формалаштыру барышында мөһим шарт булып мотивация тора. Укучыларда тыңлап аңлауга ихтыяҗ булдыру өчен аудиотекстларның дөрес сайлануы мөһим. Авыр, дөрес сайланмаган язмалар өметне өзәргә, ышанычтан мәхрүм итәргә мөмкин. Артык җиңел аудиотекстларның шулай ук файдасы күп түгел, чөнки кыенлыкларны җиңеп чыгу моменты булмау эшне кызыксыз итә. Шулай ук аудиотекстларның укучыларга актуаль булган проблемаларга

багышланган булуы кызыксуны арттыру чарасыннан санала. Мисал өчен, укучылар тарафыннан дуслык һәм мәхәббәт, һөнәр сайлау, башка ил халыклары тормышы турындашы аудиотекстлар зур кызыксыну белән кабул ителә.

Шулай итеп, аудирование сөйләм эшчәнлегенең мөстәкыйль төрен тәшкил итә һәм ул катлаулы бүлекләрдән санала. Укучыларга сөйләм эшчәнлегенең бу төрен аның үзенчәлекләрен исәпкә алып өйрәтергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Елухина Н.В. Обучение аудированию в русле коммуникативно-ориентированной методики // Иностранные языки в школе. – 1989. – № 2. – С. 29-31

2. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Хәтер, 2001 – 368 б.

3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 234 б.

# ШӘРИФ КАМАЛ ИҖАТЫНДА КЕЧКЕНӘ КЕШЕ ОБРАЗЫ

*Гатауллина Р., Буа р-ны, Түбән Наратбаш мәктәбе, IX сыйныф*
*Фән. җит. – Исланова Г.Г.*

Еллар, чорлар алмашынып торганда да исемнәре җуелмыйча, күп меңләгән укучылары күңелләрендә мәңгегә урнашып кала торган әдипләр була, – аларның әсәрләренә тарих тузаннары да кунмый – андыйлар гел балкып, күңелләрне сөендереп яшиләр дә яшиләр. Мондый язучыларны классик әдипләр дип, ә аларның әсәрләрен классик әдәбият дип атыйлар. Аңлашыла ки, бу сүзләрне олы хөрмәткә лаеклы шәхесләргә һәм аларның үлмәс иҗатларына карата гына әйтергә мөмкин. Шәриф Камал – әнә шундыйларның берсе.

Язучы үз әсәрләрендә бик күп төрле проблемаларны күтәрә, күп төрле образларга мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, берничәсен генә атап үтик: Гади кешеләрнең авыр тормышын һәм рухи фаҗига белән тулы язмышын гәүдәләндергән *“Уяну”* (1909), *“Буранда”* (1909), *“Сулган гөл”* (1909), *“Сукбай”* (1910) хикәяләре. *“Кычкырыш”* (1910), *“Бер картның тойгылары”* (1910), *“Курай тавышы”* (1912) һ. б. хикәяләрендә кешелеклелек тойгысының чынбарлыктагы явызлык күренешләре белән бәрелешүе, шуның нәтиҗәсендә туган бәхетсезлек, вөҗдан газабы, драматизм сурәтләнә. Авыл зыялылары образларын үзәккә куйган *“Авыл мөгаллиме”* (1910), *“Шәкерт”* (1910) хикәяләре. Вакытлы шахтерларның авыр тормышын караңгы буяуларда сурәтләгән *“Козгыннар оясында”* (1910) әсәре. 1914 елда язылган *“Акчарлаклар”* әсәрендә балык тоту промыселларына, акча эшләү нияте белән бәхет эзләп, эшкә килгән вакытлы эшчеләрнең тормышы сурәтләнә.

Ш. Камал әсәрләрендә кеше, аның бәхете мәсьәләсе кызыл җеп булып сузылган. Беренче булып, тормыш тарафыннан рәнҗетелгән геройларны – кечкенә кешеләрне – рус әдәбиятына А.С. Пушкин “Станционный смотритель” әсәрендә алып килә. Шулай ук әлеге темага М.В. Гоголь, И.С.Тургенев һ.б. бик күпләр мөрәҗәгать иткән. Татар әдәбиятында исә бу теманы күтәрүчеләрнең берсе булып Ш. Камал тора. “Ул хикәяләрендә гомер буе изелеп, каһәрләнеп яшәүдән гаҗизләнгән, барыр кыйбласын тапмый гасабиланган, еш кына кешелеген югалту дәрәҗәсенә җиткән типлар үзәккә алына, шыксыз тормыш тудырган ямьсез инстинктлар алгы планга чыга. Язучының “Муса ачуланган иде. Ачуыннан күзләре акайган, йөзе ут шикелле яна, дулкынлануыннан сүзен әйтә алмый иде...” сүзләре белән башланган *“Уяну”* дигән беренче хикәясе кешедәге шул ерткычлык сыйфатларын

калку итеп тасвирлауга һәм явызлыкның авыр фаҗигасен өшеткеч картиналарда сурәтләүгә багышланган”.

Тегермәндә эшләүче Муса исереп кайтып, хатыны Гафифәне вәхшиләрчә кыйный һәм аның үлеменә сәбәпче була. Авыр тормышта изелгән ир (ә язучы аның кайчандыр бай баласы булуын әйтеп уза) каһәрләнгән тормышына үч йөзеннән үзе кебек бичара хатынын җәберли. Үзе кебек үк бәхетсез булган җанның елавыннан, инәлүеннән ләззәтләнә, “вәхши хиссиятеннән вәхши шигырь” эзләп кәефләнә. Әмма аның бу соңгы кыйнавы үтә ерткычларча булып, анда ирексездән бераз кешелек сыйфатлары да җанланып куя. Хикәядә Муса тетрәткән һәм кыланышларының үтә вахшилеген ассызыклаган бер эпизод бар. Ирнең күзе кинәт ишек төбенә төшә һәм аның тәне чымырдап, чәчләре үрә тора: “Ишек төбендә ...бер күз!...яшьле күз...туп-туры Мусаның күзенә карый...Гафифәнең күзе...”. Караса, ул хатынының күлмәгеннән өзелеп калган төймә икән... ләкин бу күренеш Мусаның аңына фаҗигане бөтен тулылыгына җиткерә һәм укучыны шәхес трагедиясенә әзерли. Гафифә һәлак булгач, Муса акылдан шаша. Әнә шул рәвешле, кыргыйлык, вәхшилек белән кешелек сыйфатларының кискен бәрелеше тирән кичерешләр, тетрәнүләр белән үрелеп фаҗиганең психологик аспектын тәшкил итә.

Төзәтеп булмаслык, югалту үкенече, кешенең изелгәнлеге темасы *“Буранда”* исемле хикәядә дә кабатлана.

Мостафа озакка сузылган солдат хезмәтеннән кайтып килә. Бу көнне авылына барып җитә алмыйча, ул, үзе белән бергә хезмәт иткән Хөсәен исемле иптәшенең өендә кунарга туктала. Көн буранлы. Мостафаның монда кунак булып ятасы килми – тизрәк үз авылына китәргә ашкына. Әнисенең үлем хәлендә ятканын улы, шулай ук улының менә-менә кайтып керәчәген әнисе тәгаен генә белмиләр. Кайчандыр алар аңлаша алмаганнар. Мостафа сүзе һәм игътибарсызлыгы белән ананы рәнҗеткән дә. Алай да бәхилләшү, аңлашу минутлары булыр дип көтәсең. Ә үлем хәлендәге әнисе “күзләре белән нидер эзли, нидер юксына, кемнедер күрмичә үләсе килми, торып-торып:

Килмәдеме? ... – дип сорый иде”.

“Хикәядә менә шушы якын, тугандаш җаннарның һичнәрсәгә карамыйча, бер-берсенә тартылулары әсәрнең үзенә бер төрле төсмерен тудыра. Әмма хикәя көтелгән кавышу белән тәмамланмый. Мостафа газиз анасының әле суынырга да өлгермәгән үле гәүдәсе янына гына кайтып җитешә:

“Аһ... Кяшки ул бер генә карасын!..

Ләкин ул инде карый алмый иде... Чөнки әлеге нечкә тармакның чыганакларына карап торган көенчә, очыннан ычкынып киткән иде...

Тышта буран һаман дулый иде”.

Шулай итеп, Ш. Камал иҗатында кечкенә кеше образы бик ачык, төгәл сурәтләнгән. Алар тормышның төрле почмакларында, төрле шартларында яшәүчеләр, язмышлары күңелсез, фаҗигале. Геройлар тормыш гаделсезлеге, рәхимсез чынбарлык тудырган бәхетсезлек корбаннары буларак тасвирлана.

**Әдәбият**

1. Гыйләҗев Т. XX йөз башы татар әдәбияты тарихын укыту мәсьәләләре. – Казан: “Печатный двор”, 2002. – 37-41 б.

2. Сверигин Р. Гүзәллеккә юл ярганда... // Казан утлары. – №2. – 2009. – Б. 165-169.

3. Камал Ш. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.

# Л. ӘБҮДӘРОВАНЫҢ “КАРА КАПЛАН” ХИКӘЯСЕНДӘ СУРӘТЛӘНГӘН ДӨНЬЯ

*Гатиятова А., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гайнуллина Г.Р.*

Ландыш Әбүдәрова хикәяләре күтәрелгән тема, проблема, сюжет-композиция ягыннан караганда шактый төрле. Соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре арасында “Кара каплан” хикәясе игътибарга лаек. Язучының әлеге әсәре “Казан утлары” журналында тәкъдим ителә. Әсәр композицион яктан бүленгән булуы белән аерылып тора. Автор тормышны ике өлеш: үткән һәм бүгенгедән торган бербөтен кебек күрсәтә. Оста, матур тел белән язылган хикәядә төп урын үткәндәге һәм бүгенге вакыйгаларны сурәтләүгә корылган.

“Кара каплан” хикәясе табигать күренешен сурәтләү белән башланып китә: “Агыйдел төн караңгылыгына күмелеп, күктә йолдызлар кабынырга да өлгермәде, офык чите ястү намазы алдыннан була торганча алланып та килә башлады. Төннәр якты вакыт, хәтта ки җәядән аткан ук ераклыгында кеше торганны абайлап була” [1]. Авторның табигатькә мөрәҗәгать итүе очраклы түгел. Беренче чиратта, төнге күкнең матур сурәте: ай, офык, йолдызлар укучының игътибарын җәлеп итә, икенчедән, искиткеч матур табигатьле дөнья эченә алып кереп китә. Өстәвенә вакыйгалар барачак урын яки җирлек белән таныштыра. Димәк, әлеге өзектәге пейзаж бирелеше вакыйгаларның урынын билгеләү вазифасын үти. Алга таба табигатьне тасвирлау дәвам итә, автор таң ату күренешен оста рәссамнарча сурәтли: “Таң атканда, Агыйдел үзе дә алсу-кызыл төскә манчыла. Кояшы да бит аның болыт кадәр, олы шар булып тәгәрәп килеп чыга. Чыга да кызыллыгын шактый вакыт җуймыйча тора”.

“Кара каплан” хикәясендә төп урын буыннар дәвамчанлыгы, буыннар бәйләнеше темасын яктыртуга бирелгән. Беренче тарихта Барысның улларын Сабан туена әзерләве турында хикәяләнә. Сабантуйда була торган һәр ярыш-бәйге катнашучыларның көчен сыный. Барысның зур теләге – улларының үз гәүдәләренә хуҗа булып, капланга хас җитезлек, сыгылмалылык, төгәллек, тизлек кебек сыйфатларга ия булулары. Аның газиз улларын яшьтән үк дөрес тәрбияләргә тырышуы күренеп тора. Барыс үзе дә дошман гаскәренә каршы берүзе көрәшә һәм сынатмый:

“Әмма Барыс аларны ишетми иде, ул нәкъ кендек турысында бер гайрәтле көчнең гүләвен тоеп алды. Ул көч тимерче мичендәге ялкын сыман дөрләп кабынды да тиз арада чүлмәкче мичендәге кебек кайнарлыкка җитеп, аның бөтен тәнен чорнап алды”. Биредә Барысның

дошманга каршы көче үскәннән-үсә баруы, артуы тасвирлана. Дошманга каршы ул батырларча көрәшә, Кара Каплан рухы биләгән Барысны җиңәрлек көч табылмый. Көрәш рухы халыкны саклап калган. Читтән карап торучылар аның җитезлегенә, елгырлыгына, осталыгына, хәрәкәтләренең зәрканчыларныкы кебек төгәллегенә, сыгылмалылыгына, уйланганлыгына сокланалар.

Икенче тарихта бүгенгене үткәндәге күренеш белән ялгаган вакыйгалар урын алган. "Сабан туйлары җитә башласа, Хәсәнне эчтән ут ялмап ала. Башта кендек турысында әйләнә ул, тора-бара күкрәгенә менә, беләкләренә төшә, бөтен тәненә үрли". Әлеге юллар беренче тарихта сурәтләнгән Барысның дошман гаскәренә каршы көрәшүен хәтерләтә. Барысның да бит кендек турысында ниндидер билгесез бер көч пәйда була һәм аның бөтен тәне буенча тарала. Икенче тарихның төп герое Хәсәннең дә эчендә көрәш уты яна, ләкин бу турыда башта беркем дә белми. Бары тик әнисе Хәдичә Сабир картка мөрәҗәгать иткәч кенә, Хәсәннең чың көрәшче булуы ачыклана. Шул рәвешле Хәсән Сабантуйларда бил алышуда катнаша башлый: җиңә, җиңелә. "Кендек турысындагы ут та тора-бара идарә ителә торган көч чыганагына әйләнде. Хәсәннең бик борынгыдан килгән нәсел-нәсәбендәге кан үзе турында шулай белгертә, шул аны мәйданга алып чыга..." – дип яза автор. Әлеге өзектән күренгәнчә, Ландыш Әбүдәрова көрәш рухы, Кара Каплан рухы югалмавын искәртә. Көрәш чын мәгънәсендә халыкның яшәү көчен, батырлыгын күрсәтә. Бил алышу, көрәшү традицияләре буыннан-буынга күчеп, Барыс батырдан Хәсәнгә дә килеп җитә.

Хикәя ахырында Ландыш Әбүдәрова кабат пейзаж алымына мөрәҗәгать итә. Автор Агыйдел буе табигатен сурәтли: "Нәкъ аның яшь чагындагы кебек былбыллар өздерә, иркә таллар таң җиленә толымнарын сүтеп салган, су эченә үк кереп үскән камышлар пышылдаша". Хәсән туган ягына, туып-үскән авылына әйләнеп кайта, Агыйдел буена төшә, андагы матурлыкка хозурлана, соклана. Укучы алдында да табигать әйтерсең лә җанлана, хәрәкәтләнә башлый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, язучы әсәрендә сурәтләнгән дөньяны психологизм, пейзаж алымнары ярдәмендә ачып бирә. Автор күренешләрнең сәнгатьчә матурлыгын, тирән мәгънәсен сурәтләп күрсәтүгә ирешә, композицион яктан бүлеп үзенчәлекле итеп тәкъдим итә. Моның нәтиҗәсендә әсәр кеше күңелен тулысынча яулап ала: уйландыра, моңландыра, елата, җырлата, сагындыра.

**Әдәбият**

1. http://kazanutlary.ru/news/mydan-batyrlar-chen/kara-kaplan-khikya

2. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 271 б.

3. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Н.М.Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

4. Загидуллина Д.Ф. Современная татарская проза (1986-2016 гг.): основные тенденции историко-литераторного процесса. – Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. – 246 с.

# ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРДӘ ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

*Гафиятова И., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сибгаева Ф.Р.*

Минем фәнни – тикшеренү эшемнең темасы – “Әдәби әсәрләрдә иярченле кушма җөмләләр үзенчәлеге”. Максатым: Г. Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек”, Н. Фәттахның “Итил суы ака торур” әсәрләрендәге иярченле кушма җөмләләрне чагыштыру. Бурычларым: 1. Ике язучының әлеге әсәрләрен тулысынча укып чыгу. 2. Һәр ике әсәрдән барлык иярченле кушма җөмләләрне җыю. 3. Барлык җөмләләрне төзелешләре һәм мәгънәләре ягыннан анализлау.

Мин әдәби әсәрләр укыган вакытта язучының язу стиленә, җөмләләрнең төзелешенә игътибар итәм. Миңа бигрәк тә туган ягыбызның матурлыгын, күпьеллык тарихыбызны чагылдырган әсәрләр ошый. Мин Г. Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек”, Н. Фәттахның “Ител суы ака торур” әсәрләрен тулысынча укып чыктым. Миндә ике әсәрдәге иярченле кушма җөмләләрне чагыштырып карау теләге туды. Ә төп эшкә тотынганчы, минем иярченле кушма җөмләләрнең өйрәнелү тарихын беләсем килде. Шушы өлкәгә караган бик күп хезмәтләр белән таныштым, интернет материалларыннан файдаландым. Татар сөйләм төзелешен тикшерүнең беренче адымнары Казанның рухани уку йортында татар теле укыткан Александр Троянский тарафыннан 1842 нче елда ясалуы, әле аның ул вакытта җөмлә төшенчәсен билгели алмавын белдем. Ә менә М. Иванов татар теленә хас иярчен җөмләләр дип аларның синтетик төрләрен генә санаган. Аналитик кушма җөмләләрнең кем ки сүзләре белән бәйләнгәннәрен генә күргән һәм аларның татар теленә хас түгеллеген әйткән. Алга таба Александр Казимбәк тә хезмәтләр язган. Ләкин монда кушма җөмләләрне тезмә һәм иярченле төрләргә бүлү юк. 1860 нчы елда татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри кулланма чыгара. Соңрак аның “Әнмүзәҗ” дигән грамматикасы басылып чыга. Кушма җөмлә синтаксисы биредә шактый урын ала.

1911 нче елда Г.Ибраһимовның “Татар нәхүе” дигән синтаксис китабы басыла. Иярчен җөмләгә билгеләмә бирә, аларның биш төрен күрсәтә. Г. Ибраһимов синтетик иярчен җөмләләрне генә иярчен җөмлә дип атый, аналитик иярчен җөмләләрне тезмә кушма җөмләләр белән бергә тикшерә. Җ.Вәлиди, М.Корбангалиев һ.б. авторлар да иярчен җөмлә дип бары синтетик иярчен җөмләләрне генә таныйлар.

Г.Алпаров “Татар телендә иярчен җөмләләр бармы?” дигән мәкалә яза. Анда ул “иярчен җөмләләр бер кабыргалары белән тулы

җөмләләргә якын торсалар, икенче кабыргалары белән иярчен кисәкләргә якын торалар”, – дигән фикерне әйтә.

50 нче еллардан башлап М.Зәкиев, В.Хангилдин, С.Ибраһимов, Ф.Сафиуллина, Ш.Н.Асылгәрәев кебек галимнәр күп хезмәтләр язалар. Кушма җөмләләр синтетик һәм аналитик төрләргә бүлеп өйрәнеләләр.

Ике әсәрдә барлыгы 503 иярченле кушма җөмлә булып, “Итил суы ака торур” әсәрендә 202, “Туган ягым – яшел бишек” әсәрендә 301 иярченле кушма җөмлә булды Төп өлештә иярченле кушма җөмләләрне төзелешләре һәм мәгънәләре ягыннан анализладым. Төзелешләре ягыннан һәр ике язучының да синтетик иярченле җөмләләрне, мәгънәсе ягыннан караганда, иярчен вакыт җөмләләрне күп куллануларын белдем. Г.Бәшировта синтетик иярчен җөмләләр 264, Н.Фәттахта 164 булса, иярчен вакыт җөмләләр Г. Бәшировта 149, Н. Фәттахта 105 булды. Фәнни-эзләнү эшемне башкарып мин шундый нәтиҗәгә килдем: ике язучыда да уртак яклар бик күп, аермалы яклар да юк түгел. Г.Бәширов иярченле кушма җөмләләрне күбрәк кулланган. Һәр ике язучының да теле бик матур .

Тел – гаҗәеп үзенчәлекле, катлаулы күренеш. Аның кайсы гына өлкәсен алып карасаң да, кызыклы һәм шул ук вакытта мөһим фактларга тап буласың, әллә никадәр яңалыклар ачасың. Дөньяны танып – белү кебек үк телне өйрәнүнең дә ахыры- чиге юк. Шушы телдә рәхәтләнеп сөйләшә, уйлый, фикерли алуым белән чиксез бәхетле мин. Язучыларыбыз әлеге әсәрләре аша туган телебезнең нинди бай, матур тел булуын күрсәтергә тырышкан. Менә бу безнең өчен үрнәк, менә бу безгә бәһасез зур мирас! Шушы мирасыбызны саклау безнең кулда. Телебез беркайчан да бетмәсен, тел байлыгыбыз кимемәсен иде.

**Әдәбият**

1. Бәширов Г. Туган ягым – яшел бишек // Сайланма әсәрләр. 5 томда, 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 397 б.
2. Зәкиев М.З.Татар грамматикасы III том. – М.: “Инсан”, Казан: “Фикер”, 1999. – 512 б.
3. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.
4. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы. – Казан: Мәгариф, 2008. – 398 б.
5. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407 б.
6. Фәттах Н.С. Итил суы ака торур. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 397 б.

# СЛЕНГ КАК СВОЕОБРАЗНЫЙ СПОСОБ САМОВЫРАЖЕНИЯ У МОЛОДЕЖИ (НА ПРИМЕРЕ РУССКОГО, КИТАЙСКОГО И БАШКИРСКОГО ЯЗЫКОВ)

*Гильманова Л., УУНиТ, аспирант 3 г.о.*

Сленг, являясь лингвистическим явлением – занимает уникальное место в жизни каждого индивида, особенно молодого пласта общества. Молодежью можно назвать людей от 18 до 25 лет, у которых нет таких больших обязательств, как у работающего взрослого, у них больше свободного времени, нет семьи и детей, и в основном молодые люди где-либо учатся. В общественно-социальном пространстве у молодежи особая позиция, так как они в большинстве случаев не работают, у них нет строгих рамок поведения, за счет этого молодые люди чаще всего в той или иной степени неординарно проявляют себя, подвержены творчеству. Такое проявление также свойственно и для их речи. Речь молодежи более яркая, необычная, в ней много каких-либо ненормативных выражений, в том числе присутствует и сленг.

Рассмотрим пласт молодежного сленга. Молодежный сленг очень схож с личностями, которые его используют в речи, то есть такой вид сленговых слов более яркий, импульсивный, быстроменяющийся, богат словообразовательными формами. Молодежный сленг – это слова и выражения, которые употребляют молодые люди, а также более поколение старше них считают, что данные слова звучат вульгарно и странно [1].

Молодежный сленг это, прежде всего, творческое самовыражение. И во всем мире молодое поколение использует слова, выражающие их отношение к миру, их точку зрения.

Например, в русском языке в 2023 году были популярны такие сленговые выражения:

Душнила – это человек, который часто исправляет своих собеседников, из-за данной черты его характера с ним сложно общаться. Пример использования: «Ну ты и душнила, кто-нибудь откройте окно».

Краш, крашиха – это выражение используется по отношению к объектам, к которым говорящий испытывает симпатию и любовь.

Инфоцыгане – данное выражение имеет негативный окрас, описывает человека, который не прилагает никаких усилий и зарабатывает деньги. В большинстве случаев «инфоцыганами» называют некоторых блогеров, из-за того, что они продают какие-либо

информативные продукты, которые не несут в себе никакой пользы для обывателя.

В русском языке в 2023 году в основном были популярны сленговые слова, которые являются существительными. Молодежь пользуется сленгом, так как данные выражения наиболее экспрессивны, а также коротко и емко дают характеристику тому или иному явлению. Но также можно отметить, что сленг в большинстве случаев используется для забавы, так как в литературном языке есть синонимические выражения.

В китайском языке в большей части популярны словосочетания. Например, такие как:

显眼包xiǎnyǎn bāo – это выражение применяется в основном по отношению к индивидам, которые привлекают к себе внимание с помощью внешнего вида или же характера, но могут делают это не намеренно. Что касается строения слова, иероглиф 包 ставится в конце прилагательного или же глагола, чтобы описать характер личности. 显眼 дословно переводится как «видный, яркий, импозантный». Изначально данное слово имело негативный окрас, но на данный момент характеризует людей, которые имеют милый и яркий характер, и с помощью этого привлекают к себе внимание. В интернете можно часто увидеть комментарий «每个物种每个领域都有自己的显眼包» (Каждое явление имеет свое очарование).

配享太庙Pèixiǎng tàimiào – данное выражение пришло из телевизионного сериала «知否» («Знать или не знать»), это шутливое выражение часто использовала в своей речи одна из героинь – госпожа Ван. В древние времена 配享太庙 называли чиновников, которые добились больших высот в службе. В современной речи данное выражение используется, чтобы выразить восхищение знаниями и способностями того или иного человека и чтобы указать его высокие умения. Если смотреть прямой перевод, то 配享 переводится как «заслужить какую-либо похвалу», 太庙 – «императорский храм», дословно на русский язык можно перевести как «Кто-либо заслуживает быть похороненным в императорском кладбище».

那你报警吧Nà nǐ bàojǐng ba – на первый взгляд, данное шутливое словосочетание обозначает неспособность решить ту или иную проблему, показывает беспомощность. Дословно выражение переводится как «Давай, тогда ты позовешь полицию». Но это не обозначает, что говорящий не понимает, как разрешить проблему, это значит, что точка зрения и аргументы другой стороны не были поняты,

и он считает, что больше не имеет смысла продолжить разговор. В основном используется, чтобы закончить спор.

После исследования популярного сленга у молодежи, можно сказать, что в китайском языке популярный молодежный сленг в большинстве случаев используется в социальных сетях. А также основой образования сленговых выражений является какая-либо локально известная история или же киноиндустрия.

В башкирском же языке, хоть и сленговых выражений мало, однако они в языке образуются под влиянием молодого поколения. Так как именно молодежь является главным лицом, которое использует сленг и жаргон. В башкирском языке сленг в основном образуется под влиянием русского языка. Например, такие выражения как Нормалай – от русского слова «нормально». Данное выражение принято использовать как ответ на вопрос «Как дела?».

Таким образом, в башкирском языке в роли сленга используются слова на русском языке, происходит русификация нелитературной речи. Данное явление означает, что язык перестает развиваться, так как не образовываются новые слова [2].

Подводя итог, можно сказать, что сленг показывает менталитет молодого поколения, их жизненные ориентиры и цели. Выполняя мировоззренческую функцию, молодежный сленг показывает взаимоотношения молодых между собой. Само молодое поколение считает сленг неотъемлемой частью своей речи. Используя нелитературные слова, они могут самоутверждаться [3]. Современный молодежный сленг является интереснейшим лингвистическим феноменом, который также имеет влияние на другие сферы языка.

Делая вывод, можно сказать, что чрезмерное использование сленга в речи может нести пагубное, маргинальное влияние на языковую культуру еще не сформировавшейся личности, на его становление как индивида. Поэтому не стоит поощрять использование сленга в некоторых сферах жизни молодых людей.

**Литература**

1. Алимов Г.Ю. Молодежный сленг и разговорная речь в современной лингвистике // Молодой ученый. – 2017. – №12. – С. 606-608.

2. Ахтямов М.Х. Современный башкирский язык. Лексикология, фразеология, лексикография. – Уфа: БашГУ, 2002. – 296 с.

3. Грязнова Е.В., Гончарук А.Г. Теология как научная специальность магистратуры: проблемы и перспективы их решения // Вестник Мининского университета. – 2019. – Т. 7. – №3. – С. 1-3.

4. Кулакова К.В. Функции молодежного сленга // Вестник научных конференций. – 2016. – №4-3(8). – С. 81-83.

5. Чжоу Цихуань. Краткое описание способов употребления буквенных сокращений // Пекин: Вестник китайской академии гражданской авиации. № 20.

# ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ КОМПОНЕНТ В ПРЕПОДАВАНИИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

*Гилязова Р., КФУ, студент V курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ашрапова А.Х.*

Лингвокультурологический компонент – это изучение языка в контексте культуры и истории народа, который на нем говорит. Это важный аспект преподавания языка, поскольку он помогает учащимся лучше понять и оценить культурные различия и сходства между ними и носителями языка.

В рамках лингвокультурологического компонента можно включить следующие элементы:

1. Изучение культурных традиций и обычаев: знакомство с праздниками, национальными блюдами, фольклором и т.д.
2. Изучение страноведения: географии, истории, политической системы страны, языка которой обучают.
3. Знакомство с произведениями искусства: литературой, музыкой, кинематографом, живописью и т.д., которые отражают особенности культуры данного народа.
4. Обсуждение социальных и культурных норм: принятых моделей поведения, ценностей, правил и запретов, которые определяют поведение людей в данной культуре.
6. Анализ языковых единиц с культурным компонентом: фразеологизмов, идиом, пословиц и поговорок, которые отражают национальные особенности и традиции.

Лингвокультурологический подход в преподавании языков позволяет учащимся не только овладеть языком как средством общения, но и изучить особенности культуры, истории и менталитета народа, говорящего на этом языке. Это способствует формированию межкультурной компетенции, которая является важной составляющей успешной коммуникации и взаимодействия между представителями разных культур [4: 43].

Интерактивная тетрадь – это эффективный инструмент для реализации лингвокультурологического подхода в преподавании иностранных языков. Она позволяет учащимся активно участвовать в процессе обучения, развивать свои навыки и знания, а также лучше понимать культурные особенности изучаемого языка [2: 102].

Одним из способов отражения лингвокультурологического компонента в интерактивной тетради является использование заданий на сопоставление культурных реалий. Например, можно предложить учащимся сравнить традиции и обычаи своей страны с традициями и

обычаями страны изучаемого языка. Также можно использовать задания на описание культурных символов, таких как национальные костюмы, блюда, праздники и т.д.

Еще один способ отражения лингвокультурологического компонента – это использование аутентичных текстов. Это могут быть отрывки из литературных произведений, статьи из газет и журналов, записи интервью с носителями языка и т.д. Учащиеся могут анализировать эти тексты, обсуждать их содержание, высказывать свое мнение и аргументировать свою точку зрения.

Также важно включать в интерактивную тетрадь элементы межкультурного диалога. Это может быть обсуждение различных культурных ценностей, стереотипов, предубеждений и т.д. Такие дискуссии помогут учащимся лучше понимать и принимать культурные различия, что является важным аспектом успешного межкультурного общения.

Лингвокультурологический компонент в преподавании татарского языка играет важную роль в формировании межкультурной компетенции учащихся. Он позволяет учащимся познакомиться с культурой, историей и традициями татарского народа, а также способствует развитию их коммуникативных навыков.

Для реализации лингвокультурологического компонента в преподавании татарского языка можно использовать различные методы и подходы. Например, можно проводить уроки, посвященные татарской культуре, истории и традициям. Также можно использовать интерактивные методы обучения, такие как дискуссии, ролевые игры проекты и т.д.

Важным аспектом лингвокультурологического компонента является изучение татарских литературных произведений. Чтение и анализ произведений татарских авторов помогает учащимся лучше понять культуру и традиции татарского народа.

Кроме того, лингвокультурологический компонент может быть использован для изучения татарской кухни, музыки, искусства и других аспектов культуры. Это поможет учащимся лучше понять татарский народ и его культуру, а также развить свою межкультурную компетенцию.

Таким образом, интерактивная тетрадь является эффективным инструментом для отражения лингвокультурологического компонента в преподавании иностранного языка. Она позволяет учащимся изучать язык и культуру одновременно, развивать свои коммуникативные навыки и формировать межкультурную компетенцию.

## Литература

1. Гальскова Н. Д. Современная методика обучения иностранным языкам: Пособие для учителя. – М.: Аркти-Глосса, 2000. –165 с.

2. Гальскова Н. Д., Гез Н.И. Теория обучения иностранным языкам. Лингводидактика и методика : учеб. пособие для студ. лингв, ун-тов и фак. ин. яз. высш. пед. учеб. Заведений. – 6-е изд., стер. – М .: Издательский центр «Академия», 2009. – 336 с.

3. Евдокимов, В. И. Наглядность и эффективность обучения: Учеб. пособие [для пед. ин-тов]. – Харьков : ХГПИ, 1988. – 85 с.

4. Маслова, В.А.. Лингвокультурология: учебное пособие: для студентов высших учебных заведений. – 4-е изд., стер. – М.: Академия, 2010.

5. Селевко, Г. К. Современные образовательные технологии: Учебное пособие. – М.: Народное. образование, 1998. – 256 с.

## БЕРТУГАН ШӘРӘФЛӘР МУЗЕЕ

*Гобәйдуллин И., Буа р-ны Аксу урта гомуми белем бирү мәктәбе, X сыйныф*

*Фән. җит. – Гобәйдуллина И.И.*

Шәрәфләр нәселе. Хәбәрдар кеше өчен бу нәсел күп нәрсә хакында сөйли. Шиһап, Шәһер, Борһан, Гыйльметдин һәм Галимҗан Шәрәфләр. Аларның урыны – татар халкының азатлыгы һәм бәхете өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшкән зыялы затларыбыз йолдызлыгында. Исемнәре, башкарган хезмәтләре дистәләрчә еллар буена халыктан яшерелеп торса да, алар янә безнең хәтергә кайта баралар.

Чыгышлары белән бертуган Шәрәфләр Буа районы (элеккеге Тәтеш өязе) Кишер Аксуы авылыннан. Шул уңайдан, Аксу гомуми урта белем бирү мәктәбендә Шәрәфләр нәселенә багышланган музей эшләп килә. Ул фактик һәм күрсәтмә материаллар белән җиһазландырылган, нәсел шәҗәрәсе эшләнелгән. Бертуган Шәрәфләрнең эшчәнлеген һәм фаҗигале язмышларын чагылдырган архив документларының, вакытлы-матбугат материалларының күпсанлы күчермәләре урнаштырылган, фотоальбомнары, зур стендлар төзелгән. Бу уникаль материалларны туплауда Сания Шәрәф-Акҗитова (Шәһер Шәрәфнең кызы) булышлык иткән. Ул безнең музейга Галимҗан Шәрәфнең кульязмаларын бүләк иткән.

Музейга килгәч, Шәрәфләр дөньясына кергәндәй тоела. Анда тупланган материалларга таянып, Бертуган Шәрәфләрның күпкырлы эшчәнлекләрен, батырлыкларын, фаҗигале язмышларын күзалдыннан үткәргәндәй буласың.

*Шәһретдин Шәрәф (1877-1938)* – җәмәгать һәм дин эшлеклесе, язучы, педагог. 1899-1919 елларда Казанда “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә мөгаллим. 1930 елларда Уфада Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәтендә казначы. Укытудан тыш, Ш. Шәрәф фәнни хезмәтләр язу өстендә дә эшли. Аның каләм мирасы, кызганычка каршы, барланмаган. Мәгълүм әсәрләреннән ислам тарихына багышланган “Гасры сәгадәт”, “Әсхабе кирам”, күренекле тарихчы Ш.Мәрҗанинең тәрҗемәи хәлен өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәте.

*Борһан Шәрәф (1883-1942)* – җәмәгать эшлеклесе, язучы, нашир, педагог. “Мөхәммәдия” (1899-1905) һәм “Хөсәения” (1909-1918) мәдрәсәләрендә мөгаллим. Бер ук вакытта 1905-1917 елларда “Казан мөхбире”, “Әхбар”, “Вакыт” газеталары, “Шура” журналы хезмәткәре. 1917 елда Оренбург мөселманнар бюросы рәисе. 1919-23 елларда Оренбургта Халык мәгарифе институтында укыта. 1930 елдан

Урта Азиядә наширлек хезмәтендә. Гани Хөсәеневкә багышланган “Гани бай” (1914), “Иран мәктүбләре” (1909) һ.б. хезмәтләр авторы.

*Гыйльметдин Шәрәф (1885-1942)* – җәмәгать эшлеклесе, нашир. Казанда “Матбагаи Шәрәф” (1906-1913) китап басмаханәсен оештыручы һәм аның җитәкчесе. 1917 елда Тәтеш өязе мөселманнарының Казан оешмасы рәисе, “Тәтеш оешмасы” газетасытасы мөхәррире, Милли Шура әгъзасы. 1920 елларда Казан хосусый коммерция банкы идарәсендә рәис урынбасары (1927 елгача). Туган авылы Аксуда мәктәп салуга зур булышлык итә.

*Галимҗан Шәрәф (1896-1950)* – сәяси эшлекле, күренекле тел галиме, язучы. Студентлар түгәрәге “Татар учагы”н оештыручы һәм аның җитәкчеләреннән берсе. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917-1918). Татар һәм башкортларны эченә алган аерым дәүләт “Идел-Урал штаты”н гамәлгә кертү комиссиясенең рәисе. Халыкара эксперименталь фонетика ассоциациясенең хакыйкый әгъзасы. Тел гыйлеменә, демографиягә, икътисади географиягә багышланган хезмәтләр, әдәби әсәрләр авторы. Үз чорында зур бәхәсләр тудырган алфавит үзгәртү мәсьәләләрендә актив катнаша. 1926 елның февраль-март айларында Баку шәһәрендә үткәрелгән I Бөтенсоюз корылтаенда сигез мәртәбә чыгыш ясый. Шул ук елны “Төрки халыклар өчен латин шрифты кабул итү мәсьәләсе турында” дигән махсус хезмәтен чыгара. Әлеге шартларда мөмкин дип уйлаган соңгы чараны кулланырга батырчылык итә – Сталинга хат яза. Анда телебез, әдәбиятыбыз, гомумән алганда татар мәдәнияте, татар милләтенең киләчәге турында сүз бара. Г. Шәрәфнең фикеренчә, гарәп алфавитын алыштыру төрки халыкларның мәдәни үсешен шактый елларга токтарлаячак.

Сөргеннән каты авырып кайтуына, торырга урыны булмауга карамастан, Г.Шәрәф “Зодчий” дигән поэмасын язып калдыра. Анда ул Иван Грозныйны һәм Иосиф Сталинны тәнкыйть утына тота. Г.Шәрәф балалар өчен дә күп шигырьләр язган, үзенең язмаларын “Гаенша бабай” исеменнән чыгарган.

*Шиһабетдин Шәрәф (1875-1939)* – Аксу авылында югары белемле мулла, мәдрәсә, мәктәп төзүдә башлап йөрүче. Олы сәясәткә, иҗтимагый-мәдәни тормышка турыдан-туры мөнәсәбәте булмаган, фәкать авылдагы крестьян хезмәте һәм вак сәүдә белән шөгыльләнгән Ш. Шәрәф тә һәлакәтле язмыштан котылып кала алмый. Аны да, кулак дип, мәдрәсә тәмамлаган дин әһеле дип, утызынчы еллар башында ук туган җиреннән сөрәләр. Ул да вакытсыз үлемен совет ГУЛАГының тимерчыбык киртәләре эчендә таба.

Гомумән алганда, Буа районы Аксу гомуми урта белем бирү мәктәбендә урнашкан музейда Шәрәфләр нәселе турында газета

материаллары, бик күп фоторәсемнәр, истәлекләр, шәхси документлар тупланган. Укучылар үз авылдашларын күреп, алар өчен горурлану хисләре кичерәләр. Бүгенге көндә тәрбия өлкәсендә төп юнәлеш булып торган туган якка мәхәббәт, патриотизм хисләрен тәрбияләү, туган телеңне хөрмәт итү, туган халкың, авылдашларың белән горурлану кебек сыйфатларны үстерү ягыннан карaганда, мәктәбебездә урнашкан бертуган Шәрәфләр нәселенә багышланган музейның роле гаять зур.

**Әдәбият**

1. Вәлиев Р. Фаҗига. – Казан, 1996.

# УЙГЫР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘГЕ ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫ

*Гулипали Паэрхати, КФУ, 2 курс магистранты*

*Фән. җит. – фил. фән. канд., доц. Мөгътәсимова Г.Р.*

Туганлык терминологиясе лексиканың иң борынгы катламнарына карый [2: 11]. Туганлык атамалары системасы халык тарихының бик борынгы чорында ук формалаша һәм, шуңа күрә дә, тарих өчен, тел тарихы өчен аеруча әһәмиятле лексик төркемне тәшкил итә. Туганлык-кардәшлек атамалары галимнәрнең игътибарын күптән җәлеп итеп килгән. Аларны төрле аспектларда өйрәнүгә багышланган хезмәтләр шактый күп. Төрки тел белемендә бу мәсьәләгә Н.П.Дыренкова, Л.П. Потапов, А.Н. Бернштам һәм башка галминәр хезмәтләрен багышлаганнар.

Уйгыр мәкальләрендә күзәтелгән туганлык атамаларын без берничә төркемчәгә бүлеп карадык. Алга таба мәкальләрдә урын алган кайбер кызыклы күзәтүләргә киңрәк тукталырбыз.

1) Кантуганлыкны белдерүче берәмлекләр. Кантуганлыкны белдерүче берәмлекләр уйгыр мәкальләрендә шактый урын алган. Кан буенча туганлык атамалары лексиканың иң борынгы катламын тәшкил итә.

Хатын-кыз белән бәйле түбәндәге туганлык атамалары кулланылганлыгы билгеле булды: ана, һәдә (апа), хотун (хатын), ани (әни), өгәй ана (үги ана).

Уйгырларда гаиләне башлап җибәрүче, гаилә башлыгы, ата – ир кеше булса да, аналарга багышланган мәкальләр күбрәк: *Туққан **ана** әмәс, бақған ана (Баланы тапкан түгел, баккан ана); **Ана** меһрини һеч ким билмә (Ана булу газабын беркем белмәс); Алтун башлиқ дадаң билән қалғичә, пахма башлиқ **анаң** билән қал (Алтын башлык ата белән калганчы, йонлач башлык ана белән кал); Кишиниң қушлиғинидин өз **анаңниң** мушлиғини яхши (Туган анаңның кыйнавы читләрнең иркәләвеннән яхшырак).*

Уйгыр халкында, бу балалар тәрбиясе белән күбрәк хатын-кыз шөгыльләнүгә бәйле булырга мөмкин.

Ана – төп номинатив терминнарның берсе. Ана берәмлеге борынгы төрки язма истәлекләрендә теркәлгән. Әлеге лексема гомумтөрки сүз фондына керә, чөнки барлык төрки телләрдә диярлек бар. Аерым алганда, татар телендә очрый.

Ата термины да мәкальләрдә киң кулланылган берәмлекләрнең берсе: ***Атиси** көрәлмигәнни балиси көрәр (Атасы күрмәгәнне улы күрер); Бир **ата** он балини беқип чидар, он бала бир **атини** еғирсинар (Бер ата ун баланы багар, ун балага бер ата да мәшәкать); **Атаңға***

*немә қилсаң, оглуңдин шуни көрәрсән (Атаңа нәрсә кылсаң, улың да сиңа шуны кылыр);* ***Атиси*** *көрәлмигәнни балиси көрәр (Әтисе күрмәгәнне улы күрер.);* ***Атиси*** *атмиған қоңғузни, балиси етипту тоңғузни (Әтисе белән коңгыз атмаганны, баласы дуңгыз атып үтерде).*

Ата термин борынгы һәм урта гасыр язма истәлекләренең күбесендә теркәлгән. Каракалпак, кыргыз, караим телләрендә ата – бабайны, ягъни әтинең әтисен аңлата. Төрек телендә эти мәгънәсендәге сүзгә баба лексемасы туры килә. Уйгыр мәкальләрендә ата сүзе кулланыла.

Моннан тыш, уйгыр мәкальләрендә ата-ана берәмлеге дә кулланыла: *Ачлиқтин өлсәңму,* ***ата-анаңни*** *ташлима (Ачлыктан үләрдәй булсаң да, ата-анаңны ташлама).*

Уйгыр халык мәкальләрендә һәдә (апа) лексемасы да күзәтелә: *Акаң кимни алса,* ***һәдән*** *шу (Абыең кемне алса, апаң шул).* һәм башкалар.

Апа сүзенең фонетик вариантлары төрки телләрдә әни, олы кан буенча кыз туганны, олы кыз җенесендәге туганны, әйтүчедән олырак булган олы абыйның кызын һ.б. аңлатырга мөмкин.

Әнинең яки этинең әнисен белдерер өчен уйгырлар moma берәмлегеннән файдалана. Ләкин кайбер җирлекләрдә эти ягыннан һәм әни ягыннан эти-әнине төрлечә атау бар. Ешрак әби этинең әнисе, дәү әни әнинең әнисе була. Уйгыр мәкальләрендә әлеге туганлык атамасын белдерә торган сүз күзәтелмәде.

Әтинең яки әнинең әтисен аңлата торган үзләр күп, бабай, дәү эти, картәтә, картәтәй һәм башкалар бар. Күпчелек төрки телләрдә, мәсәлән, төркмән, төрек, әзербайҗан, гагауз, кырым татарлары телендә баба – эти мәгънәсенә ия. Димәк, бер үк термин төрле телләрдә төрле мәгънәләрдә кулланылырга мөмкин икән. Уйгыр телендәге әлеге мәгънәне белдерә торган bova сүзе мәкальләрдә күзәтелми.

Уйгыр мәкальләрендә бали сүзе дә еш кулланыла: *Атиси көрәлмигәнни* ***балиси*** *көрәр (Әтисе күрмәгәнне баласы күрер); Атиси атмиған қоңғузни,* ***балиси*** *етипту тоңғузни (Әтисе коңгызны да тотмаган, ә баласы дуңгызны аткан);* ***Балини*** *туғмақ оңай, беқип чоң қилмақ тәс (Баланы табу җиңел, тәрбияләү авыр).*

Абый берәмлеге мәкальләрдә актив түгел. Уйгыр телендә *ака* сүзе кулланыла. Бары тик берничә мәкальдә генә күзәтелде: ***Ака-укиниң*** *азари болсиму, безәри болмас (Абый абыйны борчыр, әмма баш тартмас);* ***Акаң*** *кимни алса, һәдән шу (Абыен кемне алса, апаң шул).*

2) Никах туганлыгын аңлата торган атамалар Мәкальләрдә шулай ук никах туганлыгын аңлата торган атамалар да күзәтелде. Алар арасында хатын, ир, килен, кияү, җиңги һәм башка берәмлекләр бар.

Мәкальләрдә халык хатыннарның тышкы кыяфәтенә артык игътибар итми, әмма аларның хуҗалыкта бик яхшы эшләвен мактый. Хатыннарның эшчән һәм хуҗалыкны дөрес алып бара белүе турында уйгыр мәкальләре болай дип әйтә: *Өйдә **хотун** болмиса, боран чиқар (Өйдә хатын булмаса, буран чыгар); Әрниң етини чикарган – **хотун, хотунниң** етини чикарган – отун (Ирнең данын – хатыны, хатынның даны учак чыгарыр).*

Әлбәттә, уңай яктан тасвирлый торган мәкальләр бик мөһим. Аларда гаиләдә, аеруча хуҗалыкта хатынның әһәмияте турында сөйләнелә. Шулай ук хатын һәм балаларныэ булуы ирләргә төшкән җаваплылык дип карала: ***Аҗиз киши** өй бәхти, өй берикити (Хатын – өй бәхете, өй бәрәкәте); **Хотун киши** өйдә һәм хан, һәм хизмәткар (Өйдә хатын – хан да, хезмәткәр дә); Яхши **хотун** өйгә қозуқ (Яхшы хатын – өй тоткасы);*

Уйгыр мәдәнияте өчен иртәдән кичкә кадәр эш белән мәшгуль хатын-хуҗабикә образы хас: *Яхши **хотун** – өй берикити (Яхшы хатын өй бәрәкәте); Яхши **хотун** яман әрни әр қилар, яман хотун яхши әрни йәр қилар (Яхшы хатын яман ирне ир итәр, яман ахытн яхшы ирне җир итәр).*

Никах туганлыгын аңлата торган берәмлекләр арасында әр сүзе дә күзәтелде: *Хотун қанити – **әр, әр** қаннти – йәр.*

Уйгыр мәкальләре арасында қериндаш, туққан сүзе дә актив күзәтелә: *Көймигән **туққандин** ят яхши (Начар туганнан ят яхшы);Жирақтики **туққандин** янда хошнаң яхширақ (Ерактагы туганнан якын күршең мең якын); Вапасиз **қериндаштин**, вападар хошна яхши (Вафасыз туганнан өметле күрше яхшы)* һ.б.

Әлеге мәкальләр уйгыр халкына хас фикерне, тормышка һәм гаиләгә булган мөнәсәбәтне белдерә. Әгәр дә ул, халыкның менталитетына туры килмәгән булса, халык телендә озакка сакланып кала алмаган булыр иде.

Һәрбер халыкның үз юлы булырак формалашкан дөньяга карашы, менталитеты бар, күпчелек вакытта, әлеге халык шул менталитетка хас күренешләрне мәкаль итеп саклый.

**Әдәбият**

1. Мугтасимова Г.Р., Юсупова А.Ш. Этническая идентичность татарского народа по пословицам // Сохранение и развитие языков и культур в поликультурном и поликонфессиональном обществе: мировой опыт и современные технологии: материалы Международной

научно-практической конференции (Казань, 14-16 октября 2015 г.). – Казань: Изд-во Казан.ун-та, 2015. – С.127-129.

2. Покровская А.А. Термины родства в тюркских языках. // Историческое развитие лексики тюркских языков. – М.: Изд-во АН СССР, 1961. – С.11-81.

3. Хамраев М.К. Уйгурские пословицы и поговорки. – М.: Главная редакция восточной литературы. – 181 с.

# ПОРТРЕТ СОВРЕМЕННОГО ПЕДАГОГА ГЛАЗАМИ СОЦИУМА

*Гусева П., ТюмГу, студент II курса*
*Науч. рук.– док. филол. наук, проф. Файзуллина Г.Ч.*

Каждому человеку хочется произвести на социум хорошее впечатление. Такой эффект можно создать при помощи детально продуманного имиджа: элементов гардероба – одежды, аксессуаров, гармоничному сочетанию используемых цветов в образе, а также вербальной и невербальной коммуникаций. Педагогическая профессия напрямую связана с взаимодействием с людьми, поэтому специалистам этой сферы необходимо соблюдать определенные правила при подборе профессионального гардероба, который будет служить связующим компонентом во время коммуникации с людьми.

На протяжении нескольких веков научная сфера имиджелогии часто изучалась многими учеными такими, как: В.М. Шепелем, Э.Гоффманом, Г.Г. Почепцовым, В.А. Метаевой, А.Ю. Панасюком и др., но в основе каждой из трактовок лежат внешние и внутренние составляющие образа, а также его возможности влияния на окружающих людей.

Для реализации ожидаемого результата наглядных портретов современного педагога глазами учащихся и преподавателей, был проведен социологический опрос в сентябре 2023 года в учебных заведениях Тюменской области. В анкетировании приняли участие 247 человек, из которых: 16 преподавателей вуза, 98 учителей школ, 114 студентов высшего образования и 19 студентов среднего специального образования.

Из 247 человек, которые приняли участие в социологическом опросе, 56% являются молодые люди юношеской возрастной группы от 15 до 24 лет. 42% составили учителя и преподаватели, входящие в зрелую возрастную группу от 25 до 59 лет. Педагоги от 60 и старше лет, относящиеся к пожилой возрастной группе, составили 2%.

Респонденты анкетирования разделены по трем основным социальным статусам: 1) преподаватель – 6%; 2) учитель – 40%; 3) студент – 54%.

Социологический опрос состоит из 30 вопросов, которые разделены на три основных блока: первый – теоретический; второй проверяет уровень чувства стиля и комбинации предметов гардероба, а также правила их ношения; третий представляет собой психологическое восприятие, ассоциации и индивидуальные предпочтения цветовой палитры вещей.

Современная молодежь, по результатам анкетирования, видит современного педагога как экспериментатора своего стиля, который старается избегать постоянства и боится перемен. В своем профессиональном гардеробе он не применяет одежду синтетического материала, которая может вызвать дискомфорт при ношении, а также прослужить мало времени в использовании. Современному педагогу следует опираться на смешанный стиль, который и позволяет совмещать классические вещи с облегающими, разбавляя образ и предавая ему легкость и нотки элегантности. К юбкам есть определенные требования, касающиеся длины, и поэтому учащиеся считают, что подходящей является длина до колен. Сменная обувь в учебных заведениях обязательна, особенная для педагогов, которые являются примерами для своих учеников, такой обувью могут стать кроссовки или кеды. Украшения помогут дополнить образ, а также придать ему изюминку, но лишь при условии, что их будет не больше трех, а также гармонировать между собой. В своем профессиональном имидже прическа педагога должна быть удобной и незамысловатой, поэтому современная молодежь остановилась на варианте пучка или шишки. Отдельное место в образе учителей занимают макияж с маникюром, которые должны быть индивидуально подобраны, но при этом скромны и естественны. Идеальным вариантом длины ногтей является средняя, подчеркивающая женственность рук. Голос является рабочим средством педагогов, поэтому он должен быть хорошо поставлен, а также иметь тембр меццо, являющимся средним по громкости и скорости и мягким при звучании. Невербальное общение используется в работе учителя постоянно, особенно жесты, мимика и дистанции во время взаимодействия с детьми, поэтому необходимо ими владеть в совершенстве. Основными цветами имиджа педагога, по мнению современной молодежи, являются черный, белый и бежевый. Также можно включать оттенки красного и серого, но избегать желтого, который способен негативно влиять на психически нестабильных детей. Однако в основе имиджа современного педагога лежат его процессуальные качества, которые напрямую связаны с его профессиональными качествами и компетенциями. Такой портрет выстраивается на основе взглядов и мнений современной молодежи.

Сами педагоги видят свой профессиональный имидж следующим образом. Они отдают предпочтения сразу двум стилям одежды: классическому и смешанному. Один позволяет придерживаться строгости и правил, которые в некоторых ситуациях необходимы, а другой дает возможность для экспериментов со своим рабочим гардеробом, делая его более разнообразным. Опытные

педагоги пришли к выводу, что одежда из синтетического материала неудобна и не долгосрочна, из-за чего приходится часто менять вещи. В своей работе они также стараются не использовать облегающую одежду, отдавая предпочтения свободной и не сковывающей движения. Сменной обувью у педагогов в основном становятся туфли на небольшом каблуке, однако, в последнее время популярность набирают кеды или кроссовки, которые комфортны для долгой работы на ногах. Они дополняют и вносят изюминку в свои ежедневные рабочие образы с помощью украшений, которые по своему количеству не превышают трех и сочетаются между собой. Но в своих рядах могут иметь аксессуары с большими камнями, которые с некоторой одеждой лучше комбинируют. Большинство респондентов использует на работе прическу пучок, которая удобна и проста в собирании. Для завершения своего образа педагоги наносят макияж, отдавая предпочтения естественным цветам. За ухоженностью рук они также внимательно следят, делая маникюр средней длины с нюдовым покрытием, который делает руки более женственными. В своей профессии педагоги постоянно использует голос, который служит им хорошим помощником, поэтому они доводят навык его владением до совершенства, стараясь сделать его меццо-тембром. Также в своей работе они активно используют элементы невербального общения, а именно – жесты, мимику, пристальный взгляд и дистанцию во время коммуникации с людьми. В один ряд с цветами классического стиля педагоги ставят синий цвет, который схож с черным, однако, по их мнению, есть оттенки, которые нельзя использовать в преподавании. Например, зеленый и фиолетовый. Они также соглашаются с психологическим влиянием выбираемой цветовой палитры на себя и свое окружение. За основу своего профессионального имиджа они ставят процессуальные качества, которые будут полностью их отражать как профессионалов своей сферы деятельности.

Полученные результаты позволяют воссоздать наглядный портрет имидж современного педагога, опираясь на мнения студентов и преподавателей, которые отражают взгляды двух поколений разных времен. В получившихся образах есть как сходства, так и различия, позволяющие сделать вывод, что какие-то вещи остаются неизменными, а какие-то модернизируются и преобразовываются с учетом особенностей времени. Но одно остается постоянным – педагог является эталоном для подражания.

**Литература**

1. Гусева П.С. Профессиональный имидж: образ современного педагога // Занкиевские чтения: сборник тезисов докладов VII

Международной научно-практической конференции. – Киров, 2023. – С. 82-85.
2. Гусева П.С. Значение цвета в имидже современного педагога // Занкиевские чтения: сборник тезисов докладов VII Международной научно-практической конференции. – Киров, 2023. – С. 85-88.
3. Метаева В.М. Проблемы имиджелогии в современный период развития общества // Образование и наука. Известия РАО. – 2001. – № 6 (12). – С. 161-167.
4. Шепель В.М. Имиджелогия: учебное пособие // Народное образование. – М., 2002. – 254 с.

# ТЕКСТ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ПРОЦЕССЫНДА ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ

*Гыйлаҗетдинова Э., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Галиуллина Г.Р.*

Коммуникатив компетенция – барлык төр компетенцияләрне үз эченә алган туган телне укыту өчен иң мөһим корал. Аралашу компетенциясе үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы;

2) хәзерге татар әдәби теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын һәм сөйләмнең грамматик ягын дөрес үзләштерү;

3) бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен телдән һәм язма формада булдыру;

4) урта һәм өлкән сыйныф укучыларының кызыксыну даирәсен киңәйтү, туган телдә психологик һәм төрле аралашу ситуацияләренә бәйле рәвештә аралаша белүләренә ирешү, дәресләрдә үзләштергән белем һәм күнекмәләрдән нәтиҗәле итеп файдалана белү һ. б. [3: 83].

Танылган психолог А.А. Леонтьев фикеренчә: “Кешеләр арасындагы аралашу түбәндәге күнекмәләрне таләп итә: аралашу шартларына тиз һәм дөрес яраклаша белү, эзлекле сөйләшүне дөрес планлаштыру, аны билгеләү, эчтәлекне җиткерү өчен тиешле чаралар табу, аралашу процессында кире элемтә тәэмин итә белү мөмкинлеге. Һәм әгәр дә элемтә актындагы әлеге берәр пункт бозылса, аралашуда катнашучылар кирәкле нәтиҗәләргә ирешә алмаячак” [1: 33].

Аралашу осталыгына ия, интеллектуаль һәм иҗади үсеш алган шәхесне ничек формалаштырырга соң? Бу юнәлештә укучыларның иҗади потенциалын үстерү өчен мөһим шартларның берсе – текст белән эшләү, ул укучыларның сүз байлыгын тулыландыруны гарантияли һәм сөйләм сыйфатын яхшырта.

Дәрес барышында текст белән эшне оештыруның мондый ысуллары һәм формалары бар: текстны комплекслы анализлау; лингвистик текст анализы; төрле диктантлар; сочинение; текстны редакцияләү; интеллектуаль һәм лингвистик күнегүләр; мини-текстлар белән эшләү; синквейн, кластер алымнары; текст өчен концепция карталарын туплау; коммуникатив һәм уен ситуацияләрен чишү һ.б.

Мисал өчен, рус мәктәпләрендә татар төркемнәрендәге укучыларга “Әдәпле булу ни өчен кирәк?” дигән текст тәкъдим ителә [2: 85 – 86]. Биредә әдәплелек төшенчәсенең эчтәлеге шактый киң

ачыла: аралаша белү сыйфаты буларак, башкаларга игътибарлы булу сыйфаты буларак, ныклы режим белән яшәү һәм якыннарны кайгыртып яшәү сыйфаты буларак тасвирлама бирелә.

Текстның исемен анализлау – текстның темасы, максаты һәм эчтәлеге чикләре турында мәгълүмат алу өчен ачкыч, бу аны аңлау өчен алшарт. Мәсәлән, “Гади җөмлә” темасын өйрәнгәндә башта “Гади җөмлә ул нәрсә?” дигән сорауны бирергә мөмкин, аннан соң укучылар лингвистик чыганаклар белән эшлиләр. “Гади җөмлә” төшенчәсен билгеләү, аның төп үзенчәлекләрен ачыклау, укучыларның коммуникатив, информацион һәм лингвистик компетенцияләрен формалаштыруга ярдәм итүче төрле мәгълүмат чыганакларын кулланып башкарыла.

Текст грамоталылыгы укучыларны тексттан мәгълүмат алырга, аны иҗади кулланырга һәм үз фикерләрен белдереп, үзенчәлекле текстлар булдырырга өйрәтүне үз эченә ала. Татар теле дәресләрендә укучыларга үз текстларын булдыру өчен түбәндәге техниканы кулланырга мөмкин: лингвистик күренешне тексттан бетерү (мәсәлән, тексттан барлык сыйфатларны бетерегез һәм синонимнар белән алыштырыгыз); текстны киңәйтү (текстны тирәнтен аңларга ярдәм итә); текстны бүлгәләп карау (образлы чараларны ачыклау); сүзләрне һәм башка лингвистик берәмлекләрне тәртипкә китерү; текст компонентлары арасындагы бәйләнешне юк итү; бер үк текстның берничә автор редакцияләрендәге вариантларын чагыштыру.

Интеллектуаль һәм лингвистик күнегүләр башкару интеллектуаль һәм сөйләм үсешен тәэмин итә, чөнки бу күнегүләр ярдәмендә укучының бер үк вакытта интеллектуаль һәм лингвистик үсешен стимуллаштыра. Шулай ук, бу төр күнегүләрне башкару барышында сөйләм, игътибар, хәтер, уйлау сәләтләре үсә.

Ситуатив күнегүләр системасы – дәрес вакытында сөйләм мөмкинлекләрен булдыруның эффектив ысулы. Мәсәлән, укытучы укучылардан үзләрен берникадәр вакыт экскурсовод итеп күз алдына китерүләрен сорый: “Сез чит ил кешеләре өчен экскурсовод. Туган җирегезнең рәсемен кызыклы, җанлы, образлы һәм аңлаешлы итеп сурәтләргә тырышыгыз; туристлар арасында кызыксыну тудырырга тырышыгыз. Бу эшне кем яхшырак башкара ала?” Укытучы иң яхшы хикәя өчен конкурс игълан итә. Мондый эш төре билгеле бер сөйләм ситуациясен анализларга, язылган текстны адресатка җиткерергә, укучыны эффектив телдән аралашуга әзерләргә өйрәтә.

Татар теле дәресләрендә дидактик уеннар үткәрү шулай ук иҗади сәләтне үстерү ысулларының берсе: “Диктор” уенында, мәсәлән, текстның орфографиясен дөрес укырга кирәк; “Редактор” уены

текстагы сөйләм хаталарын төзәтүне үз эченә ала; “Тәрҗемәче” уенында текстны туган телдән рус теленә тәрҗемә итәргә кирәк. Текстка лингвистик анализ дәресләре укучыларга идеяне, сюжетны аңларга, автор кулланган сәнгать чараларын күрергә һәм аңларга ярдәм итә. Дәрес ахырында укучылар белемнәрен гомумиләштерәләр һәм лингвистик анализ осталыгын ничек кулланганнарын, текстның темасын һәм идеясен билгеләвен ачыклыйлар.

Текст белән эшләүнең күпкырлы табигате аркасында түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин: татар телен өйрәнү өчен уңай мотивация формалаштыру; укучыларның интеллектуаль осталыгын арттыру; белем бирү проблемаларын чишүгә иҗади караш формалаштыру; шулай ук укучыларның сөйләм үсешен һәм белем дәрәҗәсен камилләштерү, коммуникатив компетенция дәрәҗәсен күтәрү. Практика күрсәткәнчә, туган тел дәресләрендә текст белән системалы эшләгәндә белем сыйфатын күтәрү уңай тенденциясе күренә.

**Әдәбият**


1. Леонтьев А.А. Психологические проблемы массовой коммуникации. – М.: Наука, 1977. – 204 с.
2. Сәгъдиева Р.К., Харисова Г.Ф., Сабирҗанова Л.К., Нуриева М.Ә. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче с-ф. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2017. – 215 б.
3. Харисов Ф.Ф. Укучыларда компетенцияләр формалаштыру мәсьәләсе: лингвометодик аспект // Фәнни Татарстан. – Казан. – 2019. – №2. – Б. 81-87.

ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ ГАИЛӘ-НИКАХ ТРАДИЦИЯЛӘРЕН РЕПРЕЗЕНТАЦИЯЛӘҮ

*Гыйләҗетдинова Д., КФУ, 2 курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Мөгътәсимова Г.Р.*

Халык менталитетын чагылдыруда аеруча зур әһәмияткә ия булган берничә лексик-семантик төркем булуы мәгълүм. Шуларның берсенә гаилә, гаилә белән бәйле лексика, туганлык атамалары да керә.

Татар теленә *гаилә* сүзе гарәп теленнән кергән. Аның төп мәгънәсе – бергәләп яшәүче ир, хатын, балалар һәм якын туганнардан торган кешеләр төркеме, өй җәмагате.

Бер йортта гаилә булып яшәү – төрки халыклар вәкиле булган өйләнүче яшь егет өчен үз йортыңны булдыру, җәмгыятьнең аерым бер өлеше, ячейкасы булып китү, үз өеңдә торуны аңлата. Сүзнең эчке формасы («өй-ләнү») шуңа ишарә ясый.

Элек-электән гаилә тулы канлы тормыш итү һәм имин картлыкның бердәнбер формасы булып торган. Татарларда, башка төрки халыклардагы кебек, гаиләле булу хөрмәт ителгән, ә никахлашу зарури шарт кына түгел, мөселманнар өчен Ходай хакына башкарылучы изге гамәл дип тә саналган. Өйләнешүгә булган уңай мөнәсәбәт мәкальләрдә дә чагылыш тапкан:

*Өйләнү – көйләнү*;

*Өйләнми картайганнан акыл сорама;*

*Өйләнмәгән өйсез булыр, тормышы көйсез булыр*

*Өйләнмәгәннең тамыры корыр;*

*Өйләнү – җаныңа җавап, башыңа савап;*

*Өйләнү белән өй салуга Алла юнь бирә* һәм башкалар.

Татар халкы иртә өйләнүне хуплаган:

*Иртә торган белән иртә өйләнгән алданмас*

*Иртә торган – эшенә шатланган, иртә өйләнгән – балаларына*

Татар халкы өйләнгән кешенең тормышы жайга салына дип уйлаган. Татарлар яратып кына кияүгә чыгарга киңәш итәләр:

*Мәхәббәтсез семья — тамырсыз агач;*

*Ашны ачыкканга бир, кызны гашыйгына бир.*

Яшь кызга өйләнү үзләренең яшьлеге иллюзиясен тудырган:

*Яшь хатын яшәртә.*

Татар мәдәниятендә никахның кешеләр тормышында бик мөһим булуы әйтелә. Мәкальләрнең дөнья сурәтендә гаилә – бәхетле тормыш нигезе. Мәсәлән, *Семья – бәхет ачкычы.*

Кияү һәм килен турында да мәкальләр бар. Кияү һәм килен сайлауга караган киңәшләр тупланган аларда. Татарларда килен мондый була:

*Аш бул да таш бул!;*

*Балыкның – ике күзе, килennең бер күзе сукыр;*

*Килен кеше – ким кеше, Алабай белән тиң кеше;*

*Килен кеше – чит бавыр;*

*Килен килбәтсез була* һәм башкалар.

Татар халык мәкальләрендә кияүнең сыйфатлары турында болай язылган:

*Кияү – ат шикелле: караңгы товар;*

*Кияү – камчат бүрек;*

*Кияү – кеш тун;*

*Кияү көл астыннан;*

*Кияү каениш туфрагыннан;*

*Көзге көннең акылы – кияүләр акылы* һәм башкалар.

Лингвомәдәни җәмгыятьнең тупланган тәҗрибә турындагы күмәк күзаллавы түбәндәге киңәшләр һәм үгет-нәсихәтләрдә чагылыш таба:

1) Кыз сайлау турындагы мәкальләр:

*Авызында – теше, аркасында чәче булсын*

*Атны – тешеннән, кызны – күзеннән (сайлыйлар)*

*Аулак өйдә кыз сайлама, урак кырында сайла*

*Аягы сызлау булса кыз, тирәсеннән ерак сыз!*

*Зур авызлы кыздан саклан* һәм башкалар.

2) Кияү сайлау турындагы мәкальләр:

*Ат яхшысы тездән билгеле, егет яхшысы сүздән билгеле*

*Аязда яуган яңгырга ышанма, көлеп караган егеткә ышанма*

*Егетнең кашына карама, эшенә кара*

*Күзе сүнгән егеттән биз*

*Матур дип яратма, батыр дип ярат* һәм башкалар.

Кыз яки кияү сайлаганда, иҗтимагый фикергә колак салу да артык булмавы турында сөйли мәкальләр:

*Ана мактаганны алма, авыл мактаганнан калма*

*Ат алсаң, өең белән киңәш, хатын алсаң, авылың белән киңәш*

Кыз яки кияү сайлаганда, ата-аналарга да игътибар белән караганнар:

*Анасын карап кызын ал, кырыена карап бүзен ал*

*Анасына карап кызын коч*

*Анасына карап кызын коч, атасына карап улын коч*

*Анасы нинди, кызы шундый*

*Анасы яманның кызын алма, ишеге яманның өенә кермә*

Булачак хатынын сайлаганда, ир-егет туганнарының киңәшләрен колак салырга тиеш булган:

*Ат алсаң, авылың белән, кыз алсаң, кавемең белән.*

Гадәт буенча хатынны үз ыруында гына түгел, үз авылында да алмаска кушканнар:

*Ат алсаң, якыннан ал, хатын алсаң, ерактан ал*

*Ат белән кызны авылдан алма*

*Якыннан хатын алсаң, колагың каты булсын*

Шулай итеп, мәкальләр шактый тулы һәм дөрес итеп традицион татар җәмгыятендә булган гаилә партнерын сайлау проблемаларын чагылдыра Татарлар никахка җитди карыйлар. Үткәрелгән тикшеренү халыкның теле белән тормышны кабул итүе тыгыз бәйләнешен тагын бер тапкыр дәлилли.

**Әдәбият**


1. Замалетдинов Р.Р., Замалетдинова Г.Ф. О роли пословиц в исследовании национально-культурных особенностей языкового сознания // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. – 2010. – №2. – С.73-78.
2. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: 3 томда. II т. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 749 б.
3. Мугтасимова Г.Р., Юсупова А.Ш. Этническая идентичность татарского народа по пословицам // Сохранение и развитие языков и культур в поликультурном и поликонфессиональном обществе: мировой опыт и современные технологии: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 14-16 октября 2015 г.). – Казань: Изд-во Казан.ун-та, 2015. – С.127-129.

# А.ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ “ӨЧ АРШЫН ҖИР” ӘСӘРЕ ҺӘМ АНЫҢ ТӨРЕК ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ ТАТАР ХАЛКЫНА ХАС РУХИ КЫЙММӘТЛӘРНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Гыйләҗиева К., Казан, 127 нче мәктәп, XI сыйныйф*
*Фән. җит. – Гыйләҗиева А.Н.*

Татар халкын дөнья аренасына чыгаруда, татар халкы, мәдәнияте турында чит халыкларга мәгълүмат җиткерүдә татар әдипләренең әсәрләрен чит телләргә тәрҗемә итү күп нәтиҗәләр бирә. Шулай татарлар турында башка милләтләр беләләр, үз милли традицияләре, гореф-гадәтләре белән чагыштырып карыйлар, уртаклыкларны һәм аермалы якларны күрәләр.

Аяз Гыйләҗев әсәрләре дә рус, венгр, инглиз телләренә тәрҗемә ителү белән беррәттән, төрек галиме һәм тәрҗемәчесе Фатих Кутлу тарафыннан төрекчәгә тәрҗемә ителде. Элеге хезмәте белән Фатих Котлу төрекләргә татарларның уй-фикерләрен, кыйммәтләрен җиткерерү юнәлешендә зур эш башкарган. Үзара кардәш халыкларда уй-фикер, кыйммәтләр төшенчәләре моңа кадәр өйрәнелмәгәнлектән, теманы тикшерү минем өчен кызык булды.

Аяз Гыйләҗев – проза өлкәсендә дә, драматургиядә дә күп әсәрләр язып калдырган әдип. Аның әсәрләрен М. Хәбетдинова пропагандалый, өйрәнә, шулай ук Г.Сәгыйтова, Ф. Галимуллин, Ф. Латыйфи, Ф. Хатипов, Д. Гарифуллин һ.б.лар авторның үзенчәлекле стиле, жанры теле турында язалар, Э. Хәбибуллина әсәрләрнең төрек теленә тәрҗемәләрен өйрәнә.

А.Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” әсәре Ф. Кутлу тарафыннан төрек теленә “Bir avuç toprak “ дип бик уңышлы, яратып тәрҗемә ителгән. Автор фикерен тәрҗемәче сакларга тырышкан, төрле алымнар ярдәмендә төрек укучысына җиткергән. Әмма әсәрнең исеменнән үк күренгәнчә, автор белдерергә теләгән мәңгелеккә китү,соңгы нокта татарларда “өч аршын җир” – гүр яки 2 метр 13 см урынны аңлатса, төрекләр өчен шул ук төшенчә, руслардагы кебек, кешене күмгәндә кабергә сала торган 1 уч туфрак белән тасвирлана (горсть почвы). Бу исә әсәр исемендә үк ике халык менталитетындагы аерманы күрсәтә.

Аяз Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” повестенда Ватан, туган җир, тугрылык, бала, вөҗдан, тугрылу, бәхет кыйммәтләре сурәтләнә. Ләкин алар автор тарафыннан турыдан-туры шул сүзләрне кабатлап, тәкрарлап түгел, ә әсәр геройлары язмышы, аларның диалоглары, тормышы сурәтләнеше аша бирeләләр. Мәсәлән, “Өч аршын җир” повестенда Мирвәли кызу канлы һәм нык кеше буларак күз алдына килеп баса. Кызу канлыгы аңа һәм Шәмсегаянга бәхетсезлек китерсә,

ныклыгы көчле шәхес, иҗтимагый гаделсезлеккә үзенчә каршы чыгарга көч табарга булыша. Ул татарларга хас гаделлек өчен көрәш каһарманы итеп бирелә. Автор түбәндәге юлларда *нык, каты* сүзләре дә, *корычтай, таштай* дигән контекстуаль синоним булып килгән чагыштырулар белән автор кешенең сәламәтлеген ныклыгын күрсәтә. *"Ике кулын да сузган иде, аның* ***таштай нык тәненә, корычтай каты иңбашларына*** *кулы кагылгач, сискәнеп, ул ниятеннән кире кайтты*". Ә аның хатынын исә автор бәхетсез язмыш корбаны буларак тасвирлый. *"Дөрес, Шәмсегаян* ***авыр, фаҗигале*** *тормыш кичергән булса кирәк, аның* ***йөрәге таланган, искергән, көрәшергә көче*** *җитми, әмма ул аңа ярдәм итәргә тиеш!"*

Бала кыйммәте әсәрдә аеруча ачык чагыла. Автор аны төп герой мисалында тасвирлый. Аяз Гыйләҗевнең максаты – Шәмсегаянның балалары булмаганга борчылуы дәрәҗәсен күрсәтү. Моның өчен ул иң элек борлыгу диалекталь сүзенә мөрәҗәгать итә.

Ә төрек теленә тәрҗемәдә исә, тәрҗемәче бу кыйммәтләрне тасвирласа да, туры тәрҗемә һәм метафора, чагыштыруларсыз гына бирә алган. Мәсәлән, "*Bir tek,* ***çocukları*** *olmadı! Bunun için kendini suçlu gören Şemsigayan ızdırap içinde yaşadı."*

А.Гыйләҗев яшәү кыйммәтен, Аллаһ биргән иң кыйммәтле бүләк буларак күрсәтә, тормыш кыйммәтен үлемгә каршы куеп сурәтли. Мәсәлән, *"Авыл больницасында кечкенә генә хәбәр дә бик тиз урамга чыга: тәгәрмәч шиннары ашалып шомарган аксыл машина дулап капкадан кайтып кердеме, бел дә тор, менә бу юка пәрдәләр белән томаланган тәрәзәләр артында кемдер* ***явыз үлем белән тартыша****, кемнеңдер* ***язмышы үлчәү табасына куелган****..."* . Тәрҗемәче төрекчәдә дә моны саклап кала ала.

Тикшерү барышында нигез телдәге берәмлекләрнең төрекчәгә өч ысул белән тәрҗемә итү очракларына игътибар ителде: үзгәрешсез, башка берәмлек белән алыштыру, төшереп калдыру. Һәр ысулның да Ф. Кутлу тарафыннан еш кулланылышы билгеләнде. Үзгәрешсез бирелеш чыганак телдә бирелгән һәр берәмлекнең төрек телендә эквиваленты булу очракларына да карый (зәгыйфь, көчсез – zayıf ve güçsüz). Tekerlekleri aşınmış beyaz araba, avlu kapısından içeri gürültüyle girdi mi, bil ki bu ince perdelerle kapalı pencerelerine arkasında **kimisi ölümle pençeleşiyor, kimisinin de kaderi terazinin kefesine konuyor.**

Башка берәмлек белән алыштыру очраклары охшаш мәгънәне төрле сүз төркемнәренә караган сүзләр белән, нейтраль сүзне фразеологик берәмлек белән бирү вакытында күзәтелде: "*Дөнья, вакыт, чор төшенчәләре, заманның катлаулы язмышы, каты* ***көрәш-бәрелешләре*** *бу гашыйклардан читтә иде әлегә*!" "Dünya, vakit, hayat

mevhumları, zamanın ağırlığı, ***yaka paça mücadeleler,*** bu aşıklardan uzaktı henüz”.

Төшереп калдыру ысулы семантик яктан артыклыкка юл куймау максатларында кулланылуы ачыкланды. Мәсәлән, “*Гомере буе юатып түгел, кеше кайгыртып түгел, юанып, иркәләнеп яшәргә өйрәнгән Мирвәлигә болай бердәм рәвештә һәм ачыктан-ачык үзен үгәйсетүләре һәм санга сукмауларын күтәрү* ***бик авыр, үтә кыен*** *иде*”.“Hayati boyunca, teselli veren, başkaları için kaygılanan değil de avutularak, nazlanarak yaşamaya alışmış olan Mirveli için böyle birden bire hem de apaçık dışlanmak, adam yerine konmamak ***çok ağır*** **oldu**”.

Гомумиләштереп әйткәндә, А Гыйләҗев әсәрендә татарларга хас рухи кыйммәтләр кинаяле сөйләм, мәкальләр, һ.б. чаралар белән бирелә. Ф.Котлу да мондый чараларны тәрҗемәдә бирергә тырыша, ләкин күп очракта сүзнең туры беренчел мәгънәсе белән генә бирергә мәҗбүр була, мәкальне төшереп калдыра.

# С. ХӘКИМ ИҖАТЫНДА ФОЛЬКЛОР ОБРАЗЛАРЫНЫҢ ФУНКЦИЯСЕ

*Гыйльманова М., КФУ, соискатель*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Юсупова Н.М.*

XX гасыр татар поэзиясендә тирән эз калдырган классик шагыйрь С.Хәким иҗатының әһәмияте халыкчанлык белән характерлана. Тәлгат Галиуллин билгеләп үткәнчә, «халык иҗатына, халыкның фикерләү рәвешенә, характер үзенчәлекләренә якынлык С.Хәким шигырьләренең офыгын киңәйтә, яңгырашын бизи».

Иҗатының башлангыч чорында ук халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итә башлау шигырьләрдә тудырылган сурәтле дөньяга, образлар системасына һәм детальләргә дә тәэсир итә: С.Хәким шигъриятенә шомырт, ал таң, ак каеннар, чишмә, сандугачлар, моңсу таллар, әкияти табигать һ. б. образ-сурәтләр урнаша. Мисал өчен, Шагыйрь инде 1940 нчы елда ук язылган «Шагыйрьнең балачагы» поэмасында халык авыз иҗатыннан образлар кулланып Тукай образын, Тукай яшәгән тирәлекне ача. Ә инде соңрак, 1971 нче елда (30 елдан соң) язган «Кырыгынчы бүлмә» поэмасында Тукай образын, кабат фольклор мотивлары, образлары белән баета. Әсәрнең структурасында фольклор образлары (алтын тәхет, таҗ, ут, мәңге сихерле йорт , иске дөнья, сүнгән шәмнәр,сигез баскыч, казанда аш, әкияттәге төсле ак пароход, төне буе елаучы җилләр, ак күбеккә төшкән ат) кулланыла. Алар поэмага мифологик төсмер өсти, әсәрнең үтемлелеген, яңгырашын көчәйтә, поэманың сюжет-композициясен ачарга ярдәм итә.

Сибгать Хәким поэзиясендә мифик образлар: шүрәле, сихри көч, әфсен, карчык, карт, аксакал, Акбикә, Мөнкир-Нәкир,Хозыр Ильясны күрү дами күренеш. Авылда туып, авыл табигате, авыл кешеләре, вакыйгалары, балачак әкиятләре, ышану-юраулары белән яшәп, дөньяны танып белгән әдип шагырьләренә дә әкияти, мифик образларны кертә, вакыйгаларны тасвирлый. Бу образлар, бер яктан, шигырьләрдә билгеле бер мәгънә җиткерүгә хезмәт итә, икенче яктан, С.Хәким иҗатында милли лиризмны көчәйтә. Мисал өчен: «Шүрәле»(1960), «Юат син шуларны» (1961), «Карт»(1978), «Кырыгынчы бүлмә» (1971), «Әйтелмәгән васыят» (1979), «Бүген монда (1982) һ.б.

Фольклор әсәрләрендә саннар куллану һәрвакыт иътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, Өч, җиде,унбер санының кулланылышы борынгы мифларга барып тоташа. Борыңгы мифологидә төрки халыкларның күзаллавында дөнья өч катламнан – җир асты, җир өсте, күк өлешләреннән торган, өч – өс, оч мәгънәсендә булган дип аңлатыла.

Шуңа өч саны көч, үлемсезлек, батырлык символына әверелгән. Җиде саны да күкнең җиде катлы булуы белән бәйле дип фаразласак, халыкның ышанулары күп саннарга үз мәгънәсен салган һәм алар халык авыз иҗатында аеруча киң чагылыш тапкан. С.Хәким шигырьләрендә «бер», «өч», «җиде»,«унбер», «утыз өч», «кырык» саннары кабатлана. Автор бер генә чир, бер ишектән бер ишеккә, ике ара, ике стена, өч исем, өч гомер, сигез гасыр, сигез баскыч, утыз өч бүлмә һ.б сан-исем сүзтезмәләре аркылы фольклор традицияләренә мөрәҗәгать итеп, вакыйгалар барышын һәм хис-кичерешләрен күрсәтә, әсәрнең яңгырашын, үтемлелеген көчәйтә, серлелек төсмере өсти. Шулай ук унбер саны мифологиядә күк җисемнәре белән бәйле, мәсәлән,11 ай, 11 йолдыз,11бала һ.б. Сибгать Хәким поэзиясендә бу саннарга исәп мәгънәсеннән тыш яңа мәгънәләрләр салынган, һәм алар әсәр эчендәге вакыйгаларда бертөрле серлелек , тылсым, мифологик образ тудыру, сюжет барлыкка китерү үзенчәлеген хасил итәләр.

Без **өчәү,өчәү** янәшә:
Үлем,мин һәм талчыбык.
Селкенми,мин дә селкенмим,
Торам өнсез талчыгып.(1975)

Халык авыз иҗаты белән бәйләнешнең көчәюе, туган җир, туган нигез, ата-баба җире, туган туфрак, ватан, нәсел-ыру кебек милли яшәешкә бәйле төшенчәләргә игътибар арту 1960 еллардан С.Хәким әсәрләренә милли йола, гореф-гадәтләр белән бәйле образлар, сюжетларны алып керә. Аның әсәрләрендә аеруча Сабантуй образы, аңа бәйле күренешләр актив булуы күренә. Шагыйрь бу милли бәйрәмне татарның рухын саклаучы, авылның милли яшәеш терәге, һәркемне туган җиренә бәйләп торучы Олы Үзәк итеп күтәрә. Шагыйрь үзенең «Өч тал» (1975ел) «Монда халык судья» (1962ел)», «Англиягә барып кайт син» (1961ел) әсәрләрендә халык бәйрәменең үзенчәлекле, татар халкыныкы гына булуын данлый.

С.Хәким әсәрләре халык җырының яңгыраш һәм вәзен формаларын үзендә ныгыта: шигырьләрендә татар халык лирик җырларында 8/7 үлчәменең актив булуы күренә. Мисал өчен:

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем;
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем («Фазыл чишмәсе»).

С.Хәкимнең фольклор стилендә язылган шигырьләрендә татар халык җырларының үзенчәлекле структурасын күрергә мөмкин: 1-2 тезмәләртабигать күренешен тасвирласа, соңгы ике юлда лирик геройның кичерешләре бирелә.

Бакчабызда шомырт агачлары
Җәй буена сине көттеләр;
Син килмәдең, көзге җилләр инде
Яфракларын җиргә сиптеләр («Юксыну»)

Халык авыз иҗатыннан килгән образларны, мотивларны файдалану, поэтик алымнарны куллану С.Хәким иҗатында фольклор образларының функциясен билгели: шигъриятенең эчтәлек һәм форма ягыннан киңәюенә китерә, «фольклор стиле» яңаруын исбатлый.

**Әдәбият**

1. Галиуллин Т.Н. Сибгат Хәким поэзиясенең халык авыз иҗаты белән бәйләнеше // Совет әдәбияты. – 1964. – № 2. – Б. 129-135.

2. Йосыпова Н.М. С.Хәким иҗаты / Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 6. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 272-291.

3. Хәким С. Томанлы тәрәзәләр: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. – 479 б.

# CHATGPT: ВЗАИМОДЕЙСТВИЕ МЕЖДУ ИИ, КУЛЬТУРОЙ И ОБРАЗОВАНИЕМ В ЦИФРОВОЙ ЭПОХЕ

*Давлетшина Д., МБОУ «СОШ №5 г.Азнакаево» РТ, X класс*
*Науч. рук. – учитель английского языка Турсунова Н.Б.*

В настоящем информационном обществе технология играет ключевую роль в формировании культурных образов и общественных отношений. Одной из самых захватывающих инноваций в этом отношении стала технология ChatGPT, олицетворяющая последние достижения в области искусственного интеллекта. Ее приложение в чат-ботах, таких как ChatGPT, стало предметом широкого обсуждения в культурологическом контексте. Нельзя не отметить популярность нейросетей в России [3].

ChatGPT, разработанный компанией OpenAI, представляет собой модель искусственного интеллекта, обученную генерировать текст, отвечая на запросы и взаимодействуя с людьми в естественной беседе. Однако, большинство обсуждений этой технологии сосредотачивается на ее потенциальных воздействиях на культуру и общество в цифровую эпоху [5].

Взаимодействие между ChatGPT и культурой в цифровую эпоху представляет собой уникальное явление, которое требует серьезного анализа. Первоначально, следует отметить, что ChatGPT открывает новые горизонты коммуникации, пересматривая способы общения и взаимодействия в цифровом пространстве. Это вдохновляет множество специалистов из различных областей – от языковедов и философов до маркетологов и социологов – изучать, каково влияние такой технологии на культурные практики и обычаи. Такое влияние может проявиться через изменение способов общения, культурных представлений, а также поведенческих норм в цифровом обществе [2].

Следует также отметить, что ChatGPT может играть существенную роль в сохранении культурного наследия и многообразия в сети. Он предоставляет возможность обмена культурными знаниями и идеями между людьми различных культур и языков через барьеры и предрассудки.

Очевидна же и тесная связь культурного наследия и образования. Проблема влияния нейросетей на обучение является не однозначной. С одной стороны ChatGPT в образовании представляет собой инновационную и перспективную область, которая имеет потенциал изменить способы передачи знаний и обучения. Например, таких как:

- обучение языкам;

- создание образовательных материалов;
- индивидуальное обучение;
- помощь в сборе информации с интернета;
- помощь в написании эссе и сочинений;
- проверка на грамматические ошибки;
- создание и решение различных задач.

Хотя ChatGPT даёт множество потенциальных преимуществ в образовании и развитии, они также имеют свои недостатки. Следует отметить что частое применение нейросетей вызывает зависимость. Применение ChatGPTдаже в самых элементарных задачах приводит к деградации навыков критического мышления и решения проблем.

Не следует забывать и о том, что ИИ может проявлять ограниченную точность в обработке сложных вопросов или в предоставлении точной информации.

Большими недостатками применения ChatGPT в образовании являются отсутствие эмпатии и потеря индивидуальности при использовании нейросети для выполнения творческих заданий или работ.

В то же время, существуют опасения относительно потенциальных негативных влияний ChatGPT на культуру, таких как усиление культурной однородности, бесконечное циркулирование стереотипов.

Чтобы снизить негативное влияние внедрения нейросети в современное цифровое общество, следует учитывать несколько факторов:

- следует формулировать свой вопрос или задание четко и конкретно, чтобы уменьшить вероятность ошибочных или недостаточно информативных ответов;
- использовать ChatGPT не как единственный источник верной информации, а лишь как один из доступных вариантов;
- осуществлять проверку данных на грамматические или лексические ошибки, не следует полностью перекладывать ответственность на ИИ;
- использовать ChatGPT лишь для получении и сбора информации по конкретным темам или вопросам, а не для полного решения задачи, дабы не потерять индивидуальность.

В заключение можно сказать, что ChatGPT предоставляет широкие возможности для взаимодействия между ИИ и культурой в цифровую эпоху [1: 12]. Однако, необходимость постоянного анализа и регулирования воздействия такой технологии на общество и культуру

тоже безусловна. Только при условии баланса между инновациями и сохранением культурного разнообразия ChatGPT сможет полностью раскрыть свой потенциал в содействии развитию культурных общностей в цифровом мире.

**Литература**

1. Ивахненка Е.Н., Никольский В.С. ChatGPT в высшем образовании и науке: угроза или ценный ресурс? // Высшее образование в России. – 2023. –Т. 32. – №4. – С. 9-22.

2. Lund B., Ting W. Chatting about ChatGPT: How May AI and ChatGPT Impact Academia and Libraries? // Library Hi Tech News. January 2023. DOI: 10.2139/ssrn.4333415

3. Билык К., Популярность ChatGPT и Midjourney привела к росту пользователей нейросетей в России в пять раз // Rb.ru URL: https://rb.ru/news/populyarnost-neirosetey/ (дата обращения 17.11.2023)

4. Чулюков В.А., Дубов В.М. Искусственный интеллект и будущее образования // Современное педагогическое образование. 2020. №3. URL: https://cyberlelinka.ru/article/n/iskusstvennyy-intellekt-i-buduschee-obrazovaniya (дата обращения: 26.10.2023)

5. Ramos L., Marquez R., Rivas F. AI’s next frontier: The rise of ChatGPT and its implications on society, industry, and scientific research // Revista Ciencia e Ingenieria. 2023. Vol. 44. No. 2. P.131-148. URL: https://erevistas.saber.ula.ve/index.php/cienciaeingenieria/article/view/18872 (дата обращения 02.07.2023)

# ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕНДӘ ТЕЛӘК БЕЛДЕРҮ ФОРМАЛАРЫ

*Денмөхәммәтова А., Казан ш., 149 нчы лицей, VIII сыйныф*
*Фән.җит. – Хөснетдинова Р.Р.*

Без якыннарыбызга, дусларыбызга, танышларыбызга һәм, гомумән, беренче тапкыр гына күргән кешеләргә дә төрле теләкләр телибез. Һәркем көнен үз телендә хәерле иртә, хәерле көн теләүдән башлый. Ерак юлга чыкканда “хәерле юл”, “ак юллар”, авырганда тизрәк сәламәтләнергә, авыруның җиңел үтеп китүен телиләр. Болар көндәлек теләкләр. Моннан тыш һәр халык билгеле бер чарага нисбәтле якыннарына төрле котлау-теләк сүзләрен җиткерә. Алар һәр җәмгыятьтә бар, ләкин нинди максаттан әйтелүгә карап аерылалар һәм телдән яки язмача белдерелә алалар. Теләк формаларының күп һәм төрле булуы һәм төрле халыкларда төрлечә әйтелүе әлегә системалы рәвештә өйрәнелмәгәнлектән, аны тикшерү кирәк дип санала һәм ул эшнең актуальлеген билгели.

Тикшеренү эшенең объекты – татар һәм инглиз телләрендә теләк белдерү формалары, ә предметы – теләк белдерүдә кулланыла торган лексика.

Максатыбыз- татар һәм инглиз телләрендә теләк белдерүдә кулланыла торган уртак һәм аермалы якларны өйрәнү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1) Интернет сайтлардан теоретик материал белән танышу;
2) Татарча һәм инглизчә теләкләрнең үзенчәлекләрен ачыклау;
3) Татар һәм инглиз теләк текстларындагы аермалы якларны билгеләү.

Фәнни-тикшеренү эшенә чыганак буларак, төрле интернет сайтларда урын алган котлау-теләк текстлары сайланды.

Бу юнәлештә эшләгән галимнәрнең хезмәтләре шактый, Х. Курбатов, С.Поварисов, Х.Сәрьян, Ш.Асылгәрәев, А.Хәйруллина һәм башкаларның мәкаләләре билгеле.

Интернет сайтларда туган көн, юбилей, туй көне, бала туу, Яңа ел, төрле һөнәри бәйрәмнәргә бәйле 500дән артык материал бар. Бер-берсен теге яки бу бәйрәм белән котлаганда, бик күп теләкләр әйтелә. Татарча котлауларда һәм инглизчә белдерелгән котлауларда әйтелгән теләкләрне өйрәнгәннән соң түбәндәгеләр билгеле булды:

1) Татарлар бер-берсенә сәламәтлек, бәхет, озын гомер телиләр. Бу 3 теләк һәр котлауда яңгырый. Аларны чагыштырулар аша белдерергә яраталар: *корычтай нык сәламәтлек, шомырт чәчәгедәй ак*

*бәхетләр яки яңа яуган кардай ак бәхетләр, кояштай озын гомер* дип әйтәләр.

Инглиз текстларында да сәламәтлек, бәхет телиләр, ләкин чагыштырып әйтү очрамый.

«*I wish you happiness/ love/ success/ joy/ good health etc*», «*Сезгә бәхет, уңышлар, шатлык, мәхәббәт, яхшы сәламәтлек телим*.»

2) Туган көн котлауларында татарлар озын гомер яки 100 яшькәчә тыныч, матур, имин тормышта яшәүне телиләр. Һәрвакыт гаилә бәхете, дуслар күп булу, парлы булу, баларның яки оныкларның куанычын күрү турында белдерәләр.

Инглизләр туган көн белән котлаганда, «*Happy birthday*!» диләр.

Алар «*Best wishes on your birthday!*» – Туган көндә барлык изге теләкләр дип әйтәләр. «Many happy returns of the day!»– Озын гомер сорыйлар.

«Keep smiling on your birthday». – Туган көндә елмаюдан туктама диләр.

«May all your dreams come true!» — «Барлык хялларың тормышка ашсын дип әйтәләр.

Шулай ук «May your birthday give you the best memories till the next one!» — «Киләсе туган көнеңә кадәр бу туган көн матур хатирәләр калдырсын» дип телиләр.

*3)* Яңа ел яки инглизләрнең Крисмос бәйрәме хәзер ике халык өчен дә иң зур бәйрәмнәрнең берсе санала. Яңа елда татарлар: *аяз күк йөзе, илдә тынычлык, табыннарның мул булуын, барлык теләкләрнең тормышка ашуын, кайгы – хәсрәтләрнең иске елда калуын, һәр кешегә матди һәм рухи байлык телиләр.*

Инглизләрдә исә «*Let it bring you a peace of mind and a huge happiness*!» – Иртә тынычлык, ә бәйрәм бәхет китерсен!

«*I congratulate you on Christmas. In this holiday no one should be alone. Let today be with the ones who appreciate and love you. Also I wish your family happiness and success at work*!»

Мин сезне Раштуа белән котлыйм! Бу бәйрәмдә беркем дә ялгыз булырга тиеш түгел. Сезнең белән сезне хөрмәт итүчеләр һәм яратучылар булсын. Гаиләгезгә бәхет һәм эшегездә уңышлар телим кебек котлаулар актив булуы ачыкланды.

Шулай ук «*My success attend you!» / Һәр җирдә уңышлар булсын! «Keep well! Stay healthy!» / Сәламәт бул! «May all your dreams come true!»/ Хыялларың тормышка ашсын*! кебек теләкләр дә очрады.

4) Тикшерү барышында бәйрәмнәрдә татарлар да, инглизләр дә бары яхшы теләкләр генә теләүләре ачыкланды. Соңгы елларда татарлар котлау текстларын шигырь белән белдерергә яратсалар,

инглизләр исә кыска, әмма аңлаешлы сүзләр белән тәбрикләү сүзләрен белдерәләр. Алар өчен бәхет, шатлык, байлыкта яшәү мөһимлеге билгеле булды.

Татар халкы теләк теләгәндә дини мотивларны да кушарга ярата. Теләкләрдә «*Алла ярдәменнән ташламасын, Ходайның яраткан бәндәсе булырга язсын, ике дөнья бәхетен күрергә язсын*» кебек сүзләр дә еш очрый.

Гомумиләштереп әйткәндә, татарлар да, инглизләр дә бары изге теләкләр генә телиләр, аларны үз халкына якын булганча белдерәләр, тирә-юньдәгеләргә ешрак әйтергә тырышалар.

# АЛМАШЛЫКЛАРДАН ЯСАЛГАН САФ КУШМА СҮЗЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮНЕҢ ЛИНГВОМЕТОДИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Җәмалова Л., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәлахова Р.Р.*

Кайсы гына телне алсак та, ул телдә шикле һәм бәхәс тудыра торган мәсьәләләр була. Теоретик яктан бу проблемалар аерым өйрәнелгән булса да, методик яктан тиешле игътибар җитенкерәмәү сәбәпле, мәктәп укучыларында сораулар тудырырга мөмкин. Татар телендә шундый темаларның берсе – кушма сүзләр. Мәгълүм булганча, кушма сүз ике яки аннан да күбрәк тамыр кушылып, бердәм лексик мәгънәгә ия булган яңа сүзләр. Сүзләр кушылу бик борынгы күренеш булып тора. Белгечләр фикеренчә, композитлар праславян, борынгы төрки, гомумалтай, шумер телләрендә үк күзәтелгәннәр. Мәсәлән, “Котадгу белек” хезмәтендә генә дә 2830 кушма сүз кулланылуы билгеле. Тюркологиядә дә, татар тел гыйлемендә дә кушма сүзләргә фәнни игътибар күптәннән килә. Тюркологиядә кушма сүзләрне өйрәнүнең борынгы тарихы бар. Ф. Таһирова фикеренчә, мондый төр сүзләр турында мәгълүмат 1680 нче елда төзелгән Менниниский грамматикасында ук бирелә.

Тюркология буенча язылган хезмәтләрдән кушма сүзләрне өйрәнүгә багышланган А. Казембек, Н.Ф. Катанов, В.А. Гордлевский, В.М. Насилов, Р. Бердыев, А.А. Юлдашев кебек һ.б. күп кенә галимнәрнең эшләрен атарга мөмкин.

Татар телендә Каюм Насыйри, Галимҗан Ибраһимов, Гыйбад Алпаров һ.б. үз заманнарында кушма сүзләрне барларга, үзенчәлекле якларын ачыкларга омтыла. Бу юнәлештә, тулы-тәфсилле хезмәләрдән Г. Ибраһимовның 1917 нче елда басылып чыккан “Татар сарыфы”н атарга мөмкин. Галим сүз төркемнәренең ясалыш юлларын төркемләү барышында кушма сүзләрнең үзенчәлекле бүленешен тәкъдим итә. Татар грамматикасында кушма сүзләрне фәнни яктан өйрәнүдә Д. Тумашева [2: 117], Ф. Ганиев хезмәтләре аеруча игътибарга лаек. Байтак материал туплану, кушма сүзләрнең төзек системасын булдыруга ирешү яңа заманда кушма сүзләрне яңа яссылыкта, әйтик Л.М. Чурилова [3: 152] кебек когнитив яссылыкта, башка телләр белән чагыштырма аспектта өйрәнү өчен шартлар тудыра.

Әмма Ф.Ә. Ганиев ассызыклаганча, бу хезмәтләрнең барысында да кушма сүзләргә караган төпле мәгълүмат бирелгән дигән сүз түгел. “Ни өчен бу тема һаман да зур кызыксыну белән бергә тирәнтен өйрәнелә алмый?” дигән сорау тарихи яссылыкта өйрәнелү дәрәҗәсен тикшерүне таләп итә. Кушма сүзләрнең тиешле дәрәҗәдә

өйрәнелмәвенең сәбәбе буларак галим телләрне агглютинатив дип санап, аналитизм чагылыш тапкан аспектларга фәнни карамауны атый. Татар теле мисалында Ф.Ә. Ганиевның фикере болайрак яңгырый: “фактлар күрсәткәнчә, татар теле системасы һәм структурасында аналитиклык агглютинативлык кебек үк әһәмиятле роль уйный. Төрки телләрдәге аналитиклык аларның грамматик һәм сүз ясалышы системасында үтәли күренә. Төрки телләрнең аналитик төзелешен исәпкә алмаган очракта, аларның грамматик һәм сүзьясалыш структурасын аңлап һәм аңлатып булмый”.

Ф.Ә. Ганиев билгеләвенчә, “Кайвакыт кушма сүзнең ничек ясалганын билгеләве бик кыен була: сүзләр кушылу ысулы белән ясалганмы, әллә сүзтезмәнең кушма сүзгә күченнән барлыкка килгәнме” [1: 25].

Татар сүз ясалышында шактый продуктив ысулларның берсе булып сүзтезмәләрнең кушма сүзгә сүзгә күчү һәм сүзтезмәләрнең кушымча алып кушма сүзгә күчү юлы белән саф кушма берәмлек хасил итүләре тора. Гадәттә бу ысул белән калькалаштырылган сүзләр ясала. Без алмашлыклар нигезендә әлеге ысулллар белән ясалган кушма рәвешләргә тукталдык, чөнки аналитик сүзләрнең нәкъ менә шушы төре укыту барышында укучыларда төрле сораулар тудыра.

Алмашлык+исем: *һәрвакыт, һәрчак, һәрвакыт, һәрьяк.*

Алмашлык +бәйлек: *үзара;*

Алмашлык + *алмашлык: кайвакыт, шулчак, шулвакыт;*

Алмашлык + урын вакыт килеше кушымчалы исем: *һәрчакта, һәрхәлдә, һәрьякта, кайвакытта, кайчакта, шулчакта, шулвакытта;*

Алмашлык + чыгыш килешендәге исем: *һәрьяктан, шулуңайдан.*

Алмашлык + бәйлек: *шулкадәр, шулчаклы, шулкадәрле, никадәр, ничаклы*;

Алмашлык + рәвеш: *нибары, нибарысы, һәрдаим*;

Алмашлык +алмашлык: *һәркайда, һәрничек, һәркая.*

Мисаллардан күренгәнчә, әлеге саф кушма рәвешләрнең ясалу ысуллары да билгеле, ясалыш тибы һәм моделе дә мәгълүм, әмма аларның төзелеш-язылыш үзенчәлекләре, кайсы сүз төркеменә каравын билгеләү укучыларда шактый зур кыенлыклар тудыра.

Беренчедән, мондый төр кушма рәвешләрне укучылар я бөтенләй сүзтезмә итеп билгелиләр, яисә саф кушма исем дип күрсәтәләр, чөнки икенче компонент исемгә тәмамланган, өстәвенә аңа килеш кушымчасы да ялганган (*һәрьяктан* “отовсюду”, *шулуңайдан* “заодно”). Шул сәбәпле, кушма сүзләрне өйрәнгәндә саф кушма исемнәр белән генә чикләнмичә, башка сүз төркемнәрен дә, аеруча телдә шактый актив кулланылган алмашлыклар нигезендә ясалган

рәвешләрне дә җентекләп өйрәнү юлларын, аларны сүзтезмәләрдән яки башка кушма сүзләрдән аеру критерийларын табу мөһим. Бу алымнар кушма сүзләрнең төзелешенә генә түгел, аларның семантикасына да, шуңа бәйле рәвештә, дөрес язылышына да төшендерергә сәләтле булырга тиеш, чөнки саф кушма сүзләрнең контексттагы мәгънәләре белән хисаплашмау, бу төр кушма сүзләрне аерым язып хата ясауга да китерә. Фәнни хезмәтебездә без әлеге проблеманың лингвометодик нигезләрен өйрәнәбез, төрле методик алымнар тәкъдим итү юнәлешендә эшлибез. Тикшеренүебез нәтиҗәләре мәктәптә кушма сүзләрне өйрәнгәндә килеп туган бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү юлында ныклы бер адым булыр дип ышанабыз.

**Әдәбият**


1. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. – Казан: Мәгариф, 2006. – 271 б.
2. Тумашева Д.Г. Хәзерге татар теле морфологиясе. – Казан: КДУ нәшр., 1964. – 300 б.
3. Чурилова Л.М. Лингвокреативные механизмы метафорических субстантивных композитов в английском и татарском языках: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2006. – 191 с.

# ТАТАРСТАН ВОЛЕЙБОЛ СПОРТ КОММЕНТАТОРЛАРЫ СӨЙЛӘМЕНЕҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Заһретдинова А., Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм университеты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Мотигуллина Ә.Р.*

Хәзерге заман телевидениесе барлык таләпләргә җавап бирүче массакүләм мәгълүмат чарасы гына түгел, ә милли-мәдәни барышны чагылдыручы үзәк булып тора. Мәгълүм булганча, тележурналистикада спорт матчларына бәя бирү аерым игътибарга лаек. Бу очракта тележурналист ролен спорт телекомментаторы үти башлый. Аларның вазифасы – үзе күргәннәрне күрсәтеп, аңлатып бару, телеэкран каршындагы җанатарларны үзе артыннан ияртү. Шуңа күрә спорт комментатары сөйләменә аерым таләпләр куела: ачык, төгәл, мәгълүматлы, теленең сыгылмалы булуы шарт.

Татарстан Республикасының телеканалларында тапшырулар ике дәүләт телендә, ягъни рус һәм татар телләрендә алып барыла. Шуңа күрә Татарстан Республикасы телеканалларының мәгълүмати программаларында сөйләм ике яклы йогынтыга дучар ителә: беренчедәндән, тел-сөйләм кагыйдәләрен саклау, икенчедән, стилистик таләпләрнең үтәлүе.

Әлеге тикшеренү эшенең **максаты** хәзерге Татарстан телевидениесе аша күрсәтелә торган тапшырулардагы спорт комментаторлары сөйләменең лексик-тематик, семантик үзенчәлекләрен бәяләү.

Спорт – кеше тормышының мөһим өлешенә әверелде. Спорт уеннары, чаралар барлык илләрнең җанатарларын берләштерә. Шуңа күрә ярышларны сыйфатлы яктырту мәсьәләсе спорт комментаторларының тел материалын төгәл файдалана белүен һәм репортажлар вакытында журналистның мәсьәләне яктырта алуы белән бәйле.

Телетапшыруларның нигезенә салынган материалларда спорт комментарийларына куелган таләпләрне ачыклап китик.

Комментаторлар сөйләменең дөрес һәм ачык булуы шарт. Әлеге таләп үтәлмәсә, киң җәмәгатьчелекнең спорт чараларын бәяләүләргә кызыксынуы кими. Бу гамәлдәге тел-сөйләм калыпларыннан читләшкән вакытта, сүзләрне урынлы һәм үтемле кулланмаган очракта күзәтелә. Татар теле лексикасы составындагы жаргон, арго сүзләрне куллану, бигрәк тә сирәк кулланыла торган, киң таралмаган булса, шундый ук кыенлык тудыра. Шулай итеп, сөйләмнең ачыклыгы аның төп сыйфатларыннан берсе булып тора.

Комментатар теленә хас төгәллек һәм ачыклык сөйләм культурасында да чагылыш таба. (төгәллек төрле чаралар белән тормышка ашырыла). Төрле тикшеренүчеләр сөйләмнең чынбарлыкка туры килүе һәм тел нормаларының үтәлүе кебек төгәллек сыйфатларына игътибар итәләр.

Телекомментатор сөйләмендә шулай ук сүз, сурәт һәм тавыш та әһәмиятле. Телевизион сөйләмнең стилистик үзенчәлекләре, беренче чиратта, күпсанлы аудиториягә мөрәҗәгать итү вакытында сүз сөрешенә, җөмләләрне урнаштыру тәртибенә дә бәйле. Бу телнең сафлыгына, аңлаешлы булына омтылу, әдәби сөйләмгә якынайту тенденциясенә бәйле.

Спорт уеннарын күзәтеп бару барышында телекомментаторлар вакыйгаларны күзәтеп кенә калмыйча, ә үз мөнәсәбәтләрен дә белдереп барырга тиеш. Аларның күзәтүче буларак бирелгән бәясе, комментарийлары җанатарлар арасында тиз арада танылуына китерә. Нәкъ менә җанатарлар спорт журналистлары эшенең төп рецензентлары булып тора. Шуңа күрә спорт комментаторлары сөйләменең ачык, аңлаешлы булуы әһәмиятле.

Спорт комментаторлары вакыйгаларны төрле тел-сурәтләү чараларын кулланып тасвирлыйлар. Мәсәлән, алдагы чараларны еш кулланалар: сәнгатьчә сурәтләү чаралары (метафора, эпитет, синекдоха, чагыштыру, гипербола, литота, перифраз һ.б.), төрле стилистик фугуралар (кабатлаулар, каламбур һ.б.) һәм төрле образлы сурәт тудыру чараларын да читләтеп узмыйлар.

Спортның киң таралган уен төре – волейболны алыйк. Волейбол матчына бәя бирү телевизион репортаж жанрларына карый. Аның иң мөһим билгеләре булып түбәндәгеләр тора: комментаторның тел-сөйләм үзенчәлекләре, репортаж кысаларында кулланылган репортерның сүз осталыгы, тел байлыгы, аның сыгылмалылыгы. Волейбол репортажы түбәндәге үзенчәлекләргә ия: тематик төрлелек (төп вакыйга), комментаторның уен барышына биргән бәясенең стилистик төзеклеге, әдәби тел нормаларын саклавы һәм төгәл репортаж композициясен саклап калуы. Фикерне рус комментаторларының тел-сөйләм үзенчәлекләреннән башлыйк. Әйтик, волейбол комментаторлары Андрей Адамов, Владимир Мерзляков уен барышындагы репортажларында эпитетларга еш мөрәҗәгать итәләр: *“...**Отличная** передача, **быстрая** в край, реакция в третьей зоне с одиночным блоком...”* (“...Бик әйбәт передача, зур тизлектә бер якка килеп төште, өченче зонада тиз реакция күрсәтү нәтиҗәсендә берүзе блок куйды...*”), “...От блока в аут, **отличный** удар, **технически исполненный**, мяч улетает на сторону «Факела» за пределы*

*площадки,* ***классная*** *передача****,*** ***очень удобная*** *леворукому..."* ("...Блоктан аутка килеп төште, бик әйбәт удар (сугу), техник яктан яхшы башкарылган, туп көндәш "Факел" командасының аутына килеп төшә, передача әйбәт, сулагай кеше өчен уңайлы передача...") [5]. Мондый эпитетлар, бер яктан, матчның мөһимлеген күрсәтә, ә икенче яктан, бу сүзләрнең еш кулланышына басым ясап, уен барышының ни дәрәҗәдә тизлеген һәм уенчыларның һөнәри осталыгын ассызыклый.

Телекомментатарның теле метафораларга да бай була. Спорт уены барышында фикерен тагын да үтемлерәк һәм төгәлрәк җиткерү максатыннан: *"...Даже с таким ростом он представляет большую угрозу для любой команды..."* ("... Хәтта шундый буе белән дә ул һәркайсы көндәш командага зур куркыныч тудыра...") [2].

Уен барышында, комментатор Алексей Осин җанландыру алымын да читләшеп узмый: "*Сам же подаёт,* ***отправляет*** *мяч в сетку" (*"...Үзе подача бирә, тупны сеткага җибәрә..."), *"...Мяч отправляется в самый дальный уголок площадки...",* (..."Туп площадканың иң ерак почмагына оча...") [2].

Спорт комментатарлары сөйләменә хас тагын бер стилистик үзенчәлек – хезитация. Әлеге күренешне комментатор Дмитрий Рыбьяков сөйләмендә күзәтәбез: "*...У Сурмачевского не получается атака, пальцами попадает по мячу, мяч далеко в аут улетает, и... 2:1 Югра-Самотлор вперёд выходит...*" ("... Сурмачевский көндәш команданы һөҗүм итә алмый, туп еракка аутка оча, һәм... 2:1 Югра-Самотлор алга чыга...") [6]. Әлеге комментаторның осталыгын күрсәтүче тагын бер дәлил – ул уен барышыда тиешле пауза ясый белү белән дә бәйле. Бу да спорт комментатары сөйләмендәге лексик-семантик күренеш буларак бәяләнә.

Тагын бер лексик-сурәтләү алымының метафора мисалына тукталыйк. Хәзерге вакытта «Зенит-Казан» волейбол командасы уеннарын, күпчелек очракта, яшь спорт комментаторлары алып бара. Шулай ук аларның сөйләм телләрендә дә билгеле бер үзенчәлек бар. Мәсәлән, Дмитрий Лосев «Зенит-Казан» һәм «Динамо-Мәскәү» уенын алып барганда, шул уенны бәяләп: "*...Первая подача была от Семышева и...первое очко соответственно набирает московская команда в этой игре..."* ("...Беренче подача Семышевныкы иде һәм... әлеге уенда беренче очконы Мәскәү командасы яулап ала", - дип, очко яулап алганны әйтә).

Заманча волейбол матчларын бәяләүне җанландыру (сынландыру) алымыннан башка күз алдына китереп булмый. "*...Если не получилось у Михайлова, то нашли выход переводом...и поляк все-таки пробиваепт оборону очень крепкую..."* ("...Михайловның килеп

чыкмаса да, шулай да поляк чыгу юлларын барыбер таба һәм көчле оборонаны “җимереп” чыга...”) [7]. Элеге мисалда комментатор тамашачыга «Зенит-Казан» командасының, авыр булуына карамастан, очко яулаганын әйтә. Безнең уенчыларның көчле уеннарын күреп, телекомментатор *“пробивает оборону”* сүзтезмәсен җанландыру чарасы буларак куллана.

Спорт комментаторлары Андрей Адамов, Владимир Мерзляков «Зенит-Казан» һәм «Факел» уеннарын алып бару дәвамында җанландыруны һәм эпитетларны кулланалар: *“...Нельзя не отметить этого французского доигровщика, лидера* ***европейского волейбола****, на своей позиции* ***отлично видит площадку*** *соперника, обладает* ***классной техникой****...”* (“...Әлеге француз уенчысы турында әйтмичә китеп булмый, Европа волейболының лидеры, үзенең позициясеннән көндәш команданың площадкасын бик яхшы күрә, уен ягыннан техникасы да бик әйбәт...”) [5].

Шул рәвешле, әлеге теманы ачу барышында түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1) хәзерге вакытта Татарстанда зур үсеш алган юнәлешләрнең берсе – спорт санала. Волейбол трансляцияләре Татарстан телевидениясендә күрсәтелә. Шуңа күрә спорт комментаторының лексик-стилистик үзенчәлекләренә зур игътибар бирелә. Аларның төп бурычларының берсе – сөйләм төгәллеген һәм ачыклыгын саклап калу;

2) Волейболда гына түгел, ә һәр спорт төрендә спорт комментаторларның уенны күзәтүе, бәяләве төгәл сүз таба белүгә, тел-стиль чараларын урынлы куллана белүенә нигезләнә;

3) спорт комментатторлары – сөйләмнәрендә сүз белән сурәт ясауның төрле тел чараларын кулланалар, аеруча лексик сурәтләү чараларыннан метафора, эпитет, җанландыру, фразеологизмнарны куллануга өстенлек бирәләр;

4) уен барышын игътибар белән күзәтеп барган телекомментатор күргәннәрен сөйләү белән беррәттән, шәхси тәҗрибәсенә таянып, төрле вакыйгаларны искә төшерә, аларны уенчыларның казанышлары белән бәйли. Шул рәвешле җанатарларның да ышанычын яулый.

**Әдәбият**

1. Борытко, А.Н. К вопросу о терминологической ясности речи спортивного комментатора: экспериментальное исследование // Изв. Волгогр. гос. пед. ун-та. Сер.: Филол. науки. – 2012. – № 8 (72). – С. 19–23.

2. Зиянгиров, Э.К. Тропы и стилистические фигуры в речи спортивных комментаторов [Электронный ресурс] // Современные

проблемы науки и образования. 2015. № 2. Ч. 2. URL: http://bit.ly/2K7ExF4. Дата обращения: 15.03.2023.
3. https://www.youtube.com/watch?v=k2A3Dcc6P5Y&t=1704s
4. https://www.youtube.com/watch?v=Vc8rkKpiYwQ&t=440s
5. https://www.youtube.com/watch?v=vY_mzA6cxsE&t=531s

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИЯТАРА БӘЙЛӘНЕШ КҮНЕКМӘЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘҮ АЛЫМНАРЫ

*Зиатдинова Д., КФУ, IV курс студенты*
*Фәнни җит.. – филол. фән. канд., доц. Сибгаева Ф.Р.*

Мәдәниятләр диалогын төзү, сөйләм этикеты модельләрен саклап, теге яки бу илнең үзенчәлекләрен белеп һәм хөрмәт итеп аралашудан башка уңышлы була алмый. Үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен һәм сөйләм тәртибенә кагылышлы билгеләнгән стандартларны үтәмичә озак перспективалы мәдәни багланышларны төзү мөмкин түгел.

Туган мәдәниятне белмичә, аңа мөрәҗәгать итмичә, башка җәмгыять телен һәм мәдәниятен өйрәнү мөмкин түгел. Чит мәдәният, үз мәдәниятең белән чагыштыру аша таныла. Гамәлдә, өйрәнә торган тел белән бергә, халкының мәдәни үзенчәлекләрен дә өйрәнер өчен, туган мәдәният фон буларак кулланыла.

Укучылар арасында мәдәниятара бәйләнеш күнекмәләре җитәрлек дәрәҗәдә формалашмавының бер сәбәбе булып «мәдәниятләр киселеше» нең мәдәниятара коммуникация практикасы буларак тормышка ашырылмавы тора, бу уку процессында телнең бөтен функциональ әһәмиятен тормышка ашырмауга китерә.

Телне һәм мәдәниятне өйрәнү процессында шуны аңлау мөһим: туган һәм өйрәнелгән мәдәниятләрне чагыштырганда, чит мәдәният призмасы аша үз мәдәниятен яңадан бәяләү бара.

Е.Г.Тарева билгеләп үткәнчә, аң формалаштыру һәм аңа бәйле рәвештә теге яки бу сөйләм стратегиясен актуальләштерү гомумән коммуникациянең уңышлылыгын билгели һәм шәхеснең формалашуына һәм мөһим сыйфатларның үсешенә китерә: толерантлык, эмпатия һәм кабул итү, үз чиратында, мәдәниятара аралашуны уңышлы тормышка ашыру өчен күпмәдәни шәхес тәрбияләүгә китерә [3].

Хәзерге җәмгыятьтә тел белеме бирүнең төп максатларының берсе – бәйләнеш күнекмәләре формалаштыру. Бу, телне чын мәдәниятара бәйләнеш ситуацияләрендә куллануга юнәлдерелгән.

Теоретик, фәнни һәм методик әдәбиятны өйрәнү һәм анализлау, төп проблема – халыкларның мәдәни аермаларын, аларның дөньяга карашын, менталитетын аңлау максатыннан мәдәниятара коммуникацияне өйрәнү дигән нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирде. Шуңа бәйле рәвештә, укучыларның «дөньяның тел картинасын» белүе һәм аңлавы мөһим әһәмияткә ия дигән нәтиҗә ясарга була. Билгеле булганча, дөньяның тел картинасы җәмгыятьтә кешеләрнең белемнәрен берләштерүгә, гомумән, аларның тыгыз бәйләнешенә

ярдәм итә һәм һәм җәмгыятьтә кешеләрне интеграцияләүнең нәтиҗәле чарасы булып тора.

Мәдәниятара коммуникатив компетенция, күпкырлы һәм күп компонентлы төшенчә, үз эченә белем, күнекмәләр, мөнәсәбәтләр һәм кыйммәтләрнең бай системасын ала. Коммуникатив компетенциянең төп компонентлары түбәндәгеләр: 1) лингвистик, 2) социолингвистик, 3) дискурсив, 4) стратегик, 5) социомәдәни, 6) социаль [2].

Мәктәп укучыларында социолингвистик күнекмә формалаштыру, билгеле бер коммуникатив ситуациягә ярашлы рәвештә аралашу сәләтен үстерүне күздә тота. Бу максатта, көн үзәгендә булган темаларны үз эченә алган далогларлар өйрәнүне кулланырга мөмкин.

Рус телле укучыларны татар теленә өйрәткәндә аларда татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләрен һәм этикет кагыйдәләрен исәпкә алып сөйләм аралашу сәләтен үстерүне күздә тоткан социомәдәни компетенция формалаштыру зур әһәмияткә ия.

Татар теле дәресләрендә мәдәниятара аралашу күнекмәләрен формалаштыру аспектларын эшләгәндә без түбәндәге факторлардан чыгып эш иттек:

1. Мәдәниятләр арасындагы нәтиҗәле элемтәләр һәм тел ияләренең ДТК (ЯКМ) аңлау өчен мәдәният, фәлсәфә, тәртип, дин, дөньяны кабул итү, характер, ягъни халыкларның менталитетын белү мөһим.

2. Һәр милли мәдәният аралашуның милли үзенчәлекләрен үз эченә ала.

3. Мәдәниятара аралашу күнекмәләрен формалаштыру бик мөһим.

Мәдәниятара бәйләнеш күнекмәләрен формалаштыру максатыннан тел ияләренең менталитетын тулырак ачучы түбәндәге темаларны өйрәнү аеруча мөһим дигән фикергә килдек: татар халкының һәм башка телле илләр халыкларының гореф-гадәтләре һәм традицияләре; бәйрәмнәр; рухи һәм матди мәдәният; төрле халыкларның аралашу үзенчәлекләре, этикет; сөйләмсез аралашу чаралары; социаль символизм; әдәби геройларның типологик охшашлыклары; фәлсәфә, дөньяга караш, кыйммәтләр.

Мәдәниятара бәйләнеш күнекмәләре формалаштыру һәм камилләштерү максатларына туры килергә тиешле аутентик текстларны сайлаганда мәгълүматның чынбарлыкка туры килүенә, тулылыгына, укучыларның тормыш һәм сөйләм тәҗрибәсенә туры килүенә игътибар итәргә кирәк.

Шулай итеп, мәдәниятара бәйләнеш аралашу күнекмәләрен формалаштыру, укучының когнитив һәм тел аңнары арасында тыгыз бәйләнеш тәэмин итә дигән нәтиҗә ясарга була.

**Әдәбият**

1. Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии. – Казань: Магариф, 2009. – 351 с.

2. Соловова Е.Н. Методика обучения иностранным языкам: Базовый курс лекций. – 2-е изд. – М.: Просвещение, 2003. – 239 с.

3. Тарева Е.Г. Устная межкультурная коммуникация: проблемы трудностей понимания // Вестник Пермского национального исследовательского политехнического университета. Проблемы языкознания и педагогики. – 2018. – № 1. – С. 71-82.

4. Сибгаева Ф.Р., Мугтасимова Г.Р. Языковая вербализация смежных эмоций во фразеологических единицах татарского языка // Филология и культура. – Казань: Изд-во КФУ, 2023. – С. 79-87.

5. Юсупова Ә.Ш., Кириллова З.Н., Фәтхуллова К.С.Татар теленә өйрәтү: үткәне һәм бүгенгесе. – Казан: Вестфалика, 2011. – 212 б.

# ХӘЙ ВАХИТ ИҖАТЫНДА ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

*Иванова П.., Саба р-ны Шәмәрдән лицее "Үсеш", XI сыйныф*
*Җит. – Сабирова Р.А.*

Фольклорның әдәбиятка һәм сәнгатькә күпьяклы тәэсире – танылган хакыйкать. Халык иҗатындагы сюжет һәм мотивларны куллану исә борынгыдан алып бүгенгәчә дәвам итә. Кайсы гына чор әдәбиятына яки кайсы гына язучы, шагыйрь яисә драматург иҗатына күз салсак та, халык авыз иҗаты белән бәйләнешне күрә алабыз. Хәй Вахит иҗатының фольклор белән бәйләнеше ни дәрәҗәдә икән? Менә шушы сорау кызыксындырды безне. Шул сәбәпле без фәнни-тикшеренү эшебезне Хәй Вахит әсәрләрендә халык авыз иҗатының ни дәрәҗәдә кулланылуын өйрәнүгә багышладык һәм "Хәй Вахит драмаларында – фольклор" дип атадык.Эшебезнең максаты – әсәрләрне өйрәнеп, фольклор белән бәйләнешен ачыклау. Тикшерү объекты итеп, "Яшьлек юллары", "Пьесалар", "Күк капусы ачылса" җыентыкларын алдык.

Х. Вахит, чын халыкчан драматург буларак, иҗатында фольклорга еш мөрәҗәгать иткән. Аларда автор татар фольклорының мәкаль, җыр, әкият, хикәят, сынамыш, һ.б. жанрларына караган әсәрләрен үзгәрешсез хәлендә тулаем да, өлешчә дә, кирәк булганда үзгәртеп тә файдаланган. Х.Вахит үз иҗатында характер тудыруда еш кулланылган поэтик алым – мәкаль-әйтемнәрне аеруча еш кулланган. Алар аша әсәрләренең телен халык сөйләменә якынайткан, образлылыгын көчәйтүгә китергән. Х. Вахит мәкальләрне үз әсәренә күбесенчә әзер хәлдә кертеп җибәрә. Мәсәлән, "Тел сөяксез, ул ни сөйләмәс", "Телең нәрсә сөйләгәнне колагы ишетми", "Дүрт аяклы ат та сөртенә" . Ә кайбер очракта ул аны үзенә кирәкле рәвештә үзгәртеп кертә. Мәсәлән, "Беренче мәхәббәт" драмасында "Кызым сиңа әйтәм, киленем, син тыңла" мәкален "Кызым сиңа әйтәм, Тәлгать, син тыңла", "Бер акыл яхшы, ике акыл яхшырак" урынына "Бер акыл яхшы, бер ярым акыл яхшырак" дип, Рәхиләнең гади генә нәрсәләрне дә аңлый алмавына ишарә итә. Драматург әсәрләрендә башка милләт халкының да мәкальләреннән оста файдаланган. Рус халкының "В каждой шутке есть доля правды", "Не было бы счастья да несчастье помогло" , "Чем черт не шутит, когда бог спит" мәкальләрен "Сәер кеше" драмасында бик оста кулланган. Шулай ук "Рәхим итегез" пьесасында немец халкының "Укысаң, катман булырсың; укымасаң – черки" мәкален Зәйтүнәнең сөйләменә кертеп, аның белем дәрәҗәсен күрсәтүгә ирешә. Ә инде "Җырым табар сине" драмасында кытай халык мәкален дә

урынлы куллана: “Ун адым атларга кирәк булганда, тугыз адым атлагач, ярты юлны үттем дип исәпләргә була”. Драматургның 13 әсәреннән 72 мәкаль һәм әйтем язып алдык.

Җырлар – халык иҗатының бик бай һәм үзенчәлекле ягы. Җырда – кешенең уй-теләкләре, хис-кичерешләре; тел әйтә алмаганны җыр әйтеп бирә. Шуңа да Х. Вахит сәнгатьнең бу төренә еш мөрәҗәгать иткәндер. Пьесаларында татар халык җырларын да, үзе язган җырларны да шактый күп куллана. Мин тикшергән әсәрләрдә халык җырларының барлык төрләре дә очрый.Йола җырларына мисалга, никах туенда башкарылган җырларны әйтә алабыз. “Талак, талак”, “Ике килен-килендәш”, “Соңгы хат”, “Күк капусы ачылса” музыкал комедияләрендә туй йоласы белән , шушы матур бәйрәмдә башкарыла торган җыр-такмаклар белән танышабыз. Ай икегез,икегез, Икегезнең битегез...Икегез дә пар килгәнсез,Тигез гомер итегез (“Сәер кеше”).

Шулай ук Х.Вахит драма әсәрләрендә табышмаклар да (“Утта янмый, суда батмый” (“Сәер кеше”, 114 б.), әкият мотивларын да (“бүре барыбызны да берәм- берәм тотып ашады” (“Сәер кеше”, 99 б.) , үртәвечләрне дә (Газиз: көнче, Рәмзия: көнче, Газиз: бака-ка, Рәмзия: бака-ка” (“Күк капусы ачылса”,184 б.), сынамышларны да очратырга була. “Җырым табар сине” пьесасында юрау белән дә очрашабыз. Сәрия сөйгәне Шәүкәт турында: “Яратамы соң ул мине? Әгәр дә яратса, ул янындагы кызны биергә чакырмаячак, минем янга да килмәячәк.. Ул тәрәзә янына китәчәк. Әгәр дә яратса” дип юрый .

Нәтиҗә ясап әйткәндә, драма әсәрләрендә халык авыз иҗаты үрнәкләре, аеруча җырлар, такмаклар, мәкаль-әйтемнәр шактый еш кулланылган. Аларның вазифасы күптөрле. Алар геройларның хис-кичерешләрен тулырак чагылдыру, сөйләмне матурлау, эмоциональлекне арттыру өчен хезмәт итәләр.

**Әдәбият**


1. Әхмәдуллин А. Хәй Вахит (1918-1978: [драматург тур.] // Татар әдәбияты тарихы. – Т.6. – 2001. – Б.388-405.
2. Җамалетдинов Л.Ш. Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә әкият традицияләре.// Төркиләрнең телләре, рухи мәдәниятләре һәм тарихлары: традицияләр һәм заман. Халыкара конференциянең хезмәтләре 3-томда, 9-13июнь 1992, Казан. – Б. 230-236.
3. Татар халык мәкальләре: Өч томда / Җыючысы һәм төзүчесе Нәкый Исәнбәт. 1 т. – Казан, 1959. 632б.
4. Хәй Вахит: [Язучы драматург Х. Вахит (1918-1978) тур.] // Татар драматурглары: биобиблиографик белешмәлек/төз. Ф. Ганиева, Ф. Яруллина, А. Саттарова. – 2007. – Б.53-54.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ ПАРЛЫ СҮЗЛӘРНЕҢ СИНОНИМИК КОМПОНЕНТЛАРЫНЫҢ МӘГЪНӘВИ ТӨРЛӘРЕ

*Ильясова Г., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Денмөхәммәтова Э.Н.*

Парлы сүзләрнең – төрки телләрнең сүзьясалыш һәм лексик системасының үзенчәлекләренең берсе. Парлы сүзләр башка лексик берәмлекләрдән ике компонентлы булулары белән аерыльш торалар: ата-ана, көн-төн, мал- туар, савыт-саба һ.б. Алар сөйләмдә мәгънәне я көчәйтеп (экспрессия), я киңәйтеп, я гомумиләштереп киләләр.

Татар телендә синоним компонентлы парлы сүзләр – төрле генетик чыгышлы, әмма бер үк семантикага ия булган сүзләрнең кушылмасы. Безнең фикеребезчә, татар телендәге мондый парлы сүзләр тыңлаучыга йогынты ясау көчен арттыру өчен барлыкка килгән.Татар телендә кулланыла торган парлы сүзләр составында синоним берәмлекләрне семантик, структур, этимологик яссылыкта барлау тел белемендә актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Мәкаләнең максаты – татар телендә парлы сүзләр синонимик компонентларының мәгънәви төрләрен тикшерү.

Мәкаләнең өйрәнү объекты – татар телендәге парлы сүзләр. Өйрәнү предметы – парлы сүзләр составындагы синоним берәмлекләрнең мәгънәви төрләре.

Татар телендәге парлы сүзләр үзләренең семантикасы, тематикасы буенча шактый киң спектрдагы классификацияләрне тәшкил итә ала. Бу факт телебезнең никадәр бай һәм сыгылмалы булуын тагын бер кат дәлилли.

Парлы сүзләр дип комплексның бер мәгънәсен белдерүче бертөрле сүзләрнең парлашуыннан барлыкка килгән сүзләрне атыйбыз. Бу субъект компонентлары арасында синонимияне күренешен барлыкка китерүне алдан билгели. Компонентларның семантикасын ачыклау аркасында, семантик яктан конкретрак өченче мәгънә барлыкка килә. Мәсәлән, «*кайгы-җафа*»: *кайгы – төрки-татар теленнән авырлык, җафа – гарәп-фарсы алынмасы авырлык, «холык-табигать»: холык – гарәп-фарсы алынмасы характер, табигать – гарәп алынмасы табигать һ.б.*

Синонимик компонентлы парлы сүзләр ике тулы (охшаш) синоним яки мәгънәгә якын булган сүзләр өстәп (парлашу) нәтиҗәсендә формалашалар. Әйтергә кирәк, лингвистикада синонимнар төрлечә шәрехләнә. Берәүләр синоним сүзләр дип мәгънәләре тулысынча туры килгән сүзләрне таный, икенчеләр – мәгънәләре якын булган сүзләрне синоним дип саный.Әлеге курс эше

тикшеренүләре кысаларында без беренче карашны өстен күрәбез, ягъни синонимнар дип мәгънәсендә охшаш,бик якын мәгънәле сүзләр дип саныйбыз.

Берничә очракта парлы комбинацияләр компонентларның семантик яктан бер-берсенә туры килүеннән барлыкка килә. Игътибар итик: *гыйлем-белем, белем-мәгърифәт, хәбәр-хәтер, бәхет-тәуфыйк, сау-сәламәт һ.б.* Шулай итеп, синонимик парлы комбинацияләрдә җыю семантикасы, сыйфаты, торышы, эшнең чагылышы, шулай ук эшнең кабатлануы күрсәтелә.

Парлы сүзләр турындагы мәкалә авторы И.П. Павлов түбәндәгеләрне искәртә: «Әгәр парлы сүз үзенең составындагы ике компонентның лексик мәгънәләренең суммасын гына белдерсә, телдә андый сүзләрнең ихтыяҗы булмас иде» [2: 70].

Мисал өчен, «*табак-савыт*» сүзе борынгы заманнардан ук килгән булырга тиеш, һәм баштан ук ул ачыктан-ачык күрсәтелгән эксплицит мәгънәләрне генә түгел, ә имплицит, ягъни тулы мәгънәләрне дә күрсәткән. «Табак-савыт» дигәндә бары тик табак һәм бары тик савытларны гына түгел, гомумиләштереп, барлык төр савытны һәм хәтта калак-кашыкларны да атыйлар.

Шулай итеп, синонимик компонентлы парлы сүзләрнең гомуми лексик мәгънәсе тип төрләрен белдерүче компонентларның мәгънәләреннән күпкә киңрәк. Барлык төрләрендә дә парлы сүз, парга кушылган сүзләрнең мәгънәләренә зур үзгәрешләр кертмичә, төшенчәләрнең киңлеген киңәйтә.

Синонимик компонентлы парлы сүзләр арасында лексик мәгънәләрен югалткан компонентлар да очрый: *әҗе-гөҗе килү – озак итеп дусларча сөйләшү.*

«*Әҗе-гөҗе*» парлы сүзе искергән аваз ияртемнәре кушылмасыннан гыйбарәт булса кирәк. Морфологик һәм семантик күзлектән караганда, бу парланган сүзләр абсолют парлашу кагыйдәсенә тулысынча туры килә. Бу факт исә формалашкан вакытта ике компонентның да мөстәкыйль мәгънәгә ия булуын күрсәтә.

Икенче компонент буларак, аңлашылмый торган мотивацияле сүзләр дә кулланылырга мөмкин: *өй-тулак, сирәк-мирәк, күрше-күлән, малай-шалай, тимер-томыр һ.б.*

Йомгак ясап әйткәндә, татар телендә синоним компонентлы парлы сүзләр – төрле генетик чыгышлы, әмма бер үк семантикага ия булган сүзләрнең кушылмасы. Безнең фикеребезчә, татар телендәге мондый парлы сүзләр тыңлаучыга йогынты ясау көчен арттыру өчен барлыкка килгән. Мондый төр парлы сүзләрне өйрәнү тел тарихы, этимология, семасиология һәм социолингвистика кебек тел белеме

бүлекләрне белән тыгыз рәвештә бәйле, димәк, синоним компонентлы парлы сүзләрне өйрәнү татар телен генә түгел, ә төрки тел белемен өйрәнүдә дә аерым бер өлеш кертә алачак.

Шулай итеп, татар тел белемендә парлы сүзләр проблемасы буенча булган әдәбиятны анализлау күрсәткәнчә, бу юнәлештә күп эш башкарылган. Ләкин, парлы сүзләрдәге синонимик компонентларның тәртибе турында кайбер фикерләр алга таба да өйрәнелүне таләп итә. Чөнки бүгенге көндә парлы сүзләр актив ясала бирә, алар арасында синонимик компонентларының да саны арта бара.

**Әдәбият**


1. Муратов С.Н. Устойчивые словосочетания в тюркских языках. – М.: Восточная литература, 1961. – 131 с.
2. Павлов И. П. Парные слова в современном чувашском языке // Исследования по этимологии и грамматике чувашского языка. – Чебоксары, 1988.

ТЕРМИНЫ РОДСТВА (СЕМЬЯ / ГАИЛӘ/ СЕМЬЯ/ AILƏ) В ТАТАРСКОМ, УДМУРТСКОМ И АЗЕРБАЙДЖАНСКОМ ЯЗЫКАХ

*Исмонова М., Фатхутдинова А., МБОУ «Гимназия №6 им. Габдуллы Тукая», X А класс*
*Науч. рук. – Манафова Г. А.*

У каждого народа есть свои особенности, традиции, культура и язык. Именно они заставляют людей гордиться принадлежностью к тому или иному народу. А через родной язык и традиции передаются все особенности образа жизни народа.

Интерес к теме проекта о языках возник не случайно. В нашей республике мы можем услышать русский, татарский, чувашский, мордовский, украинский, азербайджанский грузинский и другие языки. Среди наших гимназистов тоже есть ребята разных национальностей.

В данной работе сравниваются татарский, удмуртский и азербайджанский языки. Русский язык выполняет своеобразную роль посредника.

**Цель исследования:** выявить и описать основные сходства и различия терминов родства (СЕМЬЯ /Гаилә/Семья/ Ailə) в татарском, удмуртском и азербайджанском языках и создать обучающий видеоролик.

**Объект исследования:** термины родства на татарском, удмуртском и азербайджанском языках.

**Предмет исследования:** основные сходства и различия терминов родства в татарском, удмуртском и азербайджанском языках.

**Гипотеза** – предполагаем, что у народов схожи не только культуры, но и слова, обозначающие членов семьи, схожи по написанию и звучанию (СЕМЬЯ /Гаилә/Семья/ Ailə) на татарском, удмуртском и азербайджанском языках, но многие не знают об этом.

Семья – это один из древнейших социальных институтов, возникший раньше религии, политики, государства, образования. Семья выступает элементом социальной структуры, с принятыми в ней ценностями, обычаями, традициями и устоями.

В усвоении родного языка большая роль принадлежит именно семье.

В татарской культуре семья играет очень важную роль и является основой общества. Важный аспект воспитания детей в татарской семье – это передача этнокультурных ценностей, традиций, обычаев из поколения в поколение [1].

Татарский язык относится к тюркской языковой группе.

С целью анализа терминов родства на татарском языке, мы обратились к Толковому словарю татарского языка (в трех томах) [4].

Для удмуртов семья – это величайшая ценность, поэтому жизнь в браке воспринимается ими как естественное состояние и обязательный долг [2].

красный – настоящее, а фиолетовый – будущее.[1] Композиция “Forsa” («Раб на галерах»), выпушенная в 2021 году, которая в дальнейшем вошла в альбом, на наш взгляд, имеет право именоваться заглавной песней, на что указывает её кроваво-красная обложка и сама лирика: “Ters yönden gelen bıçkın başkanım ağlamazsan bir çift sözüm var” («Мой отважный президент, идущий с противоположной стороны, если ты не заплачешь, у меня есть пара слов сказать тебе»). В данной песне музыканты бесстрашно склоняют на диалог правителя государства, честно рассказывают о том, что всегда слушали его, не убегали, покорялись року судьбы, как в суфизме. Начав этот откровенный разговор, они надеются на положительные изменения, понимая, что быть правителем – нелегкая ноша.

Песня поп исполнителя Таркана “Geççek” («Пройдет»), выпущенная в 2022 году, вызвала бурную реакцию среди общества, особенно в интернет-пространстве. Текст произведения обладает двояким смыслом: с одной стороны, автор делится чувствами после пандемии Covid-19, которые откликаются у многих слушателей, с другой стороны, исполнитель говорит о предстоящих выборах в Турции. Политический контекст прослеживается в следующих строчках: “Gitçek gitçek geldiği gibi gitçek. Her şeyin sonu var, bu çile de bitçek” («Уйдет уйдет, как пришел, так и уйдет. У всего есть конец, закончится и это испытание»). Однако большинство пользователей придерживались мнения, что в тот период, когда были экономические трудности, пандемия, политические дебаты перевешивали беспокойство о будущем. Турецкому народу было необходимо услышать обнадеживающее послание [2].

В конце концов, в столь непростое время в музыкальной индустрии намечается курс на душевный мир человека. Ярким примером является альбом “Harekete kimse mani olamaz” («Никто не может помешать движению») группы Адамлар, разделенный на две части и вышедший в 2021 и в 2023 годах. Согласно заявлению исполнителей, основная идея второй части альбома – это разговор с самим собой [3]. Название “Harekete kimse mani olamaz” встречалось ранее в произведении Ашика Вейселя, “Anlatamam Derdimi Dertsiz İnsana” («Я не могу рассказать о своем горе беззаботному человеку»). Песня “Yaktı Geçtı” («Только прошло») задает наводящие вопросы и направляет слушателей вглубь себя за поиском ответов: “Neye güvenilir de hep unutulur? İçerine bak da kendini bul” («Чему доверяют, и о чем всегда забывают? Загляни внутрь и найди себя»). Таким образом, группа Адамлар подталкивает слушателей на анализ собственных

чувств, говоря в текстах песен, что пришло время рассказать о своих проблемах.

Анализ турецких песен за последние пять лет показал, что реп-исполнители склонны резко высказываться об актуальных проблемах общества, тогда как поп- и рок-музыканты делают это в более мягкой форме с двояким смыслом. Некоторые исполнители погружаются в самоанализ, уходя от политической повестки и пытаясь найти ответы на происходящие события внутри себя.

**Литература**


1. Aklımdakiler: mor ve ötesi // Bant Mag URL: https://bantmag.com/dergi/no77/aklimdakiler-mor-ve-otesi (дата обращения: 16.01.2024).
2. Geççek: Tarkan interneti salladı // Yetkin Report URL: https://yetkinreport.com/2022/02/18/geccek-tarkan-interneti-salladi/ (дата обращения: 16.01.2024).
3. “Harekete Kimse Mani Olamaz” üzerinden bir Adamlar analizi // Dergy URL: https://www.dergy.com/harekete-kimse-mani-olamaz-uzerinden-bir-adamlar-analizi/ (дата обращения: 16.01.2024).
4. Susamam: Turkey's social problems laid bare in popular hip-hop song // The National URL: https://www.thenationalnews.com/world/europe/susamam-turkey-s-social-problems-laid-bare-in-popular-hip-hop-song-1.908020 (дата обращения: 16.01.2024).

# ОТРАЖЕНИЕ ПРОБЛЕМ ВЛАСТИ ТЮРКСКИХ КАГАНОВ В ПИСЬМЕННЫХ ПАМЯТНИКАХ СРЕДНЕВЕКОВЬЯ

*Мельник А., ЕНУ им. Гумилева, студент IV курса*
*Науч. рук. – Шиймердинова Н.Г.*

В письменных памятниках и исторических сводках, охватывающих периоды раннего и позднего средневековья, прослеживаются упоминания многочисленных проблем, связанных с передачей и удержанием власти в тюркских государствах, в том числе в результате внешних конфликтов.

Со времен правления фактического основателя тюркского каганата – Мугань-хана (553-572 гг.) власть у тюрков передавалась от старшего брата младшему, от дяди – старшему племяннику. Подтверждение этому мы находим в китайских источниках. Так, в переводе Э.Г. Паркера [1] есть фразы «минуя сына его поставили младшего брата», а также «сына Эльтериша по малолетству не допустили к престолу, Капаган сам объявил себя ханом». Здесь хорошо проглядывается система занятия престола старшими родственниками, однако китайцам, привыкшим к линейной передаче власти это казалось узурпированием трона. С одной стороны, закон Мугань-хана способствовал укреплению власти кагана: во главе государства не мог оказаться ребенок, а родственники кагана могли претендовать на наследство и верховный титул, что снижало вероятность предательства. Вместе с тем, передача власти часто сопровождалась военными столкновениями. Ярким примером подобной борьбы является военный переворот 716 года, когда после смерти Капаган кагана на престол временно взошел его сын, Богю каган. По закону, титул кагана должен был наследовать племянник Капаган кагана – Могилян (старший сын Эльтериш кагана), однако Капаган каган, якобы, завещал передать трон своему сыну Богю. Советники каганской ставки в июне 716 г. провозгласили Богю, сына Капаган кагана, Инель-каганом. Но в том же году, Кюль-Тегин свергнул Инель-кагана, вырезав часть знати и советников, после чего каганом стал Могилян, старший брат Кюль-Тегина [2]. Таким образом, система престолонаследия в тюркских каганатах способствовала укреплению верховной власти кагана, и великая тюркская держава вместо тридцати-сорока лет просуществовала двести. Вместе с тем, братоубийственные войны за престол ослабляли тюркское государство и негативно отражались на жизни простого народа.

Борьба за власть также возникала в результате свержения кагана, что можно проследить в истории Тюргешского каганата. В 738

году Сулук каган был убит своим соратником, вождем сары-тюргешей Бага-Тарханом. В битве на реке Шу кара-тюргеши были разбиты, а столица каганата, город Талас, разрушен. В 740 году был убит и Бага-Тархан, а главой кара-тюргешей стал Иль-Идмиш-Кутлуг-Бильге [2].

Важнейшим внешним фактором, который на протяжении столетий влиял на становление и развитие тюркских государств являлось соседство с Китаем, империи которого активно вмешивались во внутреннюю политику тюрков. После появления империи Суй в 581 г., отношения тюрков с китайскими государствами ухудшались. Несмотря на то, что Восточно-тюркский каганат поддерживал империю Тан, в письменных памятниках часто прослеживается недоверие и агрессия со стороны правителей каганатов. В памятнике Тоньюкука есть строчки: «Тюркский народ, не будучи со своим ханом, отделился от Табгач (Китая). (Затем) оставив своего хана, снова вступил в Табгач (Китай). Тенгри так сказало: «Я дало (тебе) хана!)» [3], «в союзе с Ильтерис каганом, поразили на юге много Табгачей (Китайцев)», «(Так пусть) Табгач (Китай) нападет с юга, Китан - с востока, я (т.е. Огуз) нападу с севера. Пусть не распоряжается (букв. не ходят) на земле благородных Тюрков (их) властитель! Да обрушимся мы на них (с трех сторон)!», «Каган Табгачей (Китая) был нашим врагом. Каган "Десяти стрел" был нашим врагом.» [4]. В 690-х годах напряжение между Вторым восточно-тюркским каганатом и Китайскими империями стало нарастать. Тюрки начали войну, которая продолжалась до 745 г. Основной целью Восточно-тюркского каганата был равный статус с империей Тан и соблюдение торговых отношений. Кроме того, напряженные отношения с Китаем возрастали из-за ухудшающегося экономического положения тюрков, что в значительной степени приводило к ослаблению политической власти кагана. В разных памятниках говорится «бедная страна» (Надписи на скале Цахир1, перевод Ц.Баттулги) [3], «дабы не исчез Тюркский народ, дабы вновь стал страной» (памятник Кюль-Тегину). Из-за частых военных действий состояние экономики в каганате находилось в бедственном положении и тюркские народы стали уходить к Китаю «соблазняясь золотом и шелками». Эти события прослеживаются в памятниках Кюль-Тегина, Бильге кагана, Тоньюкука и других: «Ты, оставив своего хана, вступил (букв. вступил внутрь, т.е. подчинился снова Китаю)!», «Из-за этого вступления Тенгри поразило (букв.: умертвило). Тюркский народ ослаб (умер), обессилел, сошел на нет» (Памятник Тоньюкуку). «У табгачей(китайцев) слова сладкие и шелка мягкие. Обманывая своими сладкими словами и мягкими шелками, они

привлекают к себе людей издали. Как только люди к ним приближаются, одурманивают их еще больше. Они не позволяют мудрым и хорошим мужам приблизиться к себе. Они развращают, начиная от одного до его целой семьи и клана. Будучи обманутым их сладкими словами и мягким шелком, вы тюркский народ, умирали….Они обманом довели тюркский простой народ до смерти. Они обманывали их, что они дадут плохой шелк, если те будут жить вдалеке, и дали бы хороший шелк, если те жили близко к ним. Неблагоразумные люди следовали за этим словами, приблизились, и все умерли….О тюркский народ, вы такие сытые. Вы не думаете о голоде и изобилии. Один раз насытившись вы никогда не думаете, что можете быть и голодными. Из-за вашего легкомыслия, и неповиновения вашему кагану» (Памятник Бильге кагану) [5]. Как свидетельствуют эти источники, беднеющее население каганата мигрировало в Китайские провинции, где их в последствии не воспринимали как полноценных граждан. Таким образом, власть тюркских правителей на территории Центральной Азии по мере усиления Китайских империй ослаблялась, однако смотря на все вышеуказанные проблемы тюркские государства остались не только в истории, но и смогли дожить до сегодняшних дней под другими названиями.

**Литература**

1.Паркер. Э.Г. Китай. Его история, политика и торговля с древнейших времен до наших дней. С 6 картами / пер. М.Грулев. – СПб.: Тип. Тренке иФюсно, 1903. – 569 с.

2. Гумилев Л.Н. Древние тюрки. – СПб.: СЗКЭО, 2002. – 576 с.

3. Радлов В. В., Труды Орхонской экспедиции, Атлас древностей Монголии. выпуски 1–4. – СПб., 1892—1899.

4. Кляшторный С.Г. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии // История Центральной Азии и памятники рунического письма / Яковлев В.В.. – СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2003. – 560 с.

5. Кляшторный С. Г., Султанов Т. И. Государства и народы Евразийских степей: От древности к Новому времени. –СПб.: Петербургское востоковедение, 2009. – 432 с.

6. Казахстан. Национальная энциклопедия» (1998–2007), предоставленного редакцией «Қазақ энциклопедиясы» по лицензии Creative Commons BY-SA 3.0 Unported

7. Насилов В. М., Грамматика языка тюркских рунических памятников (VII—IX вв.). – Л., 1980.

# М. МӘҺДИЕВ ПУБЛИЦИСТИКСЫНДА МИЛЛӘТ ТАРИХЫ ТЕМАСЫ

*Минәхмәтова Э., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гайнуллина Г. Р.*

Мөхәммәт Мәһдиев – XX йөзнең икенче яртысында киңкырлы әдәби эшчәнлек алып барган, татар әдәбиятын прозаик әсәрләр белән баеткан язучы. Әдип турында тормыш-яшәешкә карата анык үз фикере булган, әдәбиятта үз сукмагын тапкан, беркемне дә кабатламаган каләм иясе, дип әйтергә мөмкин.

Мөхәммәт Мәһдиев публицистикасында татар теле, сөйләм культурасы белән бәйле проблемаларга багышланган мәкаләләр күп. Автор зыялы даирәдә дә еш җибәрелә торган хаталарга игътибар итә. Мөхәммәт Мәһдиев шулай ук туксанынчы елларда тел өлкәсендәге тагын бер процесска битарафлылык күрсәтә алмый. Бу елларда рус-европа алынмаларын кискен рәвештә гарәп-фарсы алынмалары белән алыштыру процесса бара. Мөхәммәт Мәһдиев бу юл белән генә милли үсешкә ирешеп булмый, дигән фикерне дә белдерә. Шулай ук терминологиядә, башка өлкәләрдә бары рус теле аша кергән алынмаларның артык күп булуына да ризасызлык белдерә. Асылда исә ул шушы мизгелдә кешедә редактор дип тә, мөхәррир дип тә; мәдәният дип тә, культура дип тә сөйләшү мөмкинлеге калырга тиешлеге идеясен яклап чыга. Авторның аеручы әһәмиятле фикере түбәндәге юлларда чагылыш таба: “*Без – Шәрык белән Гареб (Көнбатыш) арасында яшибез. Бу – безнең бәхетебез. Татар баласы якын елларда дүрт теле булып үсәргә һәм барысын да камил рәвештә белергә тиеш. Болар – үз теле, рус теле, бер Көнчыгыш теле һәм, һичшиксез, бер Көнбатыш теле. Татар баласы якын елларда Төркия, Россия, Африка, Европа сәүдә контораларында эш йөртергә, аларның гыйлем учакларында кайнарга һәм үзен мескен шәкерт хәлендә түгел, европалы галим, бизнесмен дәрәҗәсендә сизәргә, эш-гамәл йөртергә тиеш*” [2: 369].

Мөхәммәт Мәһдиев публицистикасында татар авыллары, аларның атамалары белән бәйле язмалар да шактый актив. Дөрес, “Туган як авазы” язмасында автор үзе үк ассызыклап киткәнчә, “*Мин бу өлкәдә белгеч түгел, бу мәсьәлә белән махсус шөгыльләнгәнем юк. Фән-гыйлем өлкәсендә минем XX гасыр башы татар әдәбиятына һәм халык иҗатына караган азмы-күпме хезмәтләрем бар. Авыл исемнәренә килсәк, моңа инде мин туган як табигатендә, җирендә сакланып калган тарих авазларын интуиция белән генә сизә алам. Ә интуиция ул – фактлар белән дәлилләми, шуңа күрә минем бу өлкәдә бик нык ялгышуым да бар. Шулай да тәҗрибә-күзәтүләремне*

*уртаклашып карыйсым килә* [2: 118]. Мөхәммәт Мәһдиев бу темага фәнни хезмәтләр язмый, фикерләре белән публицистик яңгырашлы язмаларында уртаклаша. Әлбәттә, туган ягы Арча районы авылы атамалары, туган авылы Гөберчекне бу яктан игътибарсыз калдыра алмый. Атаклы Тукаебыз тормышындагы авыллардан Өчиле, Кушлавыч атамаларына да аерым туктала. Автор шуңа игътибар итә: беренче карашка, күп кенә авылларның атамалары җиңел интерпретацияләнә. Мәсәлән, Өчиле авылының исеме өч һәм өй сүзләре нигезендә ясалу аңлашыла кебек. Әмма бу алдвыч караш. Мөхәммәт Мәһдиев болай дип яза: "*Өчиле" исеме "бу авылда башта өч өй булганнан килеп чыккан" дигән версиягә минем ышанасы килми. Борынгы заманда, яңа җир үзләштергәндә, кайсы авылга нигез салганда анда ничә өй салынуы турында документлар була алмый, һәм аны эзләргә дә кирәкми. Өч өйле авылдан килми әлеге исем, ә "оч иле" дигән сүздән. Калын урман эченәрәк керә-керә авыл салып, ил нигезләп килгән бабайлар аерым территорияләрне кысалап, очын-кырыен билгеләп барганнар*" [2: 123].

Шунысы кызыклы: татар авылы атамалары, аларның килеп чыгышы, этимологиясе, аларның дөрес язылышы, рус телендә бирелеше кебек проблемалар күп кенә атаклы шәхесләребез, зыялыларны борчый. Т. Миңнуллин да әлеге проблеманы шактый актив күтәрде. Моны, беренчедән, күпчелек зыялыларыбызның авыл чыгышлы булуы белән аңлатырга була. Икенчедән, авыл электән татар милләтенең бишеге, әхлакый һәм мәдәни сакчысы буларак кабул ителгән. Дөрес, бүген ситуация беркадәр үзгә, әмма авылларга ихтирам һәм игътибар тәрбияләү актуаль яңгырашын югалтмый.

Мөхәммәт Мәһдиевнең әдәби тормыш, әдәби барыш, татар әдәбияты классиклары язмышы һәм аларның иҗатының милләт тормышындагы роле, гомумән, язучының Җирдәге, илендәге вазифасы, аның башкалардан аермасы турындагы язмалары аеруча уйлануларга этәрә. Тукайлар заманыннан ук шагыйрьләрне, язучыларны пәйгамбәр белән чагыштыру идеясе яшәп килә. Тукайда шагыйрь-пәйгамбәр образы А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтов иҗатларына мөрәҗәгать итү, алар белән яхшы танышу булу җирлегендә туа. Мөхәммәт Мәһдиев әдипләрне изгеләштерми, әмма Р. Назами белән әңгәмәдә ("Әйдә, халыкка хезмәткә!") аларда алдан сизенү, тарихи борылышларга карата үтә сизгерлекне төгәл хакыйкый фактлар белән дәлилли. Татар шигъриятеннән мондый мисаллар китерә: "*Муса Җәлил, комсомол, пионер турында дежур шигырьләр язып, матбугатта Алланы, мәчетне, динне сүгеп гомерен исраф итеп ятканда, кинәт кенә тарихи тема – "Алтынчәч"кә килеп керә. Һич тә көтелмәгән пассаж бит.*

*Ничек алай була соң? Шагыйрьнең күңеле алдан сизә. Кулупай пәһлеваннар бөтен бер Болгар илен актык кешесенә кадәр бетерергә дип килгәндә, көн тәртибенә бер халыкның икенче бер халыкны бетерү мәсьәләсе куела. Муса Җәлил моны язганда, Гитлер нәкъ шушындый план корып ята иде бит. Шагыйрь күңеле моны сизгән һәм комсомол рухлы, шикәрле шигырьләрен куеп торып, әнә шундый мөһим темага кергән*” [2: 621]. Әлбәттә, аерым язмаларда әдип үзенең язучы булып китү тарихына, әдәбият белән кызыксынуына йогынты ясаган факторларга да туктала. Бу яктан аның “Каләм ни димәс” һәм “Мәшәкатьле һөнәр” кебек мәкаләләре игътибарга лаек.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: Мөхәммәт Мәһдиевнең публицистик мирасы тематик яктан гаять киң һәм автор шәхесе белән бәйле. Аның язмалары арасында икътисад, сәясәт белән бәйле проблемаларга багышланганнарны табуы бик катлаулы. Нигездә исә мәдәният, сәнгать, мәгърифәт, туган тел, педагогика, татар әдәбияты тирәсендә тупланган проблемаларга мөрәҗәгать ителә. Мөһиме шул: автор үз компетенциясеннән ерак булган темаларга үрелми, үзенә яхшы таныш, иҗтимагый яктан әһәмияткә ия аспектларга игътибар итә. Публицистик мирасы аны милләтнең асыл улы, Ватанының актив гражданины, зыялы шәхес буларак ачарга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**


1. Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. Биш томда. Том 3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 480 б.
2. Мәһдиев М.С. Әсәрләр. 10 томда. 9 нчы т.: публицистика, эсселар, интервью. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 767 б.
3. Ахунов Г. Авыл пәйгамбәре // Мөхәммәт Мәһдиев: язучы турында замандашлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 9-11.
4. Әхмәтгалиева М. Әдипнең җылы эзләре буйлап // Мәгариф. – 1995. – №12. – Б. 12-19.
5. Галиуллин Т. Кеше китә – җыры кала // Мәгариф. – 1995. – №10. – Б. 17-20.

# ИНТЕГРАЦИЯ В ОБУЧЕНИИ МАТЕМАТИКЕ И ИНОСТРАННОМУ ЯЗЫКУ НА УРОКАХ В СРЕДНЕЙ ШКОЛЕ

*Минзянова Ф., КФУ, студент IV курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ашрапова А.Х.*

Интеграция математики и иностранного языка в обучении предполагает совместное изучение математических концепций и языка на уроке математики. В отличие от CLIL (Content and Language Integrated Learning), где предметное и языковое обучение планируются отдельно, интеграция предполагает органичное сочетание математики и иностранного языка в рамках урока математики или английского. Сочетание двух предметов в подобном соотношении частичного использования может способствовать более глубокому освоению обоих дисциплин.

Одними из главных преимуществ интеграции, несомненно, являются повышение мотивации и формирование познавательного интереса, что способствуют повышению уровня обучаемости и воспитанности обучающихся; формирование научно-целостной картины мира; систематизация знаний; увеличение темпа выполняемости учебных операций; применение творческого подхода к выполнению учебных заданий.

Для более яркого представления взаимосвязи иностранного, в частности английского языка и математики стоит разобрать закон Джорджа Зипфа, который он назвал в честь самого себя, подразделенный на две части, который описывает закономерности частотного распределения слов в тексте на любом естественном языке, в частности на английском. Первый из частей гласит, что вероятность обнаружения любого слова, умноженная на его ранг – является величиной постоянной. Вторая часть закона гласит, что разные слова в большом массиве текста могут иметь одинаковое количество вхождений.

Несмотря на то, что интеграция предметов является одним из наиболее актуальных в современном мире способов развития детей и предоставления им целостной картины окружающего нас мира, существует ряд проблем, с которыми можно столкнуться при попытке интегрировать различные предметы, и математика с иностранным языком не являются исключениями.

Если выделять проблемы, которые могут возникнуть чисто в интегрировании, то можно выделить, первоочередно, проблему изложения материала для интегрированного обучения. Следующей немаловажной проблемой, как по мне, является то, что для интеграции

этих двух предметов между собой мало одного лишь материала, составленного учителем. Нехватка подобной интеграции в самих учебниках тоже является одним из факторов, затрудняющих интеграцию. Взять, к примеру, учебники математики – они все печатаются лишь на одном языке. Еще можно выделить то, что интеграция математики и иностранного языка является сложным делом сама по себе, ибо интегрируют, обычно, те предметы, которые близки друг к другу, в которых используются похожие закономерности и теоретические основы и в которых одинаковые или же близкие методы исследования. Следующий рассматриваемый аспект – это, естественно, возрастные и психологические особенности учащихся. По сути своей, тоже является одной из главных проблем при реализации интеграции, так как учитывать эти две вещи очень непросто. Материал, который будет готовить преподаватель, должен, по крайней мере, быть способным усвоиться большей частью обучающихся. Если, к примеру, материал не будет обладать тем словарным уровнем, что и у учеников, если речь про урок математики, то интеграцию вряд ли можно будет назвать успешной. Материал не будет не только не понят, но и не воспринят в целом.

Если брать всё это во внимание, то, чисто с теоретической стороны, интеграцию можно провести вполне успешно. Но на чистой теории точные результаты предсказать невозможно. Следовательно, результаты и точность прогнозов в любом случае могут быть выявлены лишь на практике, чем, к слову, в современном образовании и занимаются. Сама необходимость в интеграции заключается в том, что в современном мире пока все еще преобладает дифференцированная, отдельно предметная система обучения. И знания, полученные в ходе такой системы, зачастую бывает отрывочными и не позволяющими полноценно воспринимать картину мира.

На самом деле, существует множество методов интеграции математики и иностранного языка на уроках в средней школе. Одним из распространенных методов является использование математических задач, которые для своего решения требуют использование иностранного языка. Следующий, тоже, в принципе, распространенный, но не сказать, что он такой эффективный, – это изучение математических терминов на иностранном языке с последующим выявлением соответствующих на родном языке терминов. В качестве ещё одного метода, можно назвать введение игр и упражнений, требующих использование иностранного языка для выполнения определённых задач. Еще одним довольно интересным, можно сказать, методом является просмотр фильмов, связанных с

математикой, на иностранном языке с последующим обсуждением. В этот ряд также можно включить чтение книг и статей, связанных с математикой, на иностранном языке.

Перечислять методы можно довольно долго, однако выбор зависит от целей урока, так как методы интеграции нельзя рассматривать только с плохой или хорошей стороны, ибо они имеют как свои плюсы, так и минусы. И для выбора правильного метода интеграции математики и иностранного языка стоит, в первую очередь, опираться на возрастные и психологические особенности учеников.

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕН УКЫТУНЫҢ МЕТОДИК ПРИНЦИПЛАРЫ ҺӘМ ЫСУЛЛАРЫ

*Минмуллина С., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Йосыпова Н.М.*

Хәзерге шартларда татар әдәбиятын укыту барышында педагог белем бирү технологияләрен, укытуның нәтиҗәле ысулларын сайлауга, татар әдәбиятын белү дәрәҗәсен тикшерүгә карата яңа, инновацион алымнар куллануга басым ясарга тиеш. Инновацион якын килү һәр укытучыдан татар әдәбиятын укыту методикасын тиешле дәрәҗәдә үзләштерүне сорый. Татар әдәбияты дәресләрендә әсәрнең эчтәлеген сөйләү, тестлар уздыру, төрле типтагы сораулар бирү традицион биремнәргә әверелде. Шуның өчен бу юнәлештә яңалыклар кертү аеруча да файдалы һәм максатка ярашлы санала.

Хәзерге татар әдәбияты дәресенең төп принциплары дип түбәндәгеләрне атап була:

1) укучыларның яшь үзенчәлекләренә таяну һәм аларның психологик үзенчәлекләренә нигезләнү; дәрестә һәрбер укучыга мөрәҗәгать итү, һәркайсының шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алу;

2) белем бирүдә укучы үсешен тәэмин итә торган формаларның өстенлеге: белемнәрне әзер рәвештә бирмәү, аларны мөстәкыйль рәвештә үзләштерергә өйрәтү, әсәр тукымасында проблеманы күрү һәм аны мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә тырышу;

3) дәрес формаларының төрлелеге, нәтиҗәле методик алымнар, ысулларны сайлап куллану, дәреснең тикшеренү характерында булуы зарур;

4) дәреснең төгәл структурасы, аның сюжетларга бүленеше, дәрес өлешләренең үзара бәйләнеше. Шартлы рәвештә дәресне берничә өлешкә бүлеп була: укучыларны проблемага җәлеп итү максатыннан формалаштырылган кереш өлеш; теманы аңлату, аны “хәрәкәткә” китерү, үстерү, тирәнәйтү; балага теләсә нинди әдәби проблеманың күп аспектлылыгын күрергә мөмкинлек бирү; дәрескә нәтиҗәләр ясау, үзләштерелгән белемнәрне тикшерү, төзәтмәләр кертү;

5) сораштыру формаларының төрлелеге (шул ук вакытта сораштыру дәрескә органик рәвештә үрелеп кереп китә, аның бурычларына буйсына);

6) сәнгатьле уку күнекмәләрен формалаштыру;

7) укытучының ачык һәм образлы сөйләме.

Шигъри әсәрләрне белем бирү оешмаларында укыту мәсьәләсе һәрвакыт каршылыклы фикерләр тудыра. Күп кенә методист-галимнәр шигырьне кичереп, сәнгатьле уку, яңгыраш аша укучы күңеленә

йогынты ясау мөһим дип саный. Аерым методистлар әсәрне анализламыйча, нинди дә булса нәтиҗәгә ирешергә мөмкин түгел дип исәпли.

Кереш дәрестә укытучы укучыларны шигырьне тоярга, кабул итәргә әзерли, эмоциональ яктан әзерлек эше алып барыла. Ул кайчакта укучылар элек кичергән халәткә мөрәҗәгать итеп, эмоциональ хәтерне җанландыра, йә булмаса шагыйрь һәм шигырьнең тууына кагылышлы мәгълүматлар белән таныштыруга багышлана [2: 240].

Шул ук кереш дәресләрдә укучының күңелен шигырьләрне кабул итүгә әзерләү максатыннан, төрле иҗади алымнардан файдаланырга мөмкин. Дәрес башында өйрәнелә торган шагыйрь иҗатының башка шигырьләре белән дә таныштырып узарга кирәк. Укытучы, гомумән алганда, шигъри дөнья, укучыларның яраткан шагыйрьләре хакында да бәян итә ала [3: 142].

Шигырьләр сирәк кенә өйдә укырга бирелә, чөнки аның күләме кечкенә. Күп очракта аның белән сыйныфта, анализ алдыннан гына танышалар. Бу шарт шигырьдән алган тәэсир-тойгының югалмавы өчен дә кирәк [2: 240].

Иң беренче тапкырында шигырь белән таныштырган вакытта, укытучы аны яттан укырга тиеш. Бу эшчәнлекне аңлатмаларга бүлү тыела. Шигъри әсәрне бер генә тапкыр укырга ярамый, чөнки бу гына җитми. Шигырьне уку тәмамлангач, аннан калган тәэсирләр белән уртаклашу, фикер алышуны оештыру зарур.

Шигырь анализлауда әңгәмә ысулы отышлылардан санала. Гадәттә, шигырьдәге кичереш укучы тарафыннан интуитив билгеләнә, аны төгәлләштерү исә әлеге хисне тудырган сәбәпләрне ачыклау барышында башкарыла. Дөрес, интуитив табуга ирешкәнче, укытучы, укучылар белән берлектә, кичереш образын билгеләү өстендә эшләргә, сораулар биреп, аларга кичерешне төгәл әйтүгә ярдәм итәргә тиеш. [1: 17].

Югарырак сыйныфларда, аеруча да гражданлык, сәяси лирика үрнәкләрен тикшергәндә, әсәрдә чагылыш тапкан биографик үзенчәлекләр, андагы хис-кичерешләрнең шагыйрьнең халәте белән тәңгәл килүе хакында материаллар бар. Безнеңчә, әлеге мәгълүматлар шулай ук шигырьне, анда урын алган хис-кичерешләрне шагыйрьнеке итеп түгел, ә, бәлки, шагыйрьнең лирик герой образын барлыкка китерүдә катнашып киткән материаллары буларак чагылырга тиеш.

Шулай итеп, без югарыда татар әдәбияты дәресләрендә хәзерге татар поэзиясен өйрәнү принципларына һәм ысулларына тукталдык. Бер-бер артлы буыннар алмашынып тора, мәгариф системасы да

үзгәреш кичерә, моңа бәйле рәвештә, дәресләрдә эш төрләренең төрләндереп бирелүе мөһим. Моның әдәбият фәнендә әсәрләрне анализлау вакытында да искәрмә түгеллеге мәгълүм. Педагог һәрбер шигырьнең нинди ысул аша үзләштерелергә тиешлеген алдан ук күзаллап, аны үтемле рәвештә укучыга җиткерә белергә тиеш. Әсәр гап-гади сорау-җавап формасында гына анализлана икән, аның нәтиҗәлелеге бик түбән булып санала. Шуның өчен укучыда әсәр тукымасына карата кызыксыну уяту мөһим.

**Әдәбият**

1. Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.

2. Заһидуллина Д. Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод. кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.

3. Исмәгыйлова С.Г. IV-X классларда лирик әсәрләрне өйрәнү. Әдәбият укытучылары өчен методик кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 194 б.

# Г. САБИТОВНЫҢ “УРМАН КЫЗЫ ТАҢСЫЛУ” ХИКӘЯСЕНДӘ МИФОЛОГИК ОБРАЗЛАР

*Миңнеголова Р., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гайнуллина Г.Р.*

Татар балалар прозасында Габделхәй Сабитов гомумкешелек кыйммәтләренә йөз тоткан, идеологик яки үгет-нәсыйхәт басымыннан азат кече күләмле проза әсәрләре белән танылa. Эмоциональ-тәэсирле тел белән язылган лирик-моңсу хикәяләре психологизм, символлаштыру һәм мифлаштыру алымнарын, тирән фәлсәфи фикерләр һәм гомумиләштерүне куллану мөмкинлеге белән балалар әдәбиятының офыкларын киңәйтә. Язучының “Урман кызы Таңсылу” хикәясенә тукталыйк.

Сюжет сызыгы урман кызын табуга бәйле Булат – Кәли мөнәсәбәтләренә корыла. Әсәрдә аксакал карт архетипик моделе үзәкне били: “Сәер кеше бу Газизулла абзый. Гомере буе урманда яшәп тә, һаман күңеле урманнан бизмәгән” [2: 27]. Юкка гына аны язучы урман шүрәлесе белән чагыштырмый. Булатның да әтисе кебек урман серләренә төшенәсе, Карурман бабай җырын тыңлыйсы һәм Таңсылу белән күрешәсе килә. Ата кеше баласының күңел тәрәзәләрен ачарга ярдәм итә. Малайны табигать серләрен барлаганда озатып килә. Автор-хикәяләүче курай моңын, Карурман бабай җырына кушылып усак шаулавын ишеттереп алдан психологик эчтәлек дулкынына көйли. Әлеге урман җыры образына малайларның күңел җыры мәгънәсе дә салына. Усак агачы исә чыдамлык, каршылык һәм сабырлык, сизгерлек символына ишарә итә. Әйтерсең лә, язучы алдан ук табигать серләренә төшенер өчен үҗәт, тыныч холыклы һәм авырлыкларга бирешмәүчән булырга кирәклекне ассызыклый күк. Урман кызы Таңсылу барлыгын белү Булатны сихри серле табигать дөньясына алып кереп китә. Малайның Таңсылу белән урманда очрашуы юкка түгел. Урман – серлелек, билгесезлек символы, мөһим вакыйгаларның башкарылу урыны, анда геройлар еш кына көтелмәгән үзгәрешләр кичерә. Булат та кызны урманда очратып, икенчел сихри дөньяга, табигать кочагына чума. Үзен борчыган, кызыксындырган сорауларга җавап таба, гаҗәеп күрнешләргә тап була. Шулай ук, урман малайның күңел төпкелегендәге гамьнең тирәнлегенә ишарә ясый сыман, ник дигәндә Булат табигатьне ярата, аның һәр җәнлегенә, кош-кортына сак караштa. Язучы фикеренчә, “җыр яраткан, урман-кырларны яраткан, кошларны кызганган кеше ничек инде начар булсын!” Таңсылуны күрү өчен малай таң вакытында торып урманга аны эзләргә барырга тиеш була. Таң вакыты образы малай күңелендә яхшылык, кешелеклелек

башлангычының уянуын һәм күңел күзе ачылуын искәртә кебек. Чык бөртекләре символы белән автор кеше күңеленең нәфис, нечкә булуын аңлата. Шулай ук, чык эчкерсез, сафлык һәм чисталык мәгънәсен белдерә. Символик күренеш буларак, чык геройның төрле хис-кичерешләрен һәм күңел халәтен чагылдыруга хезмәт итә.

Ә Булатның исә Таңсылу белән бөре эчендәге яшь яфраклар шытканын тыңлавы күренешендәге бөре образы малайның күңелендәге хисләрнең “тууын”, “шытып чыгуын” һәм “ныгуын” сурәтли. Булатның яфракларның яруын шулкадәр нык күрәсе килә, шуның өчен ул хәтта ки юкә агачына үрмәли, аннары соң каен кәүсәсенә сарылып, каен суы акканын тыңлый. Әлеге “юкә” һәм “каен” символикалары аша малайның характеры, уңай холкы ачыла, ягъни Көнчыгыш һәм Көнбатыш мифологиясендә каен актылык, чисталык һәм гүзәллек символы буларак, ә юкә нәфислек, йомшаклык, дуслык символын, аның йөрәксыман яфраклары яхшылык белән ассоциацияләнә. Әлеге символлар мозаика сыман, малайның күңел халәтен, характерын тулы картина ярдәмендә күзалларга ярдәм итә.

Пейзаж элементы ярдәмендә язучы бала күңелендә туган хисләр өермәсенең тирәнлеге, бөтенлекле кичерелеше хакында сөйли. Булатның Таңсылу белән очрашуы аның күңелендә тагын да гаҗәеп хис-кичерешләр уята. Матурлык образын үзендә туплаган Таңсылу малайны матурлыкны аңлый, таный белергә өйрәтә, күңел ишегенең бикләре ачыла, ник дигәндә, чынлап торып матурлыкны күрә белмәгән Булат бу кызны шулкадәр чибәр, гүзәл итеп тасвирлый алмас иде. Таңсылу Булатны таң чыгыннан энҗе сәйлән тезәргә өйрәтә. Булат берсүзсез Карурман бабай кызына буйсына, тик ромашка чәчәгенең чык бөртегеннән сәйлән тезү генә җиңел булмый. Г. Сабитов кеше күңеленең кылларын энҗе сәйлән белән чагыштырып, күңел кыллары, күңелне аңлау, рух тибрәнешләрен тыңлау сабырлык, тырышлык һәм үҗәтлек сорый дип искәртә кебек. Күңел кылларының яңа тибрәнешләре Кәли белән Булатның фотосурәт төшерү һәм ясау вакыйгасында чагылыш таба. Һәммәсе дә әлеге фотосурәтләрне күреп, таң калалар. Беренче карашка гадәти булып күренгән әлеге кадрлар, лагерь балалары тарафыннан зур кызыксыну белән каршы алына, табигать манзараларына карата карашлары үзгәрә, күңел күзләре ачыла. Фотосурәтләрнең “Күңел күзе” газетасына урнаштырылуы – матурлыкны тояр өчен күңел күзе белән карау кирәк дигәнне аңлата. Күңел күзе ачылу – тормыш-чынбарлыктагы гади генә тоелган, күнегелгән күренешләргә яңа күзлектән карый алу, һәр мизгелнең матурлыгын тоя башлау, һәр вакыйга-гамәлнең сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуына төшенү ул, ди автор. Монда үзеңнең генә түгел,

башкаларның да күңел күзен ачарга мөмкинлек тудыру белән дә кеше бик бәхетле була ала дигән фикер тоемлана. “...Беренче рәсемдә шул кошчык. Ул бер куаклыкның иң түбәнге ботагына кунган да, канатларын җәеп, авызын зур ачып түбәнгә карап тора. Нәрсәгәдер борчылганы, нәрсәдәндер бик нык курыкканы әллә каян күренә.. Ә җирдә кап-кара агулы елан. Гаҗәп! Анысын Булат бөтенләй күрмәгән иде.. Икенче рәсемдә тагын да кызыграк хәл!.. Кошчык башка ботакка күчеп утырган. Бераз гына читтәрәк аның оясы. Ояда әле каурый чыкмаган дүрт кош баласы. Куак астыннан бер керпе чыгып килә. Елан, авызыннан ике япьле угын чыгарып, керпегә ташланырга тора... Өченче рәсемдә – кошчык тынычланып балалары янына барып утырган. Ә керпе бик тәмләп кенә елан ите ашап утыра” [2: 38-39]. Дөнья мәдәниятендә кеше җанын сурәтләүче кош образы еланга, төрки-татар мифологиясендә явыз, хәйләкәр һәм бик куркыныч дошман образына каршы куела. Ә керпе исә күп кенә халыклар мифологиясендә, халык әкиятләрендә зирәк, батыр, ярдәмгә мохтаҗ булганнарга булышучы уңай образ буларак гәүдәләнә. Шул рәвешле, керпенең кошны еланнан коткарып калуы, ул кешелек яшәешенең асылын ачып сала. Тормышта яхшылыкның, әлеге башлангычның һәрвакыт начарлыкны җиңүен тасвирлый һәм матурлыкның явызлыктан өстен булуын күрсәтә. Язучы балаларны һәрвакыт яхшылыкка омтылырга, күркәм гамәлләр кылырга өнди.

Шулай ук, малайларның әлеге фотосурәтләрне үзләре төшерүләрен әйтмәве, ул яхшылыкның кем тарафыннан кылынуы түгел, ә нинди файда китерүе, күркәм гамәл буларак бәяләнүе кебек аңлатыла.

Әсәр ахырында Карурман бабай сүзләре Газизулла абзый тарафыннан әйттерелә, язучының укучыларга киңәше булара бәяләнә: “Юк, балалар, урманда сез куркырлык бернәрсә дә юк. Шатланыгыз гына, сезнең күңел күзләрегез ачылган. Күңел күзе чыклы алан өстеннән күтәрелгән ак томанны да гүзәл урман кызы итеп күрә, карт имәнне дә серле дирижерга, җырчы Карурманга охшата. Менә инде хәзер минем күңел тыныч. Сез Карурман җырын ишеткәнсез. Кабат беркайчан да ул сезнең күңелегездән чыкмас. Саф күңелле кеше булып үсәрсез” [2: 42].

Шул рәвешле, Г.Сабитов үзенең геройларын тирә-юньдәге хозурлыкка күңел күзләре ачылу ноктасында сурәтли, кичерешләр чылбырын табигать сурәтенә, портрет, пейзаж элементларына, мифологик образ, мотивларга салып тезә. Хикәя романтик һәм лирик рух белән сугарылган.

**Әдәбият**


1. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. Өч томда. Т.1. – Казан, 2008; Т.2, Казан, 2009; Т.3. Казан, 2010.
2. Сабитов Г. Кайнар туфрак: Хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 160 б.
3. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 7 т.: 1985-2000 еллар / төз. Р.Ф. Рахмани / фәнни мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. – Казан: Фолиант, 2019. – 574 б.

# ГӨЛНУР АЙЗЕТУЛЛОВА ИҖАТЫНДА АНА ОБРАЗЫ

*Мөлекова Х., Буа ш., Вахитов ис. гимназия, IX сыйныф*
*Җит. – Исмәгыйлева Г.Т.*

Буа төбәгендә яшәүче танылган мөгаллимә Гөлнур Айзетуллова шигырьләре хис-кичерешләргә бик бай, алардан моң агыла. Шуның өчен дә шагыйрә матур-матур җырлар, шигырьләр, хикәяләр, повестьлар авторы буларак танылды. Җырларда туган як, ата-ана, мәхәббәт темасы үзәк урынны алып тора. Үзенчәлекле шигырьләренә күз салыйк.“Ана бәхете”

Бала – җылың,
Бала – йөрәк җырың,
Гасырларга барыр тавышы.
Бала!
Бала!
Барлык аналарның
Бәхетле һәм ачы язмышы!

“Әниемә багышлау” шигырендә сагыну да, матур теләкләр дә, ярату күренә.

Сагыну очкыннары
Тулы яшьләр
Шомырт күзләренә сыенган,
Йөрәгендә пакъ теләкләр туган –
Кайнар сәлам кече кызыңнан!

“Ходайның яраткан кешесе” шигыре каенанасы Нурданиягә багышлана. Хөрмәт, ярату, соклану, изгелек теләү дә чагыла.

Оныкларың безнең белән
Яшә, Әнкәй, тормышта!
Имин булсын килер көннәр –
Сөенечле, тыныч та!

Дөньяда яшәү мәгънәсен шагыйрә иҗатында еш күрергә була. Гаилә, әни җылылыгы да сизелә.

Бу җиһанда яшәү күңелле ме? –
Өең балалардан гөр килмәсә.
Күкрәгеңдә сыенып сабыйларың:
“Кадерлебез әни – син!” – димәсә.
( “Бу дөньяда яшәү нигә кирәк? шигыре)

Әниләргә карата горурлык хисе, наз, яшәү чыганагы икәнлеген күрергә була.

Әниле булганга гына
Бар дөньякөлеп тора.

Әни – өебез кояшы! –
Әти дә белеп тора.
(“ Әниләр булса җирдә” шигыре)
Каенаналарга хөрмәт, бары яхшы якларын гына күрү дә чагыла.
Газиз әниемә тиңләп сине,
Еллар кичә-кичә яраттым.
Үз әнием – тормыш күгем булса,
Син бит- минем талмас канатым!
(“Каенанам – канатым” шигыре)

Аналарның балаларга булган мәхәббәте, борчулары, шатлык-сөенечләрне дә күрә алабыз.

Мин дә, улым, читкә киткәч кенә,
Яшен тойдым Ана сагышының.
Яши-яши генә аңлыйбыз шул
Бар ачысын гомер агышының.
(“Ана сагышы” шигыре)
Хатын-кызны гөл белән чагыштыру да чагыла.
Гөл язмышы – хатын кызда,
Аңа наз һәм сөю кирәк.
Уйлыйм: тормышта да
Көткән бәхет кадерлерәк!
(“Бәхет гөле” шигыре)

Гөлнур Айзетуллова шигырьләрендә гаиләсенә, әти-әнисенә, иренә, балаларына булган мәхәббәт тә күренеп тора. “Алтын сәгать” поэмасы әнисе Рафига Гыйниятуллинага багышлана.

“Бала баласы, дип,
Балдан татлы”, -
Әйтүләре дөрес, күрәсең.
Балигъ булган көнне оныгыңа
Алтын сәгатеңне бирәсең!
Апам белән миңа эләкмәгән
Алтын сәгать – бүген кызымда.
Сәгать теле саный үткәннәрне –
Анда гомер юлың сузыла.

Ана белән бала бер-берсе өчен ничек кенә өзгәләнсәләр дә, дөньяда һәркемнең гомере чикле. Шагыйрә җиһандагы ак һәм кара төсләрнең алмашып торуын искәртә. Ананы югалтудан күңел сызлана, әрни, юксына.

Алтын сәгать , әнә, әниеңнең
Барлый соңгы тапкыр сулышын.
Җиде айдан бирле түшәктә ул –

Күз яшьләрең тама тулышып.
Иң-иң газиз кешең китә җирдән,
Озатуы бигрәк авыр ла.
Якыннарның каберләре арта
Каеннарга күмелеп авылда.
(“Алтын сәгать” поэмасы)

Һәр кешедә изгелек, илаһилык башлангычы бар. Әлеге изгелек безгә әниләрдән күчәдер.

Гөлнур Айзетуллова үзенең әнисе һәм каенанасын гомер буе зурлый. Аларга карап соклана, горурлана. Шуңа күрә әнисе өчен борчылу, аның гомерен ничек булса да озынайту, әнисе булган өчен чиксез сөенү хисе барлык шигырьләрендә дә бар диярлек.

# ТАТАР ПАРЕМИОЛОГИЯСЕНДӘ АТА-АНАЛАР ҺӘМ БАЛАЛАР ТУРЫНДАГЫ МӘКАЛЬЛӘР

*Мөхәммәтҗанова А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Мөгътәсимова Г.Р.*

«Ата-аналар һәм балалар» каршылыгы буыннар арасындагы конфликт буларак карала ала. Галимнәр язганча, мондый конфликт гомумән кешелек өчен хас, гаилә эчендә мондый конфликтлар булуы табигый. Балаларга аталарның кыймматләренә тәнкыйди күзлек аша карау хас, балалар үз кыймматләрен табу аша үзләрен табарга омтылалар» [1: 159].

Билгеле булганча, шактый озак дәвердә татар гаиләләре патриархаль-дини гаилә буларак яши. Ә патриархаль гаиләләрдә гадәттә балалар аталар эшен дәвам итүче, нәселне дәвам итүчеләр буларак кабул ителә. Мондый күренеш, ягъни патриархальлек инкыйлабка кадәрге татарлар тормышына да хас була. Инкыйлабка кадәр гаилә коруның төп максаты – нәселнең дәвам ителешен тәэмин итү, ә гаиләнең иң мөһим функциясе балалар тудыру һәм аларны тәрбияләү саналган. «Халык күзаллавында ата-аналык хәләл гамәл саналган, шуңа күрә баласыз гаиләләрнең статусы җәмгыятьтә бик түбән булган», – дип яза Г.Б. Сайфутдинова [4: 15]. Бала табу, аңа үз һөнәреңне тапшыру, аталар эшен дәвам итү үстерү идеяләре түбәндәге мәкальләрдә күренә:

1) Атадан бала туар, Атасының юлын куар [3:14].
2) Алты көн ач булсаң да, ата гадәтен ташлама [3:14].
3) Атаң кем булса, син шуның угылы [3:14].
4) Аттан тай узар, Атадан бала узар [3:14].

Традицион татар гаиләсендә тәрбия эше нигездә аналар тарафыннан гамәлгә ашырылган һәм ашырыла. Гаиләдә ана – иң олы һәм иң изге шәхес. Ананы изгеләштерү хатын-кызның зур авырлыклар белән дөньяга яңа кеше тудыруы, зур мәшәкатьләр белән аны аякка бастыруы, олы мөстәкыйль тормышта үз кыйбласын таба алуы өчен җаваплылык хисе тоюы, бала бәхете өчен иң зур авырлыкларга да түзә алуы белән аңлатыла. Аналар һәм бала мөнәсәбәтләре мондый мәкальләрдә чагылыш таба:

1) Алып анадан туар, аргамак биядән туар [3:14].
2) Ханнан бала олы, Баладан ана олы [3 :14].

Халык гаиләдә атаның урынын да югары бәяли. Ата белән угыл мөнәсәбәтләренә караган мәкальләрнең күплеге шулай төрле факторлар белән аңлатыла. Ирләрнең яшәешне алып бару өчен төп көч булып торуы; илне яклау өчен көчле, батыр ирләр тәрбияләү әһәмияте;

ир бала туган очракта гына крестьян гаиләсенә җир бүлеп бирелү; картлык көнендә ата-ананың малайларның гаиләсе карарга тиешлеге – шуларның кайберләре генә. Мәсәлән:

1) Улның ояты атага, Кызның ояты анага [3:10].

2) Атадан яхшы ул туса, Кар өстендә ут ягар; Атадан яман ул туса, Ат өстендә эт кабар [3:12].

3) Аталы бала – ардаклы бала [3:13].

Татар паремияләрендә «ата-ана һәм бала» биномын лингвомәдәни яссылыкта тикшерү кайбер каршылыклы фикерләрнең барлыгын да күрсәтә. Бер яктан, бала – ирекле шәхес, гаилә алдында бурычлары булса да, тормышын үзе теләгәнчә кора алырга хокуклы шәхес буларак бирелә:

*Бала – безнеке, акылы – үзенеке* [3:8].

Әмма мондый ирекле шәхес тәрбиясе бала чактан үзеңә үзең хуҗа, үз теләкләреңне, омтылышларыңны таный белә торган кеше тәрбияләүне күздә тота, ата-ана сүзе белән генә яшәргә өйрәнгән бала үскәч чын мәгънәсендә мөстәкыйль шәхес буларак яши алмаячагы ачык билгеле. Хөрлектә, үзен чын шәхес итеп тоярдай бала тәрбиясе һәр гаиләдә дә тормышка ашырылмый. Мәсәлән:

*Атай барда атай баш, Атай юкта анай баш, Анай юкта апа баш, Апа юкта үзем баш* [3:8].

Әлбәттә, ата, ана, апа сүзләренең әһәмияте, аларга колак салу кирәклеге инкарь ителми, әмма, безнең фикеребезчә, бүгенге демократик мөнәсәбәтләргә нигезләнгән гаиләдә кеше үзен иң беренчеләрдән баш итеп санарга тиеш. Мәкальдән аңлашылганча, киресенчә, иң соң дәрәҗәдә – ата, ана, ападан соң гына бала үз теләген, үз ихтыяҗын әйтү хокукына ия булган гаиләләр дә бар.

Мәкальләр җыентыгының (төзүчесе Нәкый Исәнбәт) «ата-ана, аларга хөрмәт» бүлекчәсендә бирелгән мондый мәкаль дә теркәлгән:

*Йомырка тавыкны өйрәтми* [3:7].

Биредә бала – йомырка, ата-ана – тавык образы аша бирелә.

Йомырканың тавыкны өйрәтә алмавы, аның гомумән әле җанлы дип тә атала алмавына нисбәтле бала да ата-ана, олылар кушуы буенча яшәргә тиеш, дигән фикер җиткерелә.

Ата-ана һәм балалар конфликты гомер-гомергә сакланып килгән. Мондый конфликт табигый дип, ассызыклый галимнәр. Татар тарихына күз салсак та әлеге конфликтларга тап булабыз. Заман үзгәргән саен яңа кыйммәтләр барлыкка килә һәм шуның нәтиҗәсендә каршылыклар да килеп чыга.

**Әдәбият**

1. Биктагирова З.А. Лингвокультурологические особенности паремий о семье (на материале английского, турецкого и татарского языков) // Вестник Чувашского университета. Гуманитарные науки – Чебоксары: Чувашский университет, 2006. – №5. – С. 107–112.

2. Горбань И.В. Роль паремий в речевых актах (на материале языка русской художественной литературы): дис. … канд. филол. наук. – Краснодар: КубГУ, 2010. – 196 с.

3. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 2 т. 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 748 б.

4. Сайфутдинова Г.Б. Мир детства у татар: обряды и практика социализации: автореферат дис. ... канд. ист. наук. – Саранск, 2011. – 22 с.

ТАТАР ХАЛКЫНДА ЧӘЙ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Мөхәммәтшина А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Россиядә чәйнең барлыкка килүе турында күп фикерләр яшәп килә. Бүгенге көндә гомум кабул ителгән версия буларак, аның халыкта XVII гасырның беренче яртысында таралуы искәртелә.

Татарлар чәйне Россия империясе халыклары арасында беренчеләрдән булып беләләр. Моңа туган төрки халыклар белән тыгыз бәйләнешләр дә, Казанның сәүдә юллары чатында урнашуы да тәэсир итә. Тарихчылар Болгар сәүдәгәрләре чәйне XII гасырда ук гарәпләрдән Урта Азиягә товар алырга барганда татып караган, дип фикер йөртәләр. Анда чәй Кытайдан Бөек Ефәк юлы аша үтеп кергән. Ләкин сынаудан ары эш бармаган: татарлар чәйне күпкә соңрак белгәннәр.

XVII гасырда чәй Мәскәү патшасы өстәленә эләгә – 1618 елда кытай илчесе Михаил Федорович Романовка бүләк итеп берничә сандык киптерелгән яфраклар китерә. 1638 елда чәй Монгол ханы Алтын «бүләге» аша рус өстәленә үтеп керергә яңа омтылыш ясый, ул патшага 100 кеш бәясенә тигез булган дүрт пот чәй җибәрә. Мәскәүдә чәйне аңлап бетермиләр, шуңа да еш кына «үлән каты, начар чәйнәлә, тәме ачы», – дип хисап биргәннәре билгеле. Аннары бүләк алып килгән бояр Старков үләнне суда пешерергә кирәклеген хәбәр итә һәм, ниһаять, аны дөресләп эчә башлыйлар. Боярларга һәм патшага чәй ошый, әмма дүрт пот тиз эчелә, яңа керемнәр көтелми, һәм аның турында тагын унбиш елга онытыла.

1665 елда кытай чәйе белән (аны илче Иван Перфильев алып килә) патша Алексей Михайловичның ашказаны авыруын дәваларга тырышалар. Патшага нәрсә ярдәм иткәне төгәл билгеле түгел, әмма чәйне шунда ук шактый шифалы эчемлек дип атаганнар. XVII гасырда Россиядә чәйне бары тик затлы һәм бай кешеләр генә эчкән, XIX гасырга ул җәмгыятьнең барлык катламнарына таралган. Казан исә аны сата башлаган беренче шәһәрләрләр арасында булган. Моңа кадәр анда җимеш суы (киптерелгән җиләк-җимеш һәм җиләк-җимеш төнәтмәсе), сбитень – «бал ширбәте» (бал һәм тәмләткечләр өстәлгән су) һәм, әлбәттә, кайнар (кыш көне) һәм салкын килеш эчелә торган сөт ярдәмендә ясалган эчемлекләр популяр булган.

Чәй татар халкына тиз генә кулланылышка кереп китә алмый. Башта аның кыйммәтлеген исәпкә алып, сәүдәгәрләр, руханилар кебек халыкның югары катламнары кешеләре генә кулланган. Мондый чәй белән Казанга килгәч, Бөек Екатеринаны сыйлаганнар. Гади халык исә такта чәй эчкән. Мондый чәйнең тәме бик ачы һәм көчле булган, шуңа

күрә аны кайнатканда сөт белән сеңдергәннәр. Бу эчемлекнең тәме катыкка охшаш булган [4]. Моннан тыш, сөтле чәй куллану Европадан алынган булырга мөмкин. Чәйдән тыш, татар тормышына кофе да кергән, һәм ике чит ил эчемлегенә дә сөт өстәгәннәр.

Татарлар элек-электән бик кунакчыл халык буларак танылган. Алар өчен кунакларны дөрес кабул итү генә түгел, ә аларның күңеленә һәм теләгенә туры килә торган ризыклар-эчемлекләр сайлау да мөһим булган. Русларның «Уважить гостя по-татарски» дигәне дә чәй эчүне аңлаткан сүз. Бу сүзләр гади кешеләр өчен генә түгел, ә дәүләт дәрәҗәсендәге сөйләшүләр өчен дә тирән мәгънәгә ия. Шуңа күрә мондый чәй эчкәндә кешеләрнең тормышыннан алып сәяси яңалыкларга кадәр сөйләшергә мөмкин. Татарча чәй эчүнең үзенчәлеге аның экстравертлыгы – анда эчемлек эчү дә, сөйләшү дә тигез хокуклы, чөнки ул дуслык һәм ышаныч мөнәсәбәтләрен формалаштыруга юнәлдерелгән. Мондый чәй эчүнең аналогы инглизләрнең «five o’clock tea» гына булырга мөмкин. Татарлар чәйне шактый озак – берничә сәгать эчәргә күнеккәннәр (самовАрның күләме ким дигәндә ике чиләк!). Ләкин үз үзенчәлекләре дә бар: әгәр хуҗаның буш вакыты булса, кунакка кәсәнең яртысыннан артыгына (традицион рәвештә пиала – тәбәнәк, түгәрәк савыт) салалар, еш-еш өстенә яңартып, кайнар су өстиләр. Әгәр дә ул каядыр ашыга икән, кәсәне тулысынча чәй белән тутырганнар, бу исә хуҗаның эш белән мәшгульлегенә һәм сәфәрнең чикле булуына ишарә иткән.

Чәй тантанасын үткәрү өчен һәр кунакка ашамлыклар белән тәлинкә, пиала/кәсә һәм чәй кашыгы (бал кашыгы), аш кашыгы һәм тезгә салфетка (тастымал) бирергә кирәк булган. Дини ышанулар буенча, өстәлдә чәнечкеле кисү әйберләре булырга тиеш түгел. Татлы ризыклардан иң ятратканнары исә чәк-чәк, җиләк-җимеш (йөзем, күрәгә), кайнатма, кош-теле, бал һәрвакыт өстәл өстендә булган.

Татар чәенең уникаль тәменнән тыш, бик күп файдалы үзлекләре дә бар. Ул йокысызлыктан (ике кашык бал өстәргә кирәк), салкын тиюдән (бал һәм кура җиләге белән), эчәк авыруларыннан (каты чәй), шулай ук иммунитет түбән булганда ярдәм итә һәм организмга стресснын тискәре йогынтысын киметә. Ә сөт һәм май традицион чәйнең үзенчәлеге булып тора [1].

Электән татарлар чәйне пешерү процессына бик җитди, төгәл караганнар. Алар башта суны самоварда кайнатырга кирәк, аннары чәй яфраклары һәм сөт өстәргә кирәк дип тапканнар. Бу катнашманы биш минут чамасы кайнаталар. Аннары эчемлекне тозлап, анда бер кисәк май куеп, кәсәләргә салырга кирәк. Алмалы чәй дә таралган күренеш,

аңа киптерелгән җиләк-җимеш, мәтрүшкә, мелисса, бөтнек һәм хәтта кара җимеш яфраклары да өстәлә. Гадәттә чәйне хуҗа үзе сала.

Бүгенге көндә дә татарларда чәй, чәй эчү процессы актуальлеген югалтмый. Ләкин аны ясау күпгә гадирәк кабул ителә. Соңгы 3-5 елда гына төрле җиләк-җимеш, яфраклар белән чәй әзерләү популярлашып китте.

Тәме һәм составы буенча чәй эчемлеге нинди генә булмасын, татарларда чәй эчүнең бизәге – яхшы сөйләшү. Бу вакыт эчендә чәй суынырга өлгерә, аны кайнарга алыштыралар, ә сөйләшү дәвам итә, ул гаилә кыйммәтләрен ныгыта һәм халыклар дуслыгына ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. Зверева М. Сначала боялись, потом лечились. История татарской чайной церемонии // Аргументы и факты. Kazan.aif: [сайт]. – URL:https://kazan.aif.ru/society/snachala_boyalis_potom_lechilis_istoriya_tatarskoy_chaynoy_ceremonii (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.01.2024. )
2. Особенности татарского чая и лучшие рецепты приготовления // Prochayok: [сайт]. – URL: https://prochayok.ru/etnicheskij/tatarskij-chaj.html (мөрәҗәгать итү вакыты: 11.01.2024).
3. Семенов В. М. Все о чае и чаепитии. Новейшая чайная энциклопедия. – М.: Флинта, 2006. – 464 с.
4. Фомина Д. Ясно-понятно. Почему татарское чаепитие – особенное // Инде: [сайт]. –URL: https://inde.io/article/27904-yasno-ponyatno-pochemu-tatarskoe-chaepitie-osobennoe (мөрәҗәгать итү вакыты: 22.01.2024).

# ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ГАИЛӘЛӘРЕНДӘ ЭНДӘШ СҮЗЛӘРНЕ КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Мөхәммәтшина Д., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәлахова Р.Р.*

Эндәш сүзләр тел белеменең синтаксис өлешендә өйрәнелә. Грамматика дәреслекләрендә әлеге синтаксик берәмлекләр турында теоретик мәгълүматлар җитәрлек бирелгән. Шулай булуга карамастан, эндәш сүзләрнең милли-мәдәни үзенчәлекләре тел белеменең актив өйрәнелә торган мәсьәләләреннән санала.

Сайлап алынган тема хәзерге тел белемендә актуаль, чөнки ул милли традицияләрнең яшәеше, милләтнең тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә корылган. Бу хәл теге яки бу халыкның социаль үсеше, иҗтимагый тормышы, гореф-гадәтләре, тарихи үсеше, хәтта географик торышына да бәйле дип уйлыйбыз.

Төрки телләрдә, аерым алганда, татар һәм башкорт телләрендәге туганлык атамаларын өйрәнү XXI гасыр башына туры килә. Татар телендә бу юнәлештә Д.Б. Рамазанова, А.Г. Казиханова, Ә.Ш. Йосыпова һәм Э.Н. Денмухаметоваларның, башкорт телендә Р.С. Акманова, Г.Н. Ягафарова, Л.Р. Сөләйманова, Р.М. Исанаманова һәм Г.Р. Абдуллина кебек галимнәрнең хезмәтләре билгеле.

Эндәш сүзләр бик күптөрле стильләрдә (хатларда, лозунгларда, матур әдәбиятта һ.б.) кулланыла, әмма аның иң күп кулланылган урыны – диалоглар [4: 162]. Сөйләүче, тыңлаучыга, үзенә, өченче затка мөнәсәбәтен төрле зат, тартым кушымчалары, зат алмашлыклары, эндәш сүзләр белән белдерә.

Сөйләм һәрвакыт кемгәдер төбәлгән, багышланган була, шуңа күрә сөйләмдә эндәшүнең роле бик мөһим, чөнки ул әңгәмәдәшләр арасында бәйләнеш һәм төрле мөнәсәбәтләр барлыкка килүгә сәбәпче була.

Татар һәм башкорт телләрендә эндәш сүзләрнең үзенчәлеге булып туганлыкны белдерә торган терминнарны актив куллану тора. Эндәш сүз булып кеше исемнәре, шәхескә эндәшү сүзләре, кош-корт, хайваннарны, табигать күренешләрен, төрле җансыз әйберләрне атаучы сүзләр килә. Без исә татар һәм башкорт гаиләләрендә кулланыла торган эндәш сүзләргә тукталдык.

Әлеге чыгышта без татар һәм башкорт гаиләләрендә кулана торган эндәш сүзләрнең үзенчәлекләрен күрсәтүне максат итеп куйдык.

Ике телне чагыштырып тикшерү һәр телнең аерым үзенчәлекләрен, ике тел арасындагы уртаклыкларны билгеләргә

мөмкинлек бирә. Тугандаш телләрне чагыштырып өйрәнү, эндәш сүзләрнең этимологиясен ачыклау юнәлешендә дә кызыклы нәтиҗәләргә килергә мөмкин.

Гаиләдә туганлык терминнарын куллану буенча татар һәм башкорт телләрендә охшашлыклар да, аермалыклар да ачык күзәтелә. Мәсәлән, татар һәм башкорт гаиләләрендә бала әнисенә *әни, әнкәй, әнием, анакаем, анакай, әсә, әсәй, инәй инәки*(диалект.), әтисенә *әти, әткәй, әтием, атакаем, атай, әтки* (диалект.) дип эндәшә. Ата-ананың олы туганнарына *әбей, бабай (бауай*), ә кече туганнарына *апай* яки *агай* дип әйтү каралган.

Башкортларда энеләренә *энем, энекәш, туганым* яки *мырза* дип, ә сеңелләренә *кәрендәш, сеңелкәш* яки *сылуым*, олы абыйларына *агай*, олы апаларына *апай*, дип эндәшәләр. Шулай ук әти-әнинең сеңелесенә дә *апай* диләр, киленгә *еңгәй*, кияүгә *езнәй* дип мөрәҗәгать итү кертелгән. Югарыда әйтелгән туганлык атамаларына сирәк кенә исемнәре дә кушылып китәргә мөмкин. Татар телендә дә *энем, энекәш* сүзләре кулланыла, шуның белән беррәттән, диалектлардла *апаем, наным, нәнәм* кебек вариантлар да күзәтелә.

Эндәш сүзләрнең милли-мәдәни үзенчәлекләрен өйрәнү барышында диалекталь лексикага күзәтү ясау аеруча кызыклы булып тора. Әйтик, Д.Б. Рамазанова мондый күзәтүләре белән уртаклаша: сергач сөйләше каенегә эндәшү сүзләренең составы белән аерылып тора. Башка мишәр сөйләшләрендә иренең энесенә зурлап, яратып *кеwәз абзикай, шәкерт абзий, абызагай, күркле морза* дип эндәшү гадәткә кергән булса, сергач сөйләшендә төп сүз ролендә *йанагай, йегет* (чагыштыр: себер диалектларында *егет* – бала, малай) сүзләре йөрүчән: *сылу дҗанагай, мулла дзанагай, севәр дҗанагай, яки күөркле йегет, сылу йегет, ак* (русча: благородный) *йегет* һ.б.лар. Сергач сөйләшенең үзенчәлеге итеп тагын *тутак* – әдәби телдә *туташ* – кыз кешегә мөрәҗәгать итү формасы, *татарым* – ирем сүзләрен дә күрсәтергә мөмкин, алар башка мишәр сөйләшләрендә күзәтелмиләр [2: 100].

Эндәш сүзләрнең структурасын карасак, алар арасында гади сүзләрне дә, мәсәлән: *атай, әсәй, кыҙ, ул, ағай, авзый, апай* һ.б. лар, кушма нигезлеләрен дә күрергә мөмкин: *олатай, өләсәй, байбикә, байбисә, балтутәй, абызәней* һ.б.лар. Тезмә терминнар булып исә *бабур еңгә, бағым бала, аҡ бейем* һ.б.лар тора. *бай-бетсә, ағай-эне, ата-баба, ата-әсә* кебек парлы терминнарны күзәтелә [3: 70].

Рус һәм татар телләреннән үзгә буларак, башкорт телендә әни ягыннан булган әби-бабайга *өләсәй, олатай*, ә әти ягыннан булганнарга – *картәсәй* һәм *картатай* дип эндәшәләр [1: 15].

Татар телендә туганлыкны белдергән эндәш ролендә кулланыла торган башка сүзләр: *каен сеңеле* – ирнең сеңлесе; *кайнши* – хатының энесе; *җиңги, җиңгәчә* – абыйның хатыны; *җизни, җизнәкәй* – апаның ире; *баҗай* – бертуган апа һәм сеңелнең ирләре.

Башкорт сөйләм этикетының кызыклы үзенчәлеге булып ерак туганнарга мөрәҗәгать итәр өчен максус терминнар булуы тора. Мәсәлән: *ак әби* – әнинең абыйсының хатыны, *ак бабай* – әнинең абыйсы. Алар, әлбәттә, аеруча зур хөрмәт итү, олылауны белдерәләр һәм туган булмаган кешеләргә дә карата кулланыла алалар. Шулай *ук чибәр әби, чибәр бабай, бал әби, бал бабай, алма апай* кебек эндәшләр дә кулланыла. Соңгылары татар телендә дә актив кулланылышта: *дәү абый, дәү апа, нәни абый, нәни апа, тәти апа, алма апа, матур апа, чәчәк апа* һ.б.ш.

Мисаллардан күренгәнчә, аралашуда милли мәдәниятнең үзенчәлекләре ачык чагыла. Безнең карашка, татар телендә дә, башкорт телендә дә эндәш сүзләрнең, аерым алганда, гаиләдә кулланыла торган туганлык атамалары бай һәм күпкырлы.

**Әдәбият**


1. Валеев Д.Ж. Нравственная культура башкирского народа: прошлое и настоящее. – Уфа, 1991. – С. 10-15.
2. Рамазанова Д.Б. Терминология родства и свойства в татарском языке. В 2-х книгах. – Казань: Тат. кн. из-во, 1991, – 189 с.
3. Солтанов Ф.Р. Некоторые особенности коммуникативного поведения татар и башкир // НКСРО народов СССР. – М.: Наука, 1982. – С. 101-111.
4. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – III. т. – 162 б.

# «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫ ЯЗМАЛАРЫ БАШИСЕМНӘРЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Мөэминова Г., КФУ, III курс студенты*
*Фән.җит. – филол. фән. канд., доц. Мөгътәсимова Г.Р.*

Вакытлы матбугатның дәүләт, җәмгыять тормышындагы роле бәяләп бетергесез зур. Газеталарга игътибар, шул исәптән, фәнни игътибар кимеми. Тел белемендәге тикшеренүләрнең бер юнәлешен башисемнәр бирелеше, аларны функциональ яктан классификацияләү тәшкил итә.

Башисем медиатекстның төп элементларның берсе булып тора. Үзенең тышкы гадилегенә дә карамастан, башисем чынбарлыкның төрле якларын чагылдыра, шулар рәтендә: авторның шәхси приоритетлары, редакция позициясе, сәяси һәм идеологик карашлар, мәдәни кыйммәтләр һ.б.лар. Башисемнәрнең вакытлы матбугаттагы роле бигрәк тә С.М. Гуревич тарафыннан тәфсилле өйрәнелгән. Галим болай дип яза: «Газета язмаларының башисемнәре – дизайнының аерылгысыз элементы. Вакытлы матбугат басмасының «йөзе» күп очракта аларның характеры һәм формалашу үзенчәлегенә бәйле. Башисемнең төп вазифасы – укучының игътибарын җәлеп итү. Башисемнәр укучыга яңа номерның эчтәлеге белән тиз арада танышырга, язмаларның ни-нәрсә турында булуын аңларга, тәкъдим ителгән мәгълүматта нәрсәнең мөһим икәнлегенә төшенергә ярдәм итә» [2: 125]

«Ватаным Татарстан» газетасы Татарстан Республикасы тормышына кагылышлы актуаль проблемаларны төрле аспектларда яктырта белүе, журналистларның сүз куәтен белеп, тоеп эш итүләре белән аерылып тора.

Н.Е. Бахарева, В.М. Ваняркина, Д.З. Гоциридзе, Н.А. Кожина Е.Н. Комарова, О.А. Ляпина, В.М. Ронгинский, О.С. Толомасова Г.Г. Хазагерова, А.А. Ягодова һәм башка галимнәр газеталардагы башисемнәрнең өч вазифасын аерып караганнар: номинатив, мәгълүмати, прагматик. Номинатив вазифа ул – башисемнең текстны атавы. Бу очракта исем тулаем эстәлекне ача. Башисемнең мәгълүмати вазифада килүе ул – кыска формада текстның төп эчтәлеген белдерү.

Әгәр язманың баш исеме текстны укырга җәлеп итеп, укучыга йогынты ясаса, бу прагматик вазифа була.

Язмаларның башисемнәренең төп вазифаларының берсе рәтендә галимнәр мәгълүмат бирү һәм эчтәлекне чагылдыруны атыйлар. Әлбәттә, күпмедер дәрәҗәдә бу вазифа һәрбер башисемгә хас. Әмма аерым башисемнәрдә ул әйдәп баруы белән аерылып тора. Мондый

башисемнәрне тулы мәгълүматлы башисемнәр дип атыйлар. Мондый мисалларны яңалыклар турындагы, дини тематикага караган мәкаләләрдә, ягъни укучы өчен җитди темаларга язылган язмалар белән эшләгәндә очратырга була. Мәсәлән, «Дин хатын-кызларны олылый» (Ватаным Татарстан, 2023, 3 март); «ВТ» бүләкләре Кукмара, Зәй һәм Сабага китә» (Ватаным Татарстан, 2023, 27 гыйнвар).

Тулы мәгълүмат бирми торган башисемнәр (неполноинформативные) “тезисны тулы дәрәҗәдә хәбәр итмиләр, кайбер очракта сөйләм предметы турында сигнал гына бирелә. Аларның мәгълүматны җиткерү куәте азрак булса да, укучыларны җәлеп итү ягыннан мөмкинлекләре күбрәк” [Ергалиев, интернет-ресурс]. Кайбер мисалларга туктап китик: “*Яз тәэсире*” [Ватаным Татарстан, 2023, 11 март: 1].

Аңлашылганча, биредә беренче очракта сөйләм предметы хәбәр ителә, әмма бу тәэсирнең кемгә юнәлгәне дә, уңай (яз тәэсирендә матур тойгылар уяну) яки тискәре (яз көне психик авыруларның көчәеп китүе) булуы турында да хәбәр ителми.

Өстәмә вазифалар, галимнәр ассызыклавы буенча, мәҗбүри саналмый, әмма шушы вазифаларда килгән баш исемнәрнең укучыны җәлеп итү, аңа тәэсир итү ешрак күзәтелә. Мондый башисемнәр арасында ике төрле вазифа башкара торганнарын аерып карау кирәк: 1) автор бәясен чагылдыра торган башисемнәр; 2) сәнгатьчә чаралар ярдәмендә укучыны җәлеп итә торган башисемнәр.

Автор бәясен чагылдыра торган башисемнәргә мисаллар китерик: «Рәхмәт, укытучы!» (Ватаным Татарстан, 2023, 3 март).

Биредә этикет сөйләменә караган сүз, җөмләнең тойгылы итеп бирелүе журналистның әлеге һөнәр иясенә тирән ихтирамын күрсәтә.

Икенче очракка түбәндәге мисалны күрсәтеп булыр иде: «Бердәм көч тау күчерә» (Ватаным Татарстан, 2023, 14 март)

Сәнгатьчә чаралар ярдәмендә укучыны җәлеп итә торган башисемнәр укучының игътибарын яулау вазифасында гаять төрле чараларга мөрәҗәгать итәләр. Аеруча да еш очрый торганнардан риторик сорауларны атап булыр иде. Ул аналитик текстка эмоциональ яңгыраш бирә. Мондый алым коммуникатив тәнәфес (перерыв) тәэмин итә. Мәсәлән, «Кая бара бу дөнья?» (Ватаным Татарстан, 2021, 6 гыйнвар).

Корылыш алымнары һәм чараларына нисбәтле рәвештә М.И. Шостак башисемнәрне алты төргә аерып карый [4: 44]. Алга таба шуларны карап, һәрберсенең функциясе һәм корылыш үзенчәлекләрен «Ватаным Татарстан» газетасы мисалында анализлыйбыз.

Башисем-хрониканың вазифасы – язмадагы иң төп, әһәмиятле мәгълүматны атау: «Татарстанда – капиталь төзекләндерү» (Ватаным Татарстан, 2023, 28 февраль).

Башисем-резюме нинди дә булса вакыйга турында турыдан-туры әйтмичә генә хәбәр итә: «Тыңлап та була, карап та» (Ватаным Татарстан, 2023, 18 февраль).

Башисем-цитатаның төп вазифасы – чыннан да, нинди дә булса атаклы яки җәмгыять, газета аудиториясе өчен кызыклы шәхес әйткән сүзләрне, фикерне, хәбәрне турыдан-туры җиткереп, укучыларны язманы укырга этәрү. Мәсәлән, «Илдар Гыйльметдинов – җанисәп турында: «Милләтеңне күрсәтү – йөрәк эше»» (Ватаным Татарстан, 2021, 6 гыйнвар).

Башисем-интрига, сенсация фактны өлешчә генә атап, укучыны кызыксындыра һәм язманы укырга мәҗбүр итә. Мисалга күз төшерик: «Балага каеш кирәк!» (Ватаным Татарстан, 2023, 11 март).

Башисем-лозунг, чакыру, мөрәҗәгать. Мондый башисемнәр төрле темага караган язмаларны исемли: сәяси, әхлакый, дини язмаларда, күзәтүебез буенча, аеруча ешлык белән аерылып тора. Кайбер мисалларны китерик: “*Бүгеннән әзерләнәсе*” [Ватаным Татарстан, 2023, 10 март: 11]

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Ватаным Татарстан» газетасы мисалында газета язмаларының башисемнәренең әһәмияте күрсәтелде. Функциональ аспектта алар мәгълүмат бирү, язманың эчтәлегенә ачыклык кертү, номинатив, реклам кебек вазифаларны башкаралар. Корылыш үзенчәлекләре ягыннан «Ватаным Татарстан» газетасы журналистлары башисем-цитата, башисем-хроника, башисем-резюме, башисем-мөрәҗәгать кебек төрләрне кулланулары ачыкланды.

**Әдәбият**

1. Гарифуллин В.З. Лингвостилистическая система татарского газетного текста: автореф. дис. ... док. филол. наук. – Казань, 1998. – 50 с.

2. Гуревич С.М. Газета: вчера, сегодня, завтра. Учебное пособие для вузов. – М.: Аспект Пресс, 2004. – 288 с

3. Низамов И.М. Функционирование и развитие татарской речевой системы в массовой коммуникации: автореф. дис. ... док. филол. наук. – Казань, 1996. – 50 с.

4. Шостак М.И. Журналист и его произведение: практическое пособие. – М.: ТОО “Гендальф”, 1998. – 96 с

# ЛИНГВОСТРАНОВЕДЕНИЕ КАК НАУКА

*Муртазина Г., КФУ, студент IV курса*
*Науч. рук. – кан. филол. наук, доц. Ашрапова А.Х.*

В последнее время обращение к проблемам изучения иностранного языка и культуры приобретает все большее значение. Овладение иностранным языком неразрывно связано с приобщением к иноязычной культуре. В свою очередь лингвострановедческий материал является составляющей частью при обучении иностранному языку.

Ранее до использования термина «лингвострановедение» применяли термин – «страноведение». Страноведением лингвисты называли культуру страны, которая была включена в процесс обучения иностранного языка. Однако название «страноведение» являлось общим для всех аспектов, что изучало культуру страны, пока лингвисты не столкнулись с такими проблемами как: потребность изучения языка в тесной связи с культурой страны, а также связь языка и культуры.

В рассмотрении этих проблем большой вклад внесли ученые и лингвисты О.С. Ахманова, Н.Г. Комилев, Е.М. Верещагин, В.Г. Костомаров и Т.Д. Томахин. Они пришли к такому мнению, что страноведение изучает историю страны, географию, традиции и т.д. Ввиду этого, от страноведения в широком смысле слова, начали отличать страноведение в узком смысле, как часть лингводидактики. Тогда лингвисты и исследователи в 1971 году, а именно Е. М. Верещагин и В. Г. Костомаров, ввели в литературу термин «лингвострановедение» и стали употреблять два термина: «лингвострановедение» и «страноведение». Языковеды предложили использовать термин «страноведение», когда говорится про культуроведческую специфику. А когда речь идет о лингивистическом и языковом аспекте использовать новый термин «лингвострановедение».

По мнению Е. М. Верещагина и В. Г. Костомарова, «лингвострановедение» – это аспект методики преподавания иностранных языков, в котором учащиеся изучают культуру страны, ее традиции через язык [2]. Однако помимо этого понятия, существуют различные трактовки термина «лингвострановедение», которые дают понимание о предмете «лингвострановедение».

Например, по мнению Г. Д. Томахина «лингвострановедение» – это лингвистическая дисциплина, поскольку Г. Д. Томахин считает, что предметом лингвострановедения являются факты языка, которые

знакомят с особенностями национальной культуры, а задача кроется не в том, чтобы узнать культуру через слово, а использовать знание культуры, т.е. фоновые знания для того, чтобы раскрыть значения слова и обеспечить правильное понимание при общении с другими [5: 64-69]. Иными словами, для Г. Д. Томахина именно лингвострановедение знакомит людей с культурой страны изучаемого языка и погружает их в языковую среду. Он подразумевает, что намного эффективнее изучать язык через знания культуры страны. Благодаря этому люди смогут понимать, какую лексику использовать в той или иной ситуации.

Р. К. Миньяр-Белоручева и О. Г. Оберемко утверждают, что лингвострановедение включает национальные реалии и фоновую лексику, а также термин «лингвострановедение» был переведен с французского термина «язык и культура» [4]. То есть, в их понимании, благодаря лингвострановедению, учащиеся могут изучить значения слов в зависимости от культуры слова.

Е. В. Михайлова отмечает, что лингвострановедение – это принцип обучения, который дает возможность развить коммуникативные способности учащихся. Ведь благодаря лингвострановедению строится адекватное общение, поскольку человек понимает не только язык, но и культуру.

А. Мустайоки говорит, что главной задачей лингвострановедения является достижение коммуникативной компетенции, поскольку целью коммуникативной компетенции является изучение истории быта, традиции страны, поскольку эти знания необходимы при общении с носителями языка [3: 54-56]. Действительно, зная культуру страны, люди могут понимать различные выражения, жесты, общаясь друг с другом.

По мнению О.С. Ахмановой и О.В. Александровой, лингвострановедение – это раздел филологии, как наука о человеческих языках в их реальном существовании, а также передающая от поколения к поколению культурно-исторические традиции [1]. Другими словами, благодаря знаниям культуры страны, человек знакомится с языком страны.

Л. С. Алексеева и И. В. Арнольд подмечают, что лингвострановедение – это филологическая дисциплина, объектом которого является не только страноведение, но и язык. То есть, идет изучение как языка, так и культуры страны.

Таким образом, можно увидеть множество понятий термина «лингвострановедение» и то, что все языковеды и исследователями приходят к одному выводу: в основе лингвострановедения лежит как

культура, так и язык. Однако я придерживаюсь мнения Е. М. Верещагина и Г. Е. Костомарова, поскольку их трактовка термина «лингвострановедение» близка к методике преподавания иностранного языка, которую можно назвать лингвострановедческим аспектом.

**Литература**


1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. – М.: Советская энциклопедия, 1969.
2. Верещагин Е.М., Костомаров В.Г. Язык и культура: Лингвострановедение в преподавании русского языка как иностранного. 3-е изд. – М.: Русский язык, 1983. – 296 с.
3. Мустайоки А., Шерстинова Т. Оценка эффективности коммуникации с помощью методики ретроспективного комментирования звукозаписи непостредственными участниками диалога // Интернет и современное общество. – СПб., 2017. – С. 54-56.
4. Оберемко О. Г. Обучение лингвострановедческому аспекту иностранных языков. – Н. Новгород: НГЛУ, 2007. – 74 с.
5. Томахин Г. Д. Реалии в культуре и в языке // ИЯШ, 1981. – С.64-69.

# ЯДЕРНАЯ ОСНОВА КОНЦЕПТА “ВЕРНОСТЬ” В РУССКОМ ЯЗЫКЕ

*Наби А.Г., КФУ, аспирант 3 г.о.*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Исламова Э.А.*

Русский язык богат не только своим лексическим разнообразием, но и уникальными концепциями, которые отражают особенности культуры и менталитета. Одним из таких глубоких и многогранных понятий является "верность". Всепроникающее значение этого слова и его уникальные нюансы неизменно привлекают внимание лингвистов и философов. Однако, чтобы полностью понять суть ядерной основы концепта "верность" в русском языке, необходимо провести глубокий анализ его лингвистических корней, культурных контекстов и семантических трансформаций. В данном исследовании мы погрузимся в богатство русского языка, раскрывая тайны и особенности понятия "верность", выявляя его значения, пронизывающие каждый аспект общественной жизни и межличностных отношений.

Основными репрезентантами семантики слова “верность” в русском языке являются лексемы “верность” и “верный”. Данные лексические единицы входят в ряд первых 10000 наиболее употребительных слов современного русского языка, что зафиксировано Частотным словарем современного русского языка О.Н. Ляшевской, С.А. Шарова [3: 221]. Лексема “верность” является производной от слова “верный”, которое имеет “долгий путь” в русском языке. Согласно Историко-этимологическому словарю П.Я. Черных, имя прилагательное “верный” образовано от имени существительного “вера”: древнерусский “вѣра” – “верность”, “религия”, белорусский – “вера”, “верны”, украинский – “віра”, “вірный”, болгарский “вера” – “религиозное мировоззрение”, “доверие”, “верен” – “преданный”, сербохорватский “вȇра”, “вȇран” – “преданный”, “верующий”, словенский “vera”, “veren” – “верный”, “верующий”, чешский “vira”, “věrný” – “верный”, словацкий “viera”, “verný” – “верить”, “доверять”, польский “wiara”, “wierny” – “преданный” и восходит к индоевропейской основе “*věra”. Сравните: готский “(allawērei)” – “честность”, древневерхненемецкий “wāra” – “правда”, “истина”, древнеанглийский “wær” – “союз”, “обещание”, “верность”, “дружба”, древнеисландский “vārar” – “договор”, “обет” [5: 141].

Выявление ядерных признаков, вербализирующих семантику понятийного компонента концепта “Верность”, опирается на данные идеографических словарей.

В Русском семантическом словаре Н.Ю. Шведовой лексика, эксплицирующая семантику слова “верность”, нашла отражение в третьем томе, содержащем имена существительные с абстрактным значением. Имена существительные, репрезентирующие концепт “Верность”, включены в лексико-семантический класс “Духовный мир: сознание, мораль, чувства”, далее – в один из лексико-семантических рядов класса, имеющий название – порядочность, честность, искренность, ответственность, вежливость, воспитанность.

Концепт “Верность” может выражать также следующие понятия: 1) 'верность друга', которое содержит лексемы “стойкость” и “неизменность”; 2) 'супружеская верность', 'верность друзьям', 'верность присяге', 'верность в дружбе' – “постоянство”, “долг” [4: 30].

В Большом толковом словаре русских существительных Л.Г. Бабенко, соединяющем принципы идеографических, толковых, объяснительных словарей, словарей-справочников, лексема “верность” представлена на основе типовой семантики – “свойства человека”; в ней объединены такие семантические лексемы, как “стойкость”, “неизменность”, “обязанность”, “долг”, “надежность”, “преданность” [1: 89].

В Идеографическом словаре русского языка О.С. Баранова лексика, выражающая общие значения верности, относится к сложной иерархической системе групп, подгрупп, отделов и подразделов: Надежность – Обязательство – Измена – Верность. В подразделе Верность все лексемы объединены на основании семантического признака “надежность”: “хранить верность кому”, “быть верным долгу”, “господин своего слова”, “держать клятву” [2: 128].

Согласно данным идеографических словарей, концепт “Верность” отражает разные семантические классы, в зависимости от того, какой принцип классификации использовался авторами конкретного словаря. Отметим наиболее общие идеографические классы, которым соответствует лексика, выражающая семантику концепта “Верность”, – понятие “надежность”, понятие “стойкость”, понятие “долг”, понятие “постоянство”. В проанализированных словарях концепт “Верность” репрезентируется широким набором лексем, обозначающих различные понятия: “супружеская верность”, “верность в дружбе”, “верность долгу”, “верность слову”.

По данным Частотного словаря современного русского языка О.Н. Ляшевской, С.А. Шарова, выделим распространенные синонимы ядерной лексемы «верность» – *любовь, справедливость, надежность, достоверность, преданность, правильность, честность,*

*постоянство, приверженность, очевидность, непогрешимость, несомненность* [3: 221].

Таким образом, ядро понятийного компонента концепта "Верность" составляют лексемы-синонимы, отражающие следующие признаки: *надежность, точность, исправность, достоверность, истина, уверенность, преданность, правдивость, стойкость*.

**Литература**

1. Бабенко Л.Г. Большой толковый словарь русских существительных. – М.: АСТ-Пресс, 2005. – 862 с.
2. Баранов О.С. Идеографический словарь русского языка. – М., 2002. – 1200 с.
3. Ляшевская О.Н., Шаров С.А. Частотный словарь современного русского языка: на материалах Национального корпуса русского языка. – М.: Словари.ру, 2015. – 1087 с.
4. Шведова Н.Ю. Русский семантический словарь. Толковый словарь, систематизированный по классам слов и значений // РАН. Ин-т рус. яз. – М.: Азбуковник. Т. 3. 2003. – 573 с.
5. Черных П.Я. Историко-этимологический словарь современного русского языка: в 2-х т. – М.: Рус. яз., 1993. Т. 1. – 623 с.

# ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ АЛЫНМА ЛЕКСИКАНЫ ӨЙРӘТҮ АЛЫМНАРЫНА КҮЗӘТҮ

*Нәбиуллина А., КФУ, I курс магистранты*
*Фән.җит. – филол.фән.док., проф. Галиуллина Г.Р.*

Алынма лексиканы өйрәнү – хәзерге мәктәпнең актуаль мәсьәләләренең берсе. Укучылар ни өчен һәм нинди очракларда татар сүзләре урынына алынма лексиканы кулланырга кирәклеген белергә тиеш. Укытучы алынмалар кабул ителү процессының төп сәбәпләрен ачык итеп аңлатырга һәм бу процесска тәэсир итә торган шартлар турында кызыклы һәм аңлаешлы итеп сөйләгәндә укучылар әлеге теманы үзләштерәчәк.

Укытучының бурычы – укучыларга көндәлек сөйләмдә алынма сүзләрне ничек дөрес итеп кулланырга өйрәтү. Бу максатка ирешү өчен, чит сүзләрнең лексик мәгънәсен генә түгел, аларның синонимнар һәм антонимнар белән бәйләнешен, гомуми һәм тематик лексик төркемнәрдәге алынмаларның урынын да аңлатырга кирәк.

Соңгы елларда мәктәп программасында татар (туган) телне өйрәтүдә тел ситуациясе торышы белән бәйле кайбер үзгәрешләр булды. Алар арасында:

- уку-укыту материалларында тәкъдим ителгән алынма сүзләренең саны арту;
- чит тел лексикасы кергән текстлардан гыйбарәт күнегүләр саны арту.

Ләкин, әйтергә кирәк, әлеге эш системалы характерда түгел, һәм бу, үз чиратында, укучыларның тулы белем потенциалын җәлеп итеп, алынма лексиканы үзләштерү мөмкинлеген чикли.

Алынма лексика белән эшләү өчен нигез итеп, күнегүләр һәм бүтән авторларның биремнәре белән тулыландырып, А.В. Прудникова тәкъдим иткән системаны алырга мөмкин [3: 29].

Методист-галимә барлык лексик күнегүләрне ике төргә бүлеп бирә:

1. Телнең лексикасын һәм төрле лексик катламнарны куллану күләмен ачыклауга юнәлтелгән күнегүләр. Аларга логик-лексик, логик-семантик күнегүләр керә.

2. Берләштерелгән биремнәр. Алар арасында мәгънәне аңлау өчен лексик-грамматик күнегүләр; морфологик категорияләрне үзләштерү өчен күнегүләр; сүзнең мәгънәсен һәм аның морфемаларын ачыклау өчен лексик һәм орфографик биремнәр; лексик төшенчәләрне берьюлы кабатлау белән орфографик үрнәкләрне үзләштерү өчен биремнәр; лексик һәм стилистик күнегүләр; фразеологизмнар,

җөмләләр һәм конкрет алынмалар белән бәйле текст язу өчен биремнәр [3: 30].

Алынма лексиканы өйрәтүнең берничә төп алымы бар: әңгәмә, телне анализлау, чагыштырма-тарихи, визуаль, эвристик, коммуникатив, уен алымнары.

Укыту кораллары җыелмасы түбәндәге компонентлардан тора:

а) уку-укыту комплекслары (дәреслекләр, сүзлекләр, күнегүләр җыелмасы, укыту әсбаплары, таблицалар, күрсәтмә әсбаплар, карточкалар, техник чаралар һ.б.);

б) дидактик укыту материалы – алынма лексиканы укытуның эчтәлеге.

Бу юнәлешнең методик системасының соңгы өлеше – эшне бәяләү блогы. Ул укыту методларының эффективлыгын бәяләү критерийларыннан тора.

Методистлар алынма лексика белән эшләүнең өч төп этабын билгелиләр: кереш, беренчел ныгыту, сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләрендә алынган күнекмәләрне куллану сәләтен үстерү [1; 4].

Беренче этапта сүзлекләр кулланырга, синонимнарны һәм антонимнарны сайларга һәм чыганак теленең туры мәгънәсендә тәрҗемә ярдәмендә сүзнең мәгънәсен аңлатырга кирәк.

Укучыларда алынма лексика темасына карата кызыксыну үсешен татар телен башка телләр белән чагыштыру ысулы ярдәмендә өйрәткән чакта тәэмин итеп була. Бу очракта “Проблемалы сораулар” техникасын кулланырга мөмкин. Мәсәлән, дәрес башында мондый сораулар бирергә була: Кайсы телдә алынмалар саны күбрәк: татар телендәме, әллә рус телендәме? Башка телләр үз лексикасын киңәйтү өчен алынмалар кулланамы? Башка телләрдә татар теленнән алынмалар бармы?

Алынмалар турында сөйләгәндә, укытучы туган телгә кайсы чорда нинди алынмалар кабул ителгәнлеге турында мәгълүмат бирергә тиеш. Мәсәлән: “Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы бик борынгы чордан ук яшәп килгән, төрки халыкларның барысы өчен дә уртак булган төрки телгә барып тоташа. Бу телдәге сүзләрнең күпчелеге хәзер җәмгыятьтә, кеше тормышында, көнкүрешендә иң әһәмиятле, иң кирәкле төшенчәләрне белдерә” [2: 57].

Шулай ук  төрле сүз уеннарын кулланырга мөмкин. Мәсәлән, сүзләрне “күпер” белән тоташтырып, алдагы сүзнең соңгы хәрефләренә башланган башка алынма сүз белән чылбырны дәвам ит нәтиҗәдә: 1 нче вариант – фарсы “фәс”ен татар “түбәтәе”нә әйләндерү. Мәсәлән, *фәс – Әсфәндияр – ярканат – атрибут – утилизация – ясту –*

*түбәтәй.*; 2 нче вариант – киресенчә: *түбәтәй – йогурт – таш – шарф – фәс.*

Алынма сүзләр кергән гамәли күнегүләр түбәндәге элементлар ярдәмендә системага салына:

- чит тел катламнарын табу һәм аларның лексик мәгънәсен аңлату;
- алынма сүзләр кергән махсус күнегүләр башкару;
- бу сүзләрне эзлекле рәвештә сөйләмдә куллану.

Укучыларның татар теленә, аның тарихына һәм лексикасына кызыксынуларын үстерү өчен, аларның иҗади һәм аналитик сәләтләрен җәлеп итеп, уку тәҗрибәсен кулланырга, дәрестә төрле эшчәнлек формалары кулланырга кирәк. Болар барысы да укыту программасын эффектив үзләштерү, укучыларның индивидуаль сәләтләрен үстерү, татар телен өйрәнүгә аңлы караш формалаштыру өчен ачкыч булып тора.

**Әдәбият**


1. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар теле лексикологиясе. – Казан: Казан ун-ты, 2013. – 124 б.
2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. – 144 б.
3. Прудникова А.В. Лексика в школьном курсе русского языка: Пособие для учителей. – М.: Просвещение, 1979.
4. Татар лексикологиясе: 3 томда. Т. 1 / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 352 б.

# ДИАЛОГИК СӨЙЛӘМГӘ ӨЙРӘТҮДӘ АКЫЛ КАРТАЛАРЫН (MIND MAPS) КУЛЛАНУ

*Нәҗипова Г., КФУ, V курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Әшрәпова А.Х.*

Татар телен чит теле буларак өйрәтүнең төп максаты – телне система буларак түгел, аны аралашу чарасы буларак өйрәтү, ягъни укучыларда башкаларның әйткән һәм язган фикерен аңлау, үз фикереңне телдән һәм язма формада әңгәмәдәшеңә җиткерә белү күнекмәсен булдыру [4: 19]. Әлеге компетенцияне үстерү максаты белән, укытучылар дәрес барышында монологик һәм диалогик сөйләмгә өйрәтү өчен төрле күнегүләр һәм биремнәр кулланалар.

Көндәлек тормышта диалог телдән сөйләмнең иң актив формасы булып тора. Рус мәктәпләре өчен татар теле, татар мәктәпләре өчен рус теле дәреслекләре һәм аларны укыту методикасына караган хезмәтләр авторы, А.Ш. Әсәдуллин, татар мәктәпләрендә рус телен өйрәтүне диалогик сөйләмнән башларга кирәк дигән фикерне алга куя, чөнки диалогка өйрәнү – шактый авыр процесс. Бу сөйләмнең әлеге формасының коммуникатив, психологик һәм лингвистик үзенчәлекләре белән бәйле: күп укучыларда сөйләүченең фикерен тыңлап аңлау күнекмәсе булмау, әзерлеккә аз вакыт булуы, тематиканың еш алмашынуы, фикернең эзлекле итеп бирелү таләбе, җөмләләрнең төрле калыпларын куллану кирәклеге сөйләүче һәм тыңлаучы алдында авырлыклар килеп чыгуга сәбәп була [3: 6].

Диалог барышында катнашучыларга билгеле бер психологик мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә: үз репликаларын һәм әңгәмәдәш җиткергән фикерне истә тоту; җавап бирә башлаганчы, кабул иткән мәгълүматны бәяләү; әңгәмәдәшнең репликаларына җавап бирә һәм үз фикереңне вакытында, комачауламыйча һәм бүлдермичә әйтә белү; әңгәмәдәшнең алга таба җавап бирә алу мөмкинлеге өчен терәк реплика әйтә белү. Диалогик сөйләм үсешенә хас кимчелекләрнең берсе – укучылар теманы төрле дәрәҗәдә һәм төрле яктан ачарга мөмкиннәр: әңгәмәдәшләрнең берсе артык тирәнәя яки диалогны башка темага бора ала.

Татар телен чит тел буларак өйрәткәндә, әзерлек күнегүләр сыйфатында схемалардан файдалану киң таралган. Әлеге күнегүләрдә укучылар буш урынга төшеп калган репликаларны өстәп, үзара сөйләшәләр. Әзерлек күнегүләр ярдәмендә сөйләмдә автоматизм булдырыла, ирекле сөйләмгә әзерлек алып барыла. Әмма тикшеренүләр күрсәткәнчә, әлеге төр күнегүләр планлаштарылган нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирми. Беренчедән, интерференция

күренеше сәбәпле, татар телендәге грамматик формалар дөрес кулланылмый, укучылар җөмләләрне, фикерләрен рус теленнән сүзгә-сүз тәрҗемә итеп, уңай сүз тәртибен сакламыйча төзиләр. Икенчедән, балалар, әзер сорау һәм җаваплар кулланып, билгеле бер теманың төрле аспектларын ача белү сәләтенә ия булмыйлар. Әлеге мәсьәләне чишәр өчен, инглиз телен өйрәтү методикасыннан кергән үзенчәлекле радиаль формага ия булган терәкне, акыл карталарын куллану кулай санала.

Акыл карталары – ул кәгазь бите кулланып, истә калдыру, искә алу, уйлап табу күнекмәләрен чагылдыру, шулай ук мәгълүматны эшкәртүнең эчке процессларын да күрсәтү, аларга үзгәрешләр кертү, камилләштерү. Бу ысул күренекле британия психологы Тони Бузан тарафыннан уйлап табыла. Тәүге тапкыр әлеге карта көн аралыгында барлыкка килгән планнарны системага салу өчен кулланылган, әмма соңыннан ул уку-укыту процессына актив кереп китә. Әлеге ысулның эчтәлеге шуннан гыйбарәт: тема битнең үзәгендә урнаша. Төп фикерләр үзәк сүз яисә сүзтезмәдән чыккан ботаклар формасында сурәтләнә, өстәмә фикерләр исә нечкә сызыклар ярдәмендә үзәк сызыкларга кушыла [1: 19-20]. Акыл карталарында сүзләр генә түгел, символлар, рәсемнәр, тамгалар куллану кулайрак дип санала. Автор фикеренчә, төрле төстәге каралар белән язу ярдәмендә, мәгълүмат укучы тарафыннан яхшырак үзләштерелә, тизрәк истә кала [2: 8-9].

Әлеге ысул белән таныштырганда, укытучы тарафыннан яңа үтелгән тема буенча сыйныф белән бергә карта ясап карарга тәкъдим ителә. Беренче адым итеп, укытучы бу теманы кечкенәрәк подтемаларга бүләргә ярдәм итә. Ботаклар ясала, шулар янына сүз, сүзтезмә языла яисә рәсем ясала. Бу ботакта бирелгән мәгълүмат диалогик сөйләмнең һәр сорау репликасын тәшкил итә. Икенче адым итеп, укучылар сораулар төзеп карыйлар. Өченче адымда укучылар бер-ике җавап вариантын тәкъдим итәләр. Соңгы этапта укучылар үзләре төзегән картаны парларга бүленеп укыйлар. Алга таба укучылар мөстәкыйль рәвештә мондый схемаларны төзи алачаклар.

Укучыларның сәләтләренә, мәгълүматны үзләштерү дәрәҗәсенә карап, акыл карталарын төрлечә кулланып була. Йомшак укучылар өчен бу төр таянычны әзер функциональ моделен үз эченә алган ачык диалог схемасы буларак кулланырга мөмкин, ул укучыларга сөйләмнең җөмләләре арасында логик-мәгънәви бәйләнешне булдыруда ярдәм итә. Шул ук картада ачкыч сүзләр һәм әзер сүзтезмә, җөмләләр булырга мөмкин. Көчле укучыларга әлеге карталарны төшеп калган кушымчалар һәм сүзләр форматында бирергә мөмкин.

Акыл карталары – татар теле дәресләрендә диалогик сөйләмгә өйрәтүдә актив кулланылырга лаеклы ысул. Карталар сөйләмдә диалог алып бару күнекмәләрен формалаштыра, лексик-грамматик материалны аралашу ситуацияләре аша өйрәнергә ярдәм итә. Әлеге ысул ярдәмендә укытучы укучыларның иҗади һәм логик фикерләү сәләтләрен үстерә, камилләштерә, уку процессында дустанә мөнәсәбәт булдыра.

**Әдәбият**


1. Tony Buzan. Mind Map Mastery: The Complete Guide to Learning and Using the Most Powerful Thinking. – Watkins Publishing Ltd, 2018 – 224 p.
2. Tony Buzan. Mind Maps for Kids. – Thorsons; Reissue edition, 2005 – 128 p.
3. Скалкин В.Л. Обучение диалогической речи (на материале английского языка): Пособие для учителей. – Киев: РАДЯНСЬКА ШКОЛА, 1989. - 158 с.
4. Харисов Ф.Ф. Татар теле: укыту теориясе һәм практикасы. Монография. – Казан : “Ак бүре” нәшрияты, 2018. – 448 б.

# ПРЕЦЕДЕНТТІК ҚҰБЫЛЫСТАР – ЛИНГВОМӘДЕНИЕТТАНУ НЫСАНЫ

*Нурбаева А., Alikhan Bokeikhan University, Қазақстан Республикасы, Семей қаласы, докторант, II курс*
*Ғыл. жет.– филол. ғыл. док., проф. м.а. Абикенова Г.Т.*

Әрбір ұлттың өз тілі, ғасырлар бойы қалыыптасқан ұлттық дәстүрлері, тарихы, әдебиеті, ұлттық мәдениеті болатыны белгілі.

Тіл біліміндегі прцеденттік құбылысы (прецеденттік феномен, прецеденттік мәтін) ұғымы тіл білімінде ғылыми айналымға ХХ ғасырдың соңына қарай енгізіле бастады. Бұл ұғымдарға зерттеуші ғалымдар тарапынан түрліше анықтама беріледі. Олардың бірі бұл құбылысты жалқы есімнің жалпы есімге ауысуы деп түсінсе, тағы бірқатар ғалымдар бұл құбылыстарды кеңірек мәнде түсінеді. Прецедентті құбылыстар – ұлттық мәдениеттен ақпарат беретін тілдік бірліктер.

Соңғы жылдары тіл мен мәдениеттің арақатынасы туралы мәселе өзекті мәселелер қатарында қарастырылып келеді. ХХ ғасырдың аяғында ғалымдардың аталған мәселеге ерекше назар аударуы лингвомәдениет-тану ғылымының дамуына жол ашты. Ол тіл бірліктерінің ұлттық-мәдени семантикасын зерделеуге мүмкіндік береді. Лингвомәдениеттану – ұлттық мәдениет-тің тілдегі көрінісін сипаттау мәселелерін зерттейтін тіл білімінің саласы. Лингвомәдениеттануда тіл коммуникация мен таным құралы ғана емес, ұлттың мәдени коды ретінде қарастырылады. Әлемнің ұлттық тілдік бейнесі тіл бірліктері мен тілдің ұғымдық-категориалдық құрамындағы мағыналық бірліктерді ұлттың қабылдауы мен дүниетанымы тұрғысынан сипаттайды. Адам когнициясы мен мәдениеттүзу қызметінің негізгі тетіктерінің пайда болуы мен дамуы барысындағы тілдің қызметін зерттеу ақиқат болмыстың тілдегі бейнеленуін сипаттап, осы мәдениет өкілдерінің дүниетанымы, эстетикалық нормалары, діни наным-сенімдері туралы жан-жақты ақпарат алуға мүмкіндік береді.

Лингвомәдениеттануда тіл мен мәдениетті тұтынушы ретінде адам маңызды орын алады. Оның аялық білімі, мінез-құлығы мен тәртібі, ұстанымдары мен дүниетанымы белгілі бір мәдениеттің өкілі ретінде оны басқалардан ерекшелендіріп тұрады. Сол себепті лингвомәдениеттануда адам факторына маңызды орын беріледі [1: 45].

Прецеденттік құбылыстар – лингвомәдениеттану нысаны болып табылады.

Прецеденттік құбылыстардың құрамы үнемі өзгерісте болады.

Кейбір прецеденттер ескіреді және жарамсыз болып қалады, ал басқалары қосымша мағыналарға ие болады және осылайша жаңа прецеденттік құбылыстардың пайда болуына ықпал етеді. Қоғамның дамуы, моральдық құндылықтардың өзгеруі іс жүзіндегі өзгерістерге де әсер етеді

Прецеденттік ұғымы Ресей тіл білімінде Ю.Н. Караулов, Ю.А. Сорокин т.б. ғалымдардың зерттеулерінде сөз болады, прецедентті есім термині Д.Б. Гудков, В.В. Красных, Е.Л. Березович, О.А. Ворожцова, А.Б. Зайцева, О.С. Боярских, Г.Г. Сергеева т.б. зерттеулеріне арқау болған. Прецеденттік есім туралы қарастырған ғалымдар О.А. Ворожцова, А.Б. Зайцева Ресей және Прецеденттік құбылыстың прецеденттік оқиғалар, прецеденттік мәтіндер, прецеденттік айтылымдар, прецеденттік есімдер деген төрт түрге жіктелетіні белгілі. Сонымен қатар прецеденттік есімдердің денотативті немесе экстенсионалды, коннотативті немесе интенсионалды қолданылатын түрлерін анықтайды.

Қазақ тіл білімінде прецеденттік құбылыстар Г.А. Қажығалиева [2], Г.Қ. Ихсангалиева [3], С.Қ. Иманбердиева [4] еңбектерінде қарасырылған. Қазақ тіл білімінде теориялық және практикалық жағынан прецеденттік есім мәселесін кеңірек қарастырған Г.Б. Мәдиева еңбегінде прецеденттік есім мәселесі кеңірек сөз болады [5].

Прецедентті есімдер ұлт тарихында, ұлт мәдениетінде белгілі тұлғалардың есімінен жасалады. Мысалы, ұлт тарихында есімі сақталған батырлар мен хандар: Абылай хан, Тәуке хан, Қобыланды батыр, Қабанбай, Бөгенбай, кенесары хан т.б. Сондай ақ ұлттық діни нанымын, сенімін білдіретін сөздер де прецедентті атауларға айналады: *Жер-Ана, Су-Ана, От-Ана, Адам-Ата, Тәңір және т.б. Прецедентті есімдердің тағы бір тобы діни және мифтік образдардан құралады: Алла, Тәңір, пайғамбарлар (Дәуіт, Мұса, Сүлеймен), Қанбақ шал, Қыдыр ата; Қасиетті пірлер және әулиелер: Бибі Фатима, Қожа Ахмет Иассауи, Ұмай ана; Баба түкті Шашты Әзіз,* Көркем шығарма кейіпкерлерінің есіәмдері де халыққа ке танымал болып, прецеденттік есімге айналуы ықтимал: *Дайрабай, Мырқымбай, Судыр Ахмет.*

Ұлт тарихындағы негізгі оқиғалар тілдің құжаттық, мәдени танымдық қарекетінің негізінде фразеологиялық, паремиологиялық жүйеде, ескі мәтіндерде тарихи есімдер арқылы таңбаланып, халық санасында жатталады. Өзгеше ұлттық мазмұндық бейнедегі, мәдени ақпараттық мазмұны басым бұл атаулар лингвистикада прецеденттік деп анықталып, тіл мен мәдениет байланысында қарастырылады.

Прецедентті есімдерді мақал-мәтелдерде, жұмбақтарда, қанатты сөздерде, бата сөздерде, нақыл сөздерде жиі қолданылады. Ұлттың өмірлік идеологиясындағы өзгерістердің әсерінен ұлттық прецеденттік құбылыстардың корпусы үнемі өзгеріп отырады, бұрынғы құбылыстар ығыстырылады, олардың орнына жаңалары келеді. Прецеденттік құбылыстар – бұл мәдени құбылыс.

**Әдебиет**


1. Володина М.Н. Язык СМИ – основное средство воздействия на массовое сознание // Язык СМИ как объект междисциплинарного исследования. – М., 2003. – С. 23-24.
2. Кажигалиева Г.А. Лингвокультурологический анализ художественного текста. – Алматы: Айкос, 1999. – 104 с.
3. Ихсангалиева Г.К. Функционально-прагматический анализ заголовков (на материале казахстанских газет и телепрограмм): автореф. ... канд. филол. наук. – Алматы: КазНУ, 2000. – 28 с.
4. Иманбердиева С.Қ. Қаладағы тағамхана атаулары: филол. ғылым. канд. ... автореф. –Алматы: ҚазҰУ, 2001. – 23 б.
5. Мадиева Г.Б. Имя собственное в контексте познания. – Алматы: Қазақ университеті, 2004. – 190 с.

# Г. КАНДАЛЫЙНЫҢ ПОЭТИК ТЕЛЕ

*Нуриева Н., Саба р-ны, Шәмәрдән, IX сыйныф*
*Фән. җит. – Галимҗанова Д.И.*

Әле язма әдәби тел барлыкка килгәнче үк, халык тирән эчтәлекле, поэтик яңгырашлы, сәнгатьчә эшкәртелгән матур-матур сурәтләү чаралары иҗат иткән. Әнә шундый поэтик бизәкләрне без татар әдәбиятында дөньяви поэзияне башлап җибәргән шагыйрь Г. Кандалый поэзиясендә күрәбез.

Башта аның шигырьләрендәге фразеологик әйтемнәргә игътибар итик: *йөрәк мае сызылу* [1: 116], *кан калмау, гарык булу* [1: 89 ], *чиргә сабышу, гакыл җитмәү, коллыкка калу, гарьлеккә төшү* [1: 90], *күңел уйнату, җан түзмәү, җан тынмау, хәсрәт чигү, яныл-көю* [1: 98], *сагыштан кибеп-кору* [1: 99], *җан кыйнау, сафа сөрү, каргышка тару* [1: 105], *теңкә корту, авыз тулы кан булу, гыйшык төшү* [1: 110], *күз белән каш итеп тоту* [1: 111], *үзәк өзелү, яманат күтәрү* [1: 113], *зар булу, интизар булу, зар-интизар булу, йөрәккә кан утырды* [1: 71], *утка саласың* [1: 104] һ. б.

Болар үзләре генә дә шагыйрьнең тел хәзинәсендәге байлыкка җитди игътибар итүен күрсәтә. Г.Кандалый шигырьләрендә чын халыкчан тел бизәкләре күп.

Мәсәлән, «Сәхипҗамалга» поэмасында гарьлеккә калу дигән әйтелмә: *«Йөрерсең лә бата-ката, төшеп зиярәткә, гарьлеккә»* [1: 90], - дип бирелә. Гарьлеккә калу төрлечә булырга мөмкин. Ул кешенең, үз мәнфәгатенә, субъектив сәбәпләргә дә бәйле. «Гарьлеккә төшү», «бата-ката йөрү» дигән әйтелмә белән эчке бәйләнешкә керә. Шуның аркасында гарьлеккә калуның объектив сәбәпләре ачыклана, ягъни бата-ката йөрүгә Сәхипҗамал үзе түгел, бәлки шул чордагы тормыш-көнкүреш, социаль шартлар гаепле булуы ачыклана. Моннан без поэтик сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрнең башка тел чаралары, шулай ук әсәрнең идея-эчтәлеге һәм ул чагылдырган чор белән эчке бәйләнешкә керүен дә күрәбез.

Поэзиядә авторның традицион образларны, төрле тел чараларын үзгәртүе, гадәттә, ритм, рифма, стильгә бәйле була. «Сәхипҗамалга» поэмасыннан бер мисал: *Эш эшләп уникe аең, гомер буең, кышын-җәен, Сызып бетеп йөрәк маең, каның да калмый кашыкка. Кыекча башыңа чорнап, утырсаң лабаса җырлап, Кулың, битең камыл тырнап, юлыкып билчән ашлыкка*...[2:392]

Биредә язма әдәби тел барлыкка килгәнче үк булган йөрәк мае сызылу, соңгы кан тамганчы кебек тәгъбирләр алынган. Алар халык телендә авыр язмышны тасвирлау өчен кулланыла. Кандалыйның

тамчы кан калмау дигән әйтелмәдәге «тамчы»ны «кашык» сүзе белән алыштыруы мәгънәне тагын да көчәйтә төшкән.

Тереләй сую дигән әйтелмә дә бик борынгы. Аны хәзерге вакытта кулланыла торган мәгънәсендә аңларга ярамый. Кандалый әлеге әйтелмәнең бер компонентын гына ала. *Ярамый, әнкәй, суярга, итәм тозлап та куярга, Шул ук та бәне бер ярга, ярәшерсез, и әнкәй лә* [2: 420].

Шулай ук Г. Кандалыйның халык җырларындагы сурәтләү чараларына игътибар итик. Әйтик, күп җырларда аның сәнгатьлелеген, эмоциональлеген көчәйтүгә хезмәт итә торган традицион чара буларак, Йомшак таң җиле образы кулланыла. Бу образ поэтик бизәк сыйфатында шигъри юлларда килә. Кандалый аны матурлык символы итеп бирә: *Ирәм багындамы үстең, йөрәкем бәгырене кистең, Саба йиле кеби исдең, ки, сахраларда, чүлләрдә* [2: 390].

4. Хакимова С.Г. Проза Фаниса Яруллина (эволюция творчества): автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2004. – 23 с.

# ЧИТ ИЛ ТАТАР ПЕРИОДИКАСЫНЫҢ БҮГЕНГЕ ТОРЫШЫ

*Фәхртдинова Р.Н., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Юсупова А.Ш.*

Чит илләрдә татар басмаларын булдыру эшчәнлеге XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында ук башлана. 1905-1907 нче елгы Беренче рус инкыйлабыннан һәм Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң башлап, Төркия, Германия, Венгрия, Польша, Япония, Китай, Швеция, Румыния, Финляндия кебек илләрдә һәм АКШта татар телендә 50 дән артык газета-журналлар чыга башлый. Татар вакытлы матбугатын оештыручылар булып Россиядән 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр киткән һәм аннан соң большевиклар режимы белән ризалашмыйча туган илләрен калдырып китәргә мәҗбүр булган татар зыялылары, җәмәгать һәм дин әһелләре, аларның балалары, шулай ук Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышлары вакытында әсир төшүчеләр санала.

Бүгенге көндә дә чит илләрдә татар газета-журналлары чыгып тора.Югары мөселман көллияте дүрт елга якын дини тематика белән бәйле китаплар, журналлар һәм брошюралар чыгара. Польшадагы басма татар һәм мөселман җәмгыятьләренең тарихы һәм мәдәнияте белән таныштырып бара. Күп еллар илдә фәнни берләшмәләргә адресланган «Ежегодник польских татар» журналы басылып чыга. Анда татар халкының проблемалары, милли азчылыклар һәм Польшаның Көнчыгыш белән үзара мөнәсәбәте турында язалар.

2021 нче елның февралендә «Przegląd Tatarski» (“Татарча күзәтү”) дигән журналның яңа саны басылып чыга. Журнал Польша татарлары җәмгыятендә барган вакыйгаларны, мемуарлар, шулай ук тарихи һәм фәнни материалларны, көндәлек тормышы турындагы мәкаләләрне тәкъдим итә. Татар тематикасына яисә җәмәгатьчелек катнашындагы агымдагы вакыйгалар, очрашулар, фәнни конференцияләр, проектлар турында хисаплар;истәлекләр, гаилә күзаллаулары, үткән тормыш һәм гореф-гадәтләрне тасвирлау; Көнчыгыш Европа илләрендә татар җәмгыятьләренең яшәү үзенчәлекләре; күренекле татар активистлары казанышларын популярлаштыру; Польша татарларының фәнни, мәдәни һәм һөнәри казанышлары; Университет үзәкләре тикшеренүчеләре әзерләгән фәнни мәкаләләр, шул исәптән Ягеллон университеты, Вармин-Мазурск университеты, Торунида Николай Коперник исемендәге Университет, Белосток университеты турында яза. Монда укучылар игътибарына, ислам принциплары һәм Польшада мөселманнар тормышы белән кызыксынучы Белосток медицина университеты

студентлары турында материаллар бирелә, шулай ук бөек архитектор, художник Ильяс Айдаров турында мәкалә тәкъдим ителә. «Миллиард Татар» порталы белән хезмәттәшлек нәтиҗәсендә журналда башка кызыклы мәкаләләр дә, шул исәптән Сөембикә һәм татар хатын-кызлары костюмнары турында да мәкаләләр урнаштыру мөмкинлеге бар.

«Przegląd Tatarski» 2009 елдан башлап эчке эшләр министры һәм администрация гранты ярдәмендә өзлексез басылып тора. Ул университет үзәкләре тикшеренүчеләре һәм татар җәмгыяте вәкилләре тарафыннан чыгарыла. Квартал саен чыгарыла торган журнал булдыруның инициаторы – мөфти Р.П. Томаш Мискевич. Ә баш мөхәррир – Муса Чахоровский. 2022 нче елның февралендә чыккан журналда яңа төзелгән мәчет турында хәбәр ителә. Моның турында баш мөхәррир, Муса Чахархан: "Әле күптән түгел генә бу иске агач йорт иде. Хәзер безнең манаралы матур мәчетебез бар. Яңа мәчетнең интерьер һәм тирә-ягындагы фоторәсемнәре тышлыкның 3 нче һәм 4 нче ягында урнаштырылган», – дип, сөенече белән бүлешә.

Икетелле “Перспектива” журналы Франциядә 2003 елдан бирле чыга. «Рус» приставкасына ия булуга карамастан, анда еш кына татар халкының тормышы һәм гореф-гадәтләре турында мәкаләләр бастыралар. Мәсәлән, 2015 нче елда бастырылган 9 нчы санның тышлыгында Казан, Кол-Шәриф мәчете сурәтләнгән, ә 2019 нчы елда чыккан басманың баш битендә “Татарстанның энҗе бөртеге” язуы астында Болгар шәһәре күрсәтелгән, 2017 нче елның июнендә татар халкының милли киемнәре кидерелегән әби-бабай, онык төшерелгән сурәттә Сабантуй бәйрәме турында мәгълүмат бирелгән. Журналда җирле мәдәни вакыйгалар, кызыклы кешеләр, җирле ассоциацияләр эшчәнлеге, ике ил хезмәттәшлеге яңалыклары, диаспоралар һәм икетеллелек турында уйланулар турында күп языла, икетеллелек турындагы фикерләр үз ватаныннан еракта туган балаларны тәрбияләүдә ярдәм итә.

1995 елдан алып Литвада өч телдә – литва, рус һәм поляк телләрендә «Летувос Тоторяй»(«Литва татарлары») газетасы чыга. Аны җирле милли җәмгыятьләр йорты чыгара, ул илнең милли азчылыкларын, шул исәптән татарларны да яклый. Басма Казан турында мәкаләләр, татар бәйрәмнәрен, сәясәт һәм генерал Юзеф Беляк исемендәге хәрби-тарихи клуб эшчәнлеге турында мәкаләләр бастыра.

Газетаның төп юнәлеше булып бүгенге көн вакыйгаларын һәм проблемаларын яктырту, Литва татарлары тарихының тамырларын эзләп табу, алар белән таныштыру, шулай ук Польша, Белоруссия,

Татарстан, кебек төбәкләрдә яшәүче татарларның тормыш-көнкүреше, мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында мәгълүмат бирү тора.

«Туган тел» бөтенукраин татар мәдәни үзәге 2000 елдан башлап татарлар өчен «Дуслык» журналын чыгара. Монда Рудольф Нуреевның балет легендасы, бу елга истәлекле даталарның мөселман календаре, ислам турында мәгълүматлар, гаилә турында хәдисләр, милли бәйрәмнәр, "Галәм аһәңе " рубрикасындагы шигырьләр, мисал өчен, 2021 нче елның санында Габдулла Тукайның “Милли моңнар” шигыре тәкъдим ителә, кроссвордлар, татар халкының мәкальләре, әдәби әсәрләр, кулинария бүлеге тәкъдим ителә.

Финляндиядә шулай ук «Yaña Mähallä habärläre» (Яңа мәхаллә хабәрләре) журналы тәкъдим итә. Аның баш мөхәррире итеп Рамиль Беляев сайлана. Әлеге басма үзенчәлекле: чит ил татар диаспорасының барлык басмаларыннан ул бары тик үзе генә татар телендә латин графикасыннан файдаланып нәшер итә.

Бүгенге көндә чит илдә чыга торган татар басмаларын санын төгәл әйтү кыен. Аларның азаюына глобальләшү йогынты ясый: интернет һәркайда бар, шуңа күрә туган телдәге басмаларны Казан интернет-журналлары сайтларыннан да укып була. Әмма безгә милләттәшләребезнең тормышы, эшчәнлеге бүгенге көндә бик кызыклы. Эмигрант периодикасы әле һаман да Европада, Азиядә һәм якын чит илләрдә бар һәм бастырыла, бу исә, безне сөендерә.

**Әдәбият**


1. Ахметова Я.М. Говор татар Финляндии: дис. … канд.филол. наук. – Казань, 2004. – 182 с.
2. Беляев Р.Ф. Татарская диаспора Финляндии: вопросы интеграции и сохранения идентичности: дис. … докт.филос.наук. Хельсинки,2017. – 310 с.
3. Галямутдинов А.И. Современные татарские периодические издания Финляндии, Литвы и Украины // Ученые записки Казанского государственного университета. Серия: Гуманитарные науки. Том 151, кн. 5, ч. 2. – Казань, 2009. – 234 б.

# ЧУАШСТАН ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫНДА ЯҢА ТОРЫНКАБЕР ТАШЛАРЫ

*Феткуллова А., Чувашия Республикасы, Батыр муниципаль округы, беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәбе, IX сыйныф*
*Фән. җит. – Айзатуллова Р.Р.*

Һәрбер җирлекнең үз халкы өчен таныш булган һәм билгеле бер исем белән аталган урыннары була. Туган авылым Шыгырданда һәм авылдан ерак түгел генә урнашкан, халык телендә “Кизләү буе”, “Мөслим”, “Цаллук буе” дип аталган урыннары бар. Алар авылның тарихи ядкаре, бик күптәннән үк авыл халкының изге урыннары.

Чуашстан татарларының республикада дистәдән артык изге урыннары бар. Элек-электән килгән йола буенча, бу урыннарга халык барып, догалар кыла. Әлеге изге урыннарның күбесендә борынгы кабер ташлары да ята. Халык, шул тирәдәге мәхәллә кешеләре аларны карап-тәрбияләп тора.

Чабаксардан Сембер шәһәренә илтә торган юл кырында, Чуашстанның көньяк өлешендә, Шомыршы районына керә торган Яңа Торын дип аталган авыл бар. Чуашлар аны Вăрманти Тăрăн, ягъни урмандагы Торын диләр, урысчасы исә Ново Буяново. Авыл зур булмыйча, 110 йортта чуашлар яши.

Бу авыл инде йөзләрчә ел буена тирә-яктагы татарлар өчен мөһим дини урын булып тора. Хикмәт шунда ки, әлеге авыл уртасында, Карлы елгасы ярында борынгы 2 кабер ташы һәм тирәсе тимерчыбык белән әйләндереп алынган зират бар. Берсендәге язуларны укырлык түгел, әмма икенчесендәге язудан тарихны чамалап була. Чуашлар аны мишәр мазары-каберлеге дип атый, ә татарлар исә "болгар бабаларыбыз яуда һәлак булган урын" дип йөри.

Бу каберлек хакында төрле сүзләр йөри. Чуаш авылы уртасындагы зиратта Болгардан куылып килгән сугышчылар һәм өч изге кыз күмелгән дип, сөйләгәннәр картлар. Башка версияләрдә әлеге кабер ташы Бикбулат морза тарафыннан Тинчура улы Бикчурага һиҗри белән 1108 елда куелган. Һиҗри елын миладига әйләндерсәк, 1695 ел була. Халык бу урында сугыш булган дип сөйли. Риваятьләргә караганда, Бичура сугыш кырында һәлак булган. Аның гәүдәсен сугыш кырыннан елга буенча алып килеп, татар авылының каберлегенә күмгәннәр. Татар авылы хәзер юк. Шул тирәләргә Буяноводан һәм Торыннан чуашлар күчеп килеп авыл төзегәннәр. Татар авылының исемен хәтерләүчеләр юк. Бәлки ул авылның исеме Карабай булгандыр. Чөнки татар каберлегеннән ерак түгел Карабай Шомыршы авылы бар. В. Магницкий “Список татарских селений Буинского уезда

в “ОАИЭ”, т. 18” дигән хезмәтендә дә Карабай исеме белән татар авылы булуын искәртә. Бу урынны тарихчылар нугай татарлары белән урыс гаскәре бәрелешкән урын булуы ихтимал дип аңлата. Бичураның нинди сугышта һәлак булуы безгә төгәл мәгълүм түгел. Казаннан килгән профессор Һ.Юсупов кабер ташларындагы язуны Бичура Тинчура улы икәнлеген укып раслый.

Бу урынны җирле татарлар изге урын дип саныйлар һәм ел саен дога кылырга киләләр. Җирле тарихчылар да бу җирләрдә татар-мөселман догасы өзелмәгәнлекне яза. Тарихи чыганакларда 1908 елда Сембердән Г.Кокол дигән тарихчы Яңа Торын зиратындагы кабер ташлары хакында мәгълүмат теркәп калдырган. "Шыгырданнан килгән татарлар тезләнеп гыйбадәт кылып утыралар иде. Алар монда Казан ханлыгы вакытындагы изге затлар – сугышчылар күмелгән дип әйтәләр”, – дип язып куйган ул.

Кайсы көнне тезелеп дога кылуларын ул чакта теркәп калдырмаганнар. Бүгенге көндә Шыгырдан татарлары һәр ел май аеның соңгы көннәрендә шушы чуаш авылына килеп, гыйбадәт уздыра. Яңгыр аз булган елларны монда килеп, яңгыр намазы да укыйлар.

Авыл картлары һәм карчыкларыннан Яңа Торын турында белгән, ишеткәннәре турында да сораштырдым. “Бала чакта Яңа Торынга әниләр, әбиләр белән җәяү бара торган идек. Халык күп була иде. Әбиләр зиратның аскы ягында, Карлы елгасы ярына төшеп дога кылалар, шунда ашый-эчәләр иде. Кайбер кешеләр кунып калалар иде. Татарлар килгәнне күреп, чуашлар чәйләр кайнатып, йомыркалар пешереп безне сыйлыйлар иде. Әбиләр үзләре белән алып килгән чәйләрен пешереп, чәйләр эчәләр иде”, – дип искә төшерделәр олылар.

Яңа Торын авылы зиратына татарлар электән корылык булганда дога кылырга килә торган булганнар. Зират читендә карап торган чуаш карчыклары да, татарлар килде, димәк яңгыр була дип, ышаныч күрсәтеп калганнар. Ясин, Тәбрәк укылганнан соң, халык белән бергәләп тәүбә кылына. Моннан соң, электән килгән гадәт буенча, зираттан чыгып, яр буенда корбан ашлары ашала. Ә яңгыр теләгенең төп гыйбадәте – истиска намазы шул ук көнне мәчетләрдә укыла. Шыгырдан, Балтай, Байтирәк, Татар Согыты авылы татарлары бу урынга ел да бер аерым көнне килеп торганнар.

Нигә бу урынны чуашлар да изге итеп кабул иткәннәр соң? Бу җиргә бәйле күп вакыйгаларны мисал итеп китергә була. Картлар сөйләвенә караганда, зиратның тирә-ягында койма тотылмаган була. Бер тракторчы бу җирне сөрергә тотына. Тимер сабаны моның чытырдап сына. Колхоз икенче сабан китерә, барыбер сөрә алмыйлар.

Тракторчысы да вафат була. Шуннан соң изге урынның кадерен аңлый башлаганнар. Колхозлашу вакытында, бу урынны сөреп, анда кыяр утыртып караганнар. Әмма ике ел рәттән бозлы яңгыр явып, үсемлекләрне харап иткән. Зират тирәсендә бала-чага мал ашаткан. Балалар шуннан соң авырган. Ул авыру балаларны татарлардан өшкертеп торганнар. Файдаларын да күргәннәр.

Безнең бабаларыбыз гаделлек, иминлек, туганлык кебек төшенчәләргә табынып яшәгәннәр, тарихка саклык белән караганнар. Без аларның теләкләрен дәвам итәргә, алар кадерләгәнне кадерләргә, саклаганны сакларга тиешбез. Алар үзләре исән чакта безне тарихыбыз, ата – бабаларыбыз рухы белән бәйләп тоталар. Ә алардан соң без киләчәк буынны шуңа өйрәтергә тиешбез. Галим Тәлгать Галиуллин килер буыннар турында һәркемгә уйланырлык фикерләр әйтә: "Киләчәк буыннар үзләренең тамырларын белергә тиешләр. Башкача булганда, җәмгыятьне маңкортлар, үз тарихын белергә теләмәгән, бер көн белән яшәгән нәселсез адәмнәр явыз саранча болыты шикелле басып китәчәк", – ди ул. Үз иленең, төбәгенең, туган авылының тарихын белү кешегә үзен "Кеше" буларак танырга ярдәм итә. Изгеләрне хөрмәтләү, ихтирам белән телгә алу безнең кешелек сыйфатларын югалтмавыбызны, алдагы буыннар өчен күңелләребезнең тыныч булуын күрсәтә.

**Әдәбият**


1. Салихов П.М. Шыгырдан. – Ульяновск: ОАО «Областная типография «Печатный двор», 2010. – 544.
2. www.azatliq.org/a/28516338.html
3. https://islam21.ru

# “ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН” ӘСӘРЕНДӘ ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ ЯЗМЫШЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

*Хаҗиев С.,Саба р-ны, Шәмәрдән лицее, IX сыйныф*
*Фән. җит. – I категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы Әүхәдеева А.В.*

“Ялантауга ай кунган”әсәре теленең үзенчәлеге, байлыгы, образлылыгы белән сокландыра ул. Табигатьне саклау, кеше язмышы бүгенге көндә дә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Экологик проблемалар элек-электән әдипләребез тарафыннан күп әсәрләрдә күтәрелгән.

Табигатьне саклау һәм әхлак проблемасын 19 нчы йөз язучылары да күтәргәннәр. “Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә, гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия– иң кирәкле бер эш булачактыр”,–дип язган Р.Фәхретдин [2: 92]. Бу мәсьәлә хәзерге көн язучысы Р.Шәйдуллина әсәрендә дә чагылыш таба. “Үзеңнән соң тәүфыйксыз бала калдырсаң, яшәп тә торасы юк. Чөнки яшәү мәгънәсе–нәсел калдыру. Нәсел агачының тамыры черек булса, нинди кәүсә, нинди яфрак, нинди чәчәк, нинди җимеш инде ул?! Нәсел тамырлары нык булырга тиеш!” [4: 207]. Шулай ук “Ялантауга ай кунган” повестенда табигатьне саклау иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. “Менә шул химиягез белән бөтен табигатьне агулап бетердегез инде сез! Әнә, Мишәдә балыклар бетә бара. Басуларны яраплан белән агулыйлар да, яңгырлар ишле булса, шул агу Мишәгә агып төшә [4: 194]. Әсәренең герое Инсаф та улы Сәетне табигатьне химия белән агулап бетерүдә гаепли.

“Ялантауга ай кунган”китабы сугыштан соңгы авыл тормышын чагылдыра. Сюжет, композиция, образларның бирелеше–барысы да халыкчан. Анда тормыш кына түгел, мәхәббәт мизгелләре дә урын алган. “Мин дә йолдызга “Зәйтүнә!” дип дәшәрмен. Һәр кич саен мин синең белән шул йолдыз аша сөйләшермен.Синнән башка саргаеплар үләрмен мин. Моңарчы синсез ничек яшәлгән-белмим” [4: 40]. Автор повестенда мәхәббәтнең мәңгелек булуын, яшьли туган хисләрнең олыгайгач та сүрелмәвен күрсәтергә теләгән.

“Ялантауга ай кунган” повесте – гаҗәеп якты, эчке тирән сагышлы әсәр. Монда дингә кайту, катнаш никахлар проблемасы күтәрелә. “Безнең бабай әйтә:кайчан да булса яңа мәчетләр салырлар әле, ди. Авылга дин кайтыр, кешеләргә иман кайтыр, ди” [4: 33]. Язучы әсәрендә кешенең эчке дөньясын, рухын тирәнтен сурәтләргә омтыла. “Бәлки, Хәниянең сөю тулы карашы Сәеткә гарип вакытында кирәк

булгандыр. Үзәкләре өзелеп, тәмам өметсезлеккә төшеп, үз уйларыннан уелып торган чагында. Ул вакытта егеткә әтисе, Фатыйма һәм Нурания апалары, “Сак-Сок” бәетен, “Йосыф-Зөләйха” кыйссасын көйгә салып укыган Каракай әбисе терәк булды”[4:87].

Әсәрдә шулай ук кеше бәхете мәсьәләсе күтәрелә. Без моны бик күп образлар аша күрә алабыз. Мәсәлән, Сәет, Зәйтүнә, Хәния, Мәрьям үз бәхетләре өчен көрәшәләр, тормышның сикәлтәле юлларыннан чыгу юлын эзлиләр. “Сәет Хәнияне рәнҗетте. Әгәр бу ялгышын төзәтә калса, Мәрьям туачак улы яки кызы рәнҗеп калачаклар. Туачак баласын рәнҗетсә, үз намусына хыянәт итеп, гомере буе үкенеп яшәячәк”[4:148]. “Сәет белән Зәйтүнә, озак итеп, бер сүз сөйләшмичә, аккан суга карап тордылар. Икесе дә бер үк уйда иделәр бугай. Курыкма, Зәйтүнә, мин сиңа булышырмын. Без ул тауның башына менеп җитә алырбыз әле. Моның өчен безнең вакытыбыз да бар, көч-куәт тә җитәрлек”[4:252].

Повестьта гаилә мөнәсәбәтләре, әти-әни, балалар, дин һәм милләт мәсьәләләре дә күтәрелгән. “Василий–әйбәт кеше, мине бик ярата, ләкин урыс. Әнием минем башка милләт кешесенә кияүгә чыгуыма катгый каршы килгән булыр иде, ләкин ул хәзер үз акылында түгел”[4:71].

Гомумән, фәнни-эзләнү эше әсәрне өйрәнүгә, вакыйгалар бирелешен, истәлекләрне барлауга корылды. Кеше язмышының бирелеше үзәк урынны алып тора. “Нишләсен ул яшь кыз, көтмәгәндә шундый авыр хәлдә калгач? Зәйтүнәгә бик авырдыр дип уйлап та карамады бит Сәет! Үз кайгысы кайгы булды. Ә Василий исемле урыс егете Зәйтүнәгә таяныч була алган. Ул таяныч Сәет булырга тиеш түгел идемени? Хәзер соң инде...”[4:87].

Шулай итеп, табигать һәм кеше бер-берсе белән бәйле. Тормышта һәрберсе бәхет өчен көрәшә, никадәр авыр сынаулар үтә, үз юлын таба. Ләкин кешелек дөньясы никадәр бәхетле булырга теләсә дә, табигатьтән башка бәхетле була алмый. Шуның өчен тормышта кеше бәхете белән бергә табигатебезнең байлыгын саклау–иң зур бурыч.

**Әдәбият**

1. Казан утлары. – 2000. – № 2, 3.

2. Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Р.Фәхреддиннең мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. VI кисәк. – Казан: ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы нәшрият үзәге, 2010. –152 б.

3. Шәйдуллина Р.Ш. Карт шомырт хатирәсе. – Казан: “Ак Бүре” нәшрияты, 2020. –367 б.

4. Шәйдуллина Р.Ш. Ялантауга ай кунган: повестьлар. –Казан: “Ак Бүре” нәшрияты, 2016. –335 б.
5. Яруллин Ф. Яралы язмышлар. – Казан: Рухият, 2000. – 439 б.

# ЧИТ ТЕЛГӘ ӨЙРӘТКӘНДӘ ПРОСОДИК КОМПОНЕНТ

*Хаҗиева М., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Һадиева Г.К.*

Телдән аралашу чарасы буларак файдалану аны кулланучыларның фикер йөртү сәләте белән бәйле. Нинди дә булса телдә сөйләшүчеләр милли-мәдәни үзенчәлекләргә бәйле булган һәм берегеп калган модельләргә нигезләнеп эш итә. Бу тел системасының барлык катламнарында да, шул исәптән, просодия өлкәсендә дә чагылыш таба.

“Просодия” төшенчәсе “Лингвистик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге”ндә (2016) түбәндәгечә аңлатыла: ПРОСОДИЯ \ТАТ\ ПРОСОДИЯ Сөйләм сегментларының (иҗек, сүз, текст һ.б.) барлык катламнарында кулланыла һәм мәгънә аеру ролен үти торган фонетик чаралар системасы, ритмик-интонацион берәмлекләре: сингармонизм, сүз басымы, интонация һ.б. [1: 187].

Просодик үзенчәлек принциплары чит телгә өйрәтү структурасында дискурс яссылыгының мөһим компоненты буларак карала, чөнки просодиянең коммуникатив функциясе аралашуда бәхәссез зур роль уйный. Чит телгә өйрәтүдә мәдәниятара бәйләнешнең дискурс үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк. Сөйләүче тарафыннан булдырылган просодик модель һәрвакыт мәдәни-специфик һәм субъектив билгеләргә нигезләнә. Әмма индивидуаль, релевант булмаган факторлар белән беррәттән, просодия лингвистик яктан әһәмиятле үзенчәлекләргә дә таяна. “Әгәр дә методика субъектив булса, ул аңлаешсыз булыр иде. Без аны аңлыйбыз, ягъни билгеле бер мәгънәләрне аерып чыгарабыз икән, ул объектив лингвистик мәгънәгә ия дигән сүз” [2: 268]

Сөйләм коммуникациясе процессында мәгълүматны тапшыруның ике төп аспекты түбәндәгеләрне үз эченә ала: тавыш тирбәнешләре белән характерлана торган физик аспект, интерактантлар тарафыннан мәгълүматны тапшыруны һәм кабул итүне тәэмин итә торган әһәмиятле аспект.

Шулай итеп, телдән аралашуның просодик компонентына өйрәтү чит телнең милли-специфик үзенчәлекләрен яхшы белүнеталәп итә һәм түбәндәге компонентларны колачлый :

1) дөрес артикуляциягә өйрәтү, ягъни, әйтелеш функциясен үтәүче сөйләм органнарының дөрес эшләвенә ирешү;

2) сөйләм актын ишетү һәм аңлау процессында гамәлгә ашырыла торган акустик компонент буларак аудированиега өйрәтү.

Просодик үзенчәлекләр сөйләм билгеләренең акустик

параметрларын кабул итү нәтиҗәсе булып тора [3: 24]. Көндәлек аралашу барышында киң кулланылучы директив сөйләм актлары мисалында чит телнең просодик үзенчәлекләрен үзләштерүнең нинди зур әһәмияткә ия булуын ачык күрсәтергә мөмкин. Директив актларның максатчан юнәлеше адресантны нинди дә булса гамәлне башкарырга яки туктатырга этәрүдән гыйбарәт.

Директивлар кулланылган сөйләм ситуацияләре лингвистикага карамаган билгеләр җыелмасы белән характерлана. Юридик яки конвенциональ характердагы директивны гамәлгә ашыручы әңгәмәдәшләр арасындагы мөнәсәбәт мөһим роль уйный. Теләсә кайсы сөйләм актын гамәлгә ашыруда телнең барлык катламнары да (грамматик, лексик, фонетик) колачлана. Директивлар тел чараларының төгәл билгеле бер структурасын үз эченә ала, аның әйдәп баручы компонентларының берсе – просодик компонент. Югарыда билгеләп үтелгәнчә, тел интеракциясе әңгәмәдәшләр арасындагы мөнәсәбәтләр культурасы үзенчәлеге белән характерлана. Бу просодиягә аеруча да кагыла, чөнки туган телдәге аралашу манерасын чит телгә күчерү нәтиҗәсендә әйтелгәннәр дөрес кабул ителмәскә һәм, нәтиҗәдә, аралашу процессы бозылырга мөмкин. Просодия сөйләм актының эмоциональ өлеше белән тыгыз бәйләнгән һәм мәгълүматны дөрес булмаган тонда җиткерү әйтелəсе фикернең тиешенчә барып ирешмәве белән куркыныч.

Нинди дә булса чит телне өйрәнгәндә аның просодик нормаларын үзләштерү беренче урында тора, чөнки телнең башка катламнары кебек үк просодик компонент та сөйләм эшчәнлегенең уңышлы гамәлгә ашырылуын тәэмин итә. Мәктәптә просодик берәмлекләр – басым, иҗек, интонация – тиешле дәрәҗәдә өйрәнелергә тиеш. Туган тел дәресләрендә урта сыйныфларда әлеге берәмлекләрне өйрәтүгә караган уңышлы мисаллар карап китәрбез.

Татар телендәге басым үзенчәлекләрен өйрәтү максатыннан, түбәндәге биремне тәкъдим итәргә була: “Басым куелышы буенча бирелгән сүзләрне нинди ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин? Сүзләрне таблицага урнаштырыгыз, басымнарын билгеләгез”

Кемдер, бала, карагай, нәрсәдер, каядыр, китап, никтер, кәгазь, барлык, барысы, бармак, барчасы, башлык, һичшиксез, һәркайда, дәфтәр, һәркем, ләкин, карчыга, гаять, өстәл, гәрчә

| Басым беренче иҗеккә төшкән сүзләр | Басым икенче иҗеккә төшкән сүзләр |
|---|---|
| | |

Интонацияне өйрәтү максатыннан, укучыларга кызыклы уеннар тәкъдим итәргә мөмкин. Мисал өчен, экранда түбәндәге мәкаль бирелә:

“Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми”. Укучыларга карточклар таратыла, анда түбәндәге биремнәр язылган була:

Мәкальне сорау интонациясе белән укыгыз.

Мәкальне боеру интонациясе белән укыгыз.

Мәкальне гаҗәпләнү интонациясе белән укыгыз.

Мәкальне курку интонациясе белән укыгыз һ.б.

Һәр укучы бер карточканы ала һәм биремне үти.

Иҗек темасын өйрәткәндә, шулай ук урта сыйныф укучыларының яшь үзенчәлекләренә туры килә торган уеннар уйнатырга була. Мисал өчен, укучылар иҗекләрнең билгеләре буенча тиешле сүзне таба. Мәсәлән: “Беренче иҗеге – ябык иҗек, соңгы иҗеге ачык иҗек булган сүзне табыгыз”, “Икенче һәм өченче иҗекләре – ачык, соңгы иҗеге ябык булган сүзне табыгыз” һ.б.

Шулай итеп, мәктәптә просодияне өйрәтүгә зур басым ясарга кирәк дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин, чөнки ул сөйләм эшчәнлегенең дөрес гамәлгә ашырылуында мөһим роль уйный.

**Әдәбият**


1. Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. – Казан: ИЯЛИ, 2016. – 248 с.
2. Зиндер Л.Р. Общая фонетика. М.: Высшая школа, 1979. – 193 с.
3. Якубинский Л.П. Избранные работы. Язык и его функционирование. – М.: Наука, 1986. – 276 с.

# ПОСЛОВИЦЫ О БОГАТСТВЕ В РУССКОЙ И КИТАЙСКОЙ ЛИНГВОКУЛЬТУРЕ

*Хао Ко, КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Сафонова С.С.*

Богатство, которое может быть как материальным, так и духовным, – это понятие, общее для всех цивилизаций и обществ. Россия и Китай, как две цивилизации с многовековой историей, имеют свои уникальные ценности и различные взгляды на богатство. Сравнительно-сопоставительный анализ пословиц о богатстве в русской и китайской лингвокультурах позволяет исследовать восприятие этого понятия представителями этих двух стран.

В русской лингвокультуре богатство ассоциируется с такими понятиями, как счастье и успех. В русских пословицах достаточно частотна фраза «жить в изобилии», подразумевающая желание иметь больше материальных благ, что находит воплощение в следующих паремиях: *Копейка рубль бережет, а рубль голову стережет. После Бога – деньги первые. Деньги не счастье, но без них счастье неполно*, которые косвенно отражают место богатства в сердцах россиян и их стремление к нему.

В русских и китайских пословицах нередко наблюдается метафоризация с целью описания последствий материального богатства: *Без денег – как рыба без воды*. В данной пословице выражается чувство беспомощности и незащищенности, которое приходит с бедностью. В китайской пословице *水能载舟，亦能覆舟* （Вода может нести лодку, но может и опрокинуть ее） подчеркивается двойственная природа материального богатства, которое может принести как успех и счастье, так и праздность и несчастье.

Особое внимание в русских пословицах о богатстве уделяется накоплению и сбережению: *Копейка копейку родит. Береги денежку про черный день*, в которых подчеркивается прагматизм русского народа, его практический опыт и практический подход.

В паремиях о богатстве русский народ актуализирует и важность человеческих отношений, которые считаются одним из важнейших условий богатства и успеха. Однако согласно общественным условностям, богатые и бедные никогда не будут находиться в одном классе, что отражает социальную реальность: *Богатый бедному не брат. Богатый бедного не разумеет.*

В китайском лингвокультуре пословицы о богатстве часто связаны с внутренним миром человека, его характером и

добродетелями: *一分耕耘，一分收获。* (Что посеешь, то и пожнешь) – традиционная пословица, которую часто произносят китайцы и которая подчеркивает важность упорного труда и необходимость прикладывать усилия, независимо от того, кто хочет добиться успеха и богатства. В пословице *财富诚可贵,德行价更高。* (Богатство дорого, но добродетель дороже богатства) подчеркивается, что китайцы больше внимания уделяют внутреннему миру человека, что добродетель важнее богатства.

В Китае одинаково важны и сохранение богатства, и его приобретение: *节约金钱，就是珍惜生命。*(Экономить деньги – значит ценить жизнь) *钱要用在刀刃上，不能浪费。*(Богатство должно быть использовано для важных вещей и не может быть потрачено впустую). В этих пословицах воплощены китайские ценности и представления о деньгах, подчеркнуты бережное отношение к богатству и привычка его наживать.

Изучая и анализируя пословицы о богатстве в русской и китайской лингвокультуре, мы можем глубже понять ценности и культурные традиции обоих народов. Русские пословицы о богатстве подчеркивают связь между деньгами, чувствами и личностью и носят более гуманистический характер. В Китае, напротив, акцент делается на труде, а также на внутреннем мире человека. Благодаря этим пословицам люди могут перенять мудрость народа и улучшить свое представление о богатстве, труде и жизни. В то же время пословицы о богатстве широко используются в образовании, культурных обменах и общественной деятельности, постоянно влияя на мышление и поведение людей и вдохновляя их. Благодаря языку паремии о богатстве продолжают нести обновленную мудрость и просвещение в современное общество и являются важным культурным ресурсом прогресса человеческой цивилизации, а также общественного развития.

**Литература**

1. Даль В.И. Толковый словарь живого великорусского языка: В 4-хтомах. – М.: Русский язык, 1989.
2. Жуков В.П. Словарь русских пословиц и поговорок [Текст] / В.П. Жуков. – М., 2007. – 311 с.
3. Фролова О.Е., Пословица и ее отношение к действительности // Вестник Московского университета. – №4. 2005. –С. 125-132.
4. 念建宏．俄汉语言文化中的“贫”“富”观念对比研究[D].吉林大学, 2022.

“КАЗАН УТЛАРЫ” ЖУРНАЛЫНДА ЗАМАНА ЛИРИКАСЫ

*Хәбибуллина А., КФУ, I курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Сәйфуллина Ф.С.*

«Казан утлары» һәрвакыт күренекле һәм яшь татар әдипләренең әсәрләрен, ТРның танылган тәнкыйтьчеләренең һәм журналистларның актуаль аналитик, публицистик мәкаләләрен бастыручы, әйдәп баручы журнал.

“Казан утлары” журналында басылган әсәрләрнең аерым берләренә галимнәр тарафыннан рецензия, тәнкыйть кебек җавап мәкаләләре язылса да, билгеле бер вакыт эчендә басылган авторларга, аларның иҗатына тулаем күзәтү ясалмый. Анда әсәрләре басылган авторларны барлау, хәзерге заман шигъриятенең популяр темаларын билгеләү поэзиянең бүгенге хәл-торышын ачыклауга, киләчәген прогнозлаштыруга булышлык итә.

Мәкаләнең тикшерү объекты – “Казан утлары” журналында 2016-2019 еллар аралыгында басылып, дөнья күргән лирик әсәрләр. Тикшерү предметы исә “Казан утлары” журналында (2016-2019 еллар) басылган лирика үрнәкләре, авторларының иҗат үзенчәлеге. Эшнең максаты – “Казан утлары” журналында басылган (2016-2019 еллар) поэзия үрнәкләрен өйрәнү, авторларының үзенчәлеген билгеләү. Максатка ирешү өчен 2016-2019 елда “Казан утлары” журналы битләрендә урын алган авторларның лирик әсәрләренә күзәтү ясау бурычы куелды.

“Әдәбият белеме сүзлеге” буенча, “Лирика – ул грек телендә музыка коралының исеме. Ул музыкаль, көйле әсәр буларак билгеле. Кешенең халәтен, хисләрен, уйларын, кичерешләрен сурәтләү предметына әверелдереп, ул чынбарлыкны кешенең эчке дөньясы көзгесендә чагылдыра лирикада билгеле бер моменттагы, вакыттагы нәфрәт, ачу, борчылу, кайгы, шатлык, сагыш кебек хисләр урын ала, бу хисләрнең тирән һәм күпкырлы сәбәбе ачыклана [1: 238].

Лирика *мин* исеменнән сөйли, ләкин шул ук вакытта киң гомумиләштерүләр дә ясый. Ул кешелекнең рухи тәҗрибәсен күздә тота, шушы фонда аерым бер мизгелдәге аерым кеше хисләрен типиклаштыруга ирешә. Образ дәрәҗәсенә күтәрелгән кичереш – әдәби гомумиләштерү нәтиҗәсе. Лирикадагы кичерешләр рухи яктан лирик геройга якын бик күпләр тарафыннан кичерелергә мөмкин булуы белән кызыксындыра, үзенә тарта [2: 144].

Димәк алда әйтелгән “төзү материалы” ярдәмендә эш итеп, шагыйрь тормыш күренешләрен, хис яссылыгын сурәтли һәм, әйтергә

кирәк, сәнгатьнең башка төрләренә караганда да тормышны киңрәк, тулырак һәм ачыграк гәүдәләндерүгә ирешә [3: 104].

"Казан утлары" – айлык әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал. 1922 елның май аеннан татар телендә нәшер ителә. Исеме үзгәрә: 1922-30 елларда "Бенең юл", 1930-32 дә шул җирлектә "Атака" һәм "Яңалиф" журналлары чыга, 1933-65 тә "Совет әдәбияты", 1965 елдан хәзерге исемдә. [4: 296]

2016 елның "Казан утлары"ндагы 43 авторның иҗат җимешләре үз укучысына барып ирешкән. Әдәби берләшмәләргә дә журналда шактый урын бирелгән, бигрәк тә "Кама таңнары" берләшмәсе вәкилләре актив булганнар: 14 каләмдәш үз язмалары белән уртаклашкан.

2017 елда журналда шигырьләре басылган авторларның саны 49 га җиткән. Алар арасында шул ук таныш фамилияләрне очратырга мөмкин. Рафис Корбан, Айдар Хәлим, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рафил Газизов, Лена Шагыйрьҗан, Ленар Шәех, Рөстәм Мингалим кебек авторлар белән танышырга була.

Хатын-кыз шагыйрәләр һәр елны да актив иҗат иткәннәр: Г.Бәйрәмова, Ф.Җамалетдинова, Н.Сафина, Ш.Җиһангирова, Р.Рахман, Ә.Ситдыйкова, Э.Шәрифуллина, Л.Янсуар, Ф.Тарханова һ.б. Күбесе туган телебезгә мәдхия җырлый, аны сакларга чакыра.

"Казан утлары" журналында басылган шигырьләрнең тематикасы төрле булса да, күп кенә авторларның иҗатында кабатлана торган үзенчәлекләрне күрергә мөмкин. Әсәләр гәдәттә тематика буенча бер баш исем астында берләшмиләр, ләкин татар дөньясы өчен мөһим булган вакыйгаларга багышланган шигырьләр бер санда басылырга мөмкин.

Димәк, "Кеше Хаклары" укучының күңеленә үтеп керерлек, уйландырырлык итеп язылган. Анда тормышыбзның нигезендә яткан кыйммәтләр искә алына.

Эзләнүләр түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирде. "Казан утлары" журналы гражданлык лирикасына өстенлек бирә. Авторларның күп өлеше милләт, тел язмышы турында уйлана.

"Казан утлары" журналында өлкән буын шагыйрьләренең иҗатына күбрәк игътибар бирелә, ләкин моның белән беррәттән "Яңа исемнәр" бүлегендә дә яшьләрнең шигырьләре басыла.

Гомумән, "Казан утлары" журналы затлы лирика тәкъдим итә һәм әзерлекле укучыга йөз тота.

**Әдәбият**


1. Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар кит. нәшр., 1990. – 238 б.
2. Госман Х., Мәҗитов З. Әдәбият теориясе. Әдәби әсәр. Уртак мәктәпләрнең тел-әдәбият укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 144 б.
3. Мягкость модернизма в татарской литературе // Актуальные вопросы современной филологии и журналистики. – Воронеж, 2020. – № 1(36). – С. 97–104.
4. Татар энциклопедиясе сүзлеге / Баш мөхәррир М.Х. Хәсәнев; җаваплы мөхәррир Г.С. Сабирҗанов. – Казан: ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. – 830 б.

# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ БАСЫМНЫ ӨЙРӘТҮ

*Хәйретдинова Ч., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Һадиева Г.К.*

Сөйләм агымында бер төркем иҗекләрне бер тактка берләштерүдә басымның роле зур. Рим грамматигы Диомед (б.э.к. IV гасыр) әйтүенчә, басым – сүзнең җаны ул.

Тел белеменең орфоэпия (грекча orthos – туры, дөрес epos – сүз) бүлеге әдәби әйтелеш кагыйдәләрен өйрәнә. Орфоэпия белән укучыларның сөйләмендә пәйдә булган күп кенә хаталар бәйләнгән. Әлеге хаталарның берсе – сүздә басымның дөрес куелмавы. Нәтиҗәдә укучыларның сөйләме аңлаешсыз, мәгънәсез килеп чыга.

Татар теле белемендә басым мәсьәләсенә беренчеләрдән булып Гыйбад Нугайбәк игътибар итә. Ул үзенең «Төрлек» (1911) исемле хезмәтендә басым терминын алга этәреп чыгара һәм татар теле белеменә кертә. Гыйбад Нугайбәк басым күренешен түбәндәгечә аңлата: «Бердән артык иҗекле сүзләрдәге иҗекләр бар да бертигез сөйләнмәенчә арадан берсе басынкырак (сузынкырак) калганнары йомшаграк әйтеләләр [1: 9]. Галимҗан Шәрәф басым мәсьәләләренә тукталып: «Басым татар телендә, башка төрки телләрдәге кебек үк, экспиратор (динамик), ләкин ул музыкаль басым белән тыгыз бәйләнгән», – дигән фикер әйтә [2: 189]. Галим басым куелуның өч төрле шартын күрсәтә: а) аерым әйтелгән сүзләр (басымны соңгы иҗеккә төшә); ә) аерым әйтелгән сүзләр, ләкин басым соңгы иҗеккә төшми; в) гомуми басым астындагы сүзләр тезмәсе.

1950 нче елларда татар теле фонетикасына багышланган яңа хезмәтләр күренә башлый.

Әнвәр Әфләтунов сүз басымын интонациянең бер элементы буларак карый һәм «сүз басымы турында сөйләгәндә изоляцияләнгән сүзләрдә басым һәм сөйләм процессында сүз басымы позициясеннән чыгып фикер йөртергә кирәклегенә туктала [3: 43]. Галим басым сүзнең соңгы иҗеккә төшмәгән очракларны прокламатик басым дип атый һәм аларда модальлек төсмеренең көчле булуын, һәрберсендә диярлек яшерен фикер чагылышын күрсәтә, ә сүзнең соңгы иҗегенә туры килә торган басымны – инклитик басым дип атый. Бу басымның мәгънәгә мөнәсәбәте турыдан-туры ачык күренмәвен дәлилләп бирә.

Соңгы хезмәтләрдә галимнәр сүздә басымның урынына карап, телләрнең ике төркемгә бүленүен әйтәләр: тотрыклы басымлы телләр һәм ирекле басымлы телләр. Татар теле тотрыклы басымлы телләргә керә. Татар теленең үз сүзләрендә басым күпчелек очракта ахыргы

иҗектә була, сүзгә кушымча ялганган очракта басым соңгы иҗеккә күчә. Басым соңгы иҗеккә төшмәгән очраклар түбәндәгеләр:

1) II зат боерык фигыльләрдә басым беренче иҗеккә төшә: языгыз, утырыгыз;

2) исемдә хәбәрлек кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар: мин укучымын, сез бәхетлесез;

3) фигыльдә кайбер зат-сан кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар: язгансың, килермен;

4) фигыльдә юклык кушымчасы басымны алмый һәм үзеннән үткәрми: бармагансың;

5) рәвеш ясагыч -дай/-дәй, -тай/-тәй, -ча/-чә кушымчаларына басым төшми: бүредәй, татарча;

6) сорау, билгеләү, юклык алмашлыкларында, өлешчә күрсәтү һәм билгесезлек алмашлыкларында басым беренче иҗеккә төшә: кайда, барлык, һичкем.

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К. Һадиева, Г.В. Һадиева авторлыгындагы дәреслектә ( татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) басым темасы 5 сыйныфта карала башлый. Әлеге дәреслектә түбәндәге кагыйдә бирелгән: «Күп иҗекле сүзләрдә иҗекнең берсе, башкаларыннан аерылып, көчлерәк әйтелә. Бу иҗек басымлы иҗек дип атала: ба-тыр-лы́к, Татар телендә басым, нигездә, сүзнең соңгы иҗегенә төшә. Сүзгә кушымча ялганган саен, басым да соңгы иҗеккә күчә бара: кита́п, китаплары́м, китапларымны́ң». Шушы кагыйдәгә нигезләнеп укучылар кызыклы биремнәр белән күнегүләр эшлиләр. Мәсәлән: 147 нче күнегүдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә кушымчалар өстәп яз. Сүзләрнең басымнарын билгелә. Басымның күчешенә игътибар ит. Сүзгә кушымчалар ялганганда, басым нишли? Нәтиҗә яса дигән күнегү бирелгән. Әлеге күнегү ярдәмендә укучылар сүзгә басым кую гына түгел, ә кушымчаларны да үзләштереп баралар. Дәреслектә басым ярдәмендә сүз төркемен аерып күрсәтергә дигән кагыйдә дә бирелгән. Укучылар кагыйдәне күнегүләр эшләп үзләштерәләр: Җөмләләрне укы, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең басымын билгелә, кайсы сүз төркеменә керүен әйт: *әни алма бирде – син бу дәфтәрне алма*. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен 5 сыйныф дәреслегендә искәрмәләр турында да кагыйдә язып үтелгән. Укучылар әлеге искәрмәләрне күнегүләр белән ныгыталар. Мәсәлән, 152 нче күнегүдә диалог бирелгән. Күнегүнең биреме рольләргә бүлеп укуда һәм басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне язып алудан, басым билгеләүдән гыйбарәт.

Басымның күп кенә яшерен, үзенчәлекле яклары күп. Мәктәп дәресләрендә басым темасын яктырту татар телебездә саф сөйләшергә ярдәм итәчәк.

**Әдәбият**

1. Афлетунов А.Ш. Фонетика современного татарского языка: Методические указания для студентов заочников по изучению курса и выполнению контрольных работ. – Казань, 1962. – 53 с.

2. Шәрәф Г. Сонорная длительность татарских гласных // Вестник научного общества татароведения. – Казань, 1928. – №8. – С.180-265.

3. Нугайбәк. Г. Төрлек. – Казан: Мәгариф, 1911. – 80 б.

# ТАТАР ЛИНГВОМӘДӘНИЯТЕНДӘ ЭНДӘШ СҮЗЛӘР КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*Хәйруллина Л., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нәбиуллина Г.Ә.*

Татар халкы менталитетын чагылдыруда аеруча зур әһәмияткә ия булган берничә лексик-семантик төркем булуы мәгълүм. Социаль һәм туганлык мөнәсәбәтләре белән бәйле эндәш сүзләр шуларның берсе булып тора. Аларны өйрәнү тел ияләренең мәдәниятен анализлауның үзенчәлекле коралы булып тора, чөнки төрле этномәдәният вәкилләре кулланган мөрәҗәгатьләр җыелмасы этнопсихология һәм мәдәни традиция күзлегеннән әһәмиятле аралашу билгеләрен һәм сөйләм ситуацияләре үзенчәлеклен чагылдыра.

Сөйләмдә әңгәмәдәш белән контакт урнашыру аңа мөрәҗәгать итүдән, ягъни эндәшүдән башлана. Ул сөйләүче сөйләме юнәлгән затны атый. Шушы атаманы сайлау әңгәмәнең нинди тональлектә булачагын хәл итә ала. Шуның белән бергә ул әңгәмәдәшнең игътибарын җәлеп итү өчен дә кулланыла. Сөйләүче, әңгәмәдәшенә мөрәҗәгать иткәндә, аңа үзенең мөнәсәбәтен дуслык мөнәсәбәте, фамильяр мөнәсәбәт, бер-берсен якын итү, хөрмәт итү, олылау, ихтирам итү һ.б.) [1: 182].

Эндәшү сүзе аша сөйләүченең адресатка булган мөнәсәбәтен дә, аларның үзара мөнәсәбәтләрен дә ачыграк күзалларга мөмкин. Сөйләүченең адресатка биргән бәясе аша аның үзе турында да күпмедер мәгълүмат алып була. Эндәш сүзләр аралашу вакытында үз-үзеңне тоту кысаларын билгели, бүтәнчә әйткәндә, «социаль һәм үзара мөнәсәбәтләрнең индикаторы һәм регуляторы» булып хезмәт итә [2: 114].

Татар телендә мөрәҗәгать сүзләре ролендә йөрүче иң күп кулланылучы эндәш сүзләр – туганлык терминнары һәм аларга кушылып әйтелә торган сүзләр (*әби, бабай, апа, энем, сеңлем, кардәш, кордаш* һ.б.). Аларның төп вазыйфасы – мөрәҗәгать итү, эндәшү чарасы. Алар үзләре ике төркем хасил итә: таныш булмаган (очраклы) кешегә эндәшү өчен һәм таныш кешегә эндәшү өчен.

Татарларда үз туганнарына, аларның исемнәрен әйтмичә, туганлык терминнары белән эндәшү гадәте яши. Татар сөйләменең үзенчәлеге булып туганлык терминнарын кулланып мөрәҗагать итү тора: апа, абый, энем, апам, сеңлем, җизни, балдыз, әби, бабай. Балаларның әбиләренә, бабаларына эндәшү әби, бабай, дәү әни, дәү әти формаларында сакланган.

Татарларда якыннарга, яраткан кешеләргә эндәшүнеңербөтен

системасы булдырылган. Алар игелеклелек, эмоциональлек белән аерылалар: балам, сабыем, кадерлем, сөеклем, алтыным, күгәрченем, былбылым, акыллым, аккошым, җаным, җан кисәгем, бәгырем, бәгырькәем һ .б

Гаиләдә эти, әни сүзе балаларның ата-аналарына мәрәҗәгать итү сүз. Шулай ук аларның *әтием, әнием* дип ярату төсмере кушып әйтелү очраклары да бар. Ә ир-белән хатынның бер-берсенә *әтисе (атасы), әнисе* (анасы) дип эндәшүен дә беләбез. Болай эндәшү гаилә әгъзаларының бер-берсенә хөрмәте, яратуы һәм бер-берсе турында кайгыртуы, хәтта горурлык хисен дә күрсәтә.

*Ерак бабай, ерак әби* исә әнинең эти-әнисе, яки үзләреннән еракта яшәгән әби-бабайлары була. Бу очракта *ерак* сүзе ара ераклыгын белдерү өчен кулланыла (хатын ире йортында яши, ә аның эти-әниләре алар белән тормый, димәк, оныклар өчен алар ерактагы кебек була).

Татар лингвомәдәниятендә *әби, бабай, апа, абый* дип олы яшьтәге һәр ир-ат һәм хатын-кыз аталырга мөмкин, бу өлкәннәргә ихтирам, аларның тормыш тәҗрибәсе алдында баш июне белдерелә. Шуның белән бергә, бу сүздә башка йомшаграк һәм якын итеп әйтү төсмере бар. Соңгы вакытта әдәби телдә һәм шулай ук көндәлек тормышта да әби һәм бабайга мөрәҗәгать иткәндә, *дәү әни, дәү әти* дигән форма активлашып килә.

Туганнар арасында *апа, абый, әби, бабай* һ.б. төрле туганнар берничә булырга мөмкин. Бу очракта да татарлар аларның исемнәре белән эндәшмәскә тырышканнар. Аларны аеру өчен төрле эпитет-аергычлар кулланылган: *алма апа, матур апа, дәү абый, нәни апа, шәкерт абый, ерак әби, Мәңгәр бабай (авыл исеме белән), якын бабай, олы җиңги, чибәр җиңги, бал бабай* һ.б.

*Г*аиләдә, гадәттә, иң кадерле кешеләрнең исеме әйтелми: *әни, әнием, кадерле әнием, әнием бәгырем, әнием җанашым, әти, әтием, әтиебез; бабай, бабаем; әби, әбием, дәү әни, дәү әнием; апа, апам, апаем; абый, абыем; сеңлем, сеңелкәшем; энем, энекәшем; туганым* һ.б. Гаиләдә абый-апалар, эне-сеңелләр берничә булганда, яисә икетуган абый-апалар, эне-сеңелләр очрашканда, бу атамалар туганнарның исеме белән бергә әйтелә: *Гарәф абый, Сания сеңлем.*

Гаилә, нәсел эчендә генә урнашкан атама, кушаматлар да була: *дәу апа, олы абый, урта абый, алма апай, кечк нәкәй, төп чеккәй, көтелгән, әткәсе, әнкәсе, җәмәгатем, иптәшем* һ.б. Әби белән бабай, әни белән эти, башка туганнарның бер-берсенә эндәшү рәвеше, чаралары күптөрле. Туганлык дәрәҗәсен аера торган эндәшү сүзләре дә сөйләмне конкретлаштырып кына калмый, миллилек, туганлык,

кешене хөрмәтләү, олылау төсмере белән дә тулыландыра: *туганым, кардәшем, җизни, җиңги, балдыз, каениш, баҗай, дәдәй, кияү, кода, кодагый, кодача* һ.б.

Бу өйрәнүләр шуны күрсәтә: сөйләмдә эндәш сүзләрнең роле зур, алар татар халкының милли һәм этник үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итәләр.

**Әдәбият**


1. Гольдин В.Е. Речь и этикет. – М.: Просвещение, 1983.
2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.
3. Рыжова Л.П. Обращение: норма и правила употребления //Прагматика и семантика синтаксических единиц. – Калинин: Изд. ун-та, 1984. – С. 114-119.
4. Шәйхиева Г.М. Татар сөйләм этикетында мөрәҗәгать сүзләре / Милли Мәдәният. – 2004. – № 3.

ЗӨЛФӘТ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ФОЛЬКЛОР ОБРАЗЛАРЫ
(АТ ОБРАЗЫ МИСАЛЫНДА)

*Хәмидуллина Э., КФУ, I курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. д-ры., проф. Йосыпова Н.М.*

1960-1980 елларда татар позиясендә авыл темасына язылган әсәрләр аерым бер юнәлеш төсен ала һәм һәр шагыйрь иҗатында үзгә сурәттә, образларда, яңа яңгыраштa ачыла. Әлеге тема-мотивлар салмак лирика агымының нигезен тәшкил итә. Авыл, туган як, туган җир, әниләр темасына язылган поэтик әсәрләрендә Зөлфәт туган ягын, туган авылы кешеләрен, урман-болыннарын, алар белән бәйле истәлекләрне тасвирлау аша асыл яшәеш кануннарын, аның төп кыйммәтләрен аңлау һәм анализлауга китерә. Мондый шигырьләрдә туган җирне ярату үзәккә куела.

“Шагыйрьне язмыш тоташтан эзәрлекли икән. Күп еллар узса да, куып җитү, каршысына чыгып баса икән. Шигырь — язмыш. Сүземне йомгаклап, сезгә шигырьләр укытасым килә. Шагыйрь хакында гына түгел ул. Ул шагыйрь язмышы, шигырь язмышы хакында. Язылу тарихы — шигырьләрнең үзендә” – дип яза Зөлфәт үзенең иҗатына тасвирламасында. “Нигез” (1972), “Моң” (1975), “Ике ат турында баллада” (1973), “Атлар чаба”, “Колын” (1984) һ.б. шигырьләрендә Зөлфәтнең лирик герое гади кешенең рухи асылы, уйлары, тормыш мәгънәсе хакында уйланулары турында сөйли. Мондый төр шигырьләрдә яшьлек елларын, үткәннәрне сагынучы, туган җиренә ихлас мөккибән, аның матурлыгын күңел күзе аша ача алган гаять “хисле” лирик герой әйдәп бара. Аның бу халәте учак, авыл капкасы, болын, басу-кырлар, чишмә, гармун һәм ат кебек халык авыз иҗатыннан үстерелә килгән традицион романтик сурәтләр аша җиткерелә.

Фольклор образлары, гомумән, Зөлфәт иҗатының үзәгендә тора һәм аның әсәрләрендә фольклo стилен формалаштыруда катнаша. Бер халыкны икенче бер халыктан аерып торган үзәнчелекле образлары, ышану-юрауларына бәйле булган хайваннары бар.

Татар халкының йөзек кашы булган – ат образы халык авызиҗатында да зур урын алып тора. Атның бик күп атамалары бүгенге көндә дә актив кулланыла. Татар халкында атның яше, төсе, яраклашуына карап кимендә 25 исем белән йөртелә, мисал өчен акбүз, алмачуар, байтал, бахбай, бия, кашка, күккүз, сөлек, колын, айгыр, тай, кырыкмыш, толпар, чабышкы, чаптар, юртак, җылкы, җигү аты һ.б. Шулай ук мәкаль-әйтемнәр, табышмакларда, фразеологизмнарда да актив кулланыла, мисал өчен “ат җене кагылу”, “ат бәясе”, “ат белән

чыпчык куу”, “ат кебек”, “ат кебек эшләү”; “Атта да бар, тәртәдә дә бар”, “Атның аты өлкән”, “Дөянең табаны өлкән” һ.б. Әлбәттә, ат иң тырыш, ярдәмчел, хезмәт сөючән, нык кыйммәтле, асыл хайван образ кысаларына керә. Шул нисбәттән әдипләр иҗатында да бу ачык яктыртыла.

Зөлфәт иҗатында ат образы шактый зур урынны алып тора. Мисал өчен, “Колын” шигыре – гүзәл үрнәкләрнең берсе. Әлеге шигырь 1997 елда “Сабантуй” журналында басылып чыга.

Каймалы композициягә корылган әлеге әдәби үрнәк Төн кызының көлүе белән матур таң атуга килеп тоташа. Җиһан тутырып яктылык нуры сирпелә, кояш тәүге нурлары аша җирне уятуга ашыга:

*Ут элделәр офык аръягына,*
*Үләннәрдә чыклар яктырды.*
*Еракларда ат пошкырып куйды...*

Лирик геройның күңелендә әлеге “уяну” мизгеле, шашкын хисләрдән бигрәк сагыну-юксыну хисләре алга сугара, шуңа бәйле шигырьнең хис катламын якты сагыш хисе каймалап ала. Лирик герой үткәндәге рәхәт һәм самими мизгелләрне балачакның матур хатирәсе итеп күз алдына бастыра, тоемлавы белән үткәненә әйди:

*Әверелче, күңел, тик бер мәлгә*
*Шул ат янындагы колынга!*
*Һәм баш чөеп, ярсып кешнәп*
*җибәр*
*Офыкларга карап*
*Бер генә! –*

Ат янында булган колын – балалык, самимилык, чисталык символы булып шигырь тукымасында иң зур көчкә ия була. Лирик герой инде дөньяны “ал күзлек”тән түгел, ә бәлки “аклы-каралы” күзлектән дә карап өлгергән, шактый җитлеккән шәхес буларак күзаллана. Шуңа да аның өчен балаларның самимилыгы, күңел көрлеге, дөньяны бары бер яктан гына күреп, ихлас яхшылыкны гына кабул итүләре – ниндидер кимчелек, җитешсезлек түгел, ә кешелекнең асылы булып күзаллана.

*Эресен җан тынлык күкрәгендә,*
*Югалыйк бер, күңел, без монда –*
*Бер гөнаһсыз нәни колын булып*
*Газиз әнкә – бия янында.*
*Тәвәккәллә, күңел, тик бер*
*мәлгә! –*
*Галәм нуры безгә кагылсын,*
*Колыннарның карашында бары*

*Саф йолдызлар гына чагылсын*

Шигырьнең иң югары ноктасына җиткерелгән әлеге юлларда лирик герой балалык мизгеленә кайту өчен бар булганыннан, бүгенгесе көндә ирешкән- уңышларыннан да баш тартырга риза булуы турында сөйли, үткәннәргә юлның булмавын сыкрану катыш үкенү тойгысын җиткерә. Шушы фонда колын балачак символы, балачакның якты, канатлы хыяллары символы буларак та ачыла.

*Тик бер генә тапкыр колын булып*
*Шушы таңда килә чабасым!*
*...Ә аннары... дөнья низагыннан*
*Агарасы чәчләр агарсын!*
*Үкенмәбез, күңел!*

Инде таң ату белән хыялый мизгелләр юкка чыга, бу халәт таң кызы көлүе аша җиткерелә:

*Ишетәсеңме: таңны дәшә дәшә*
*Тын болында көлә таң кызы...*

Шигырь тукымасында бирелгән колын кешелекнең яшәеш асылын да символлаштырып килә. Үзеңнең балачак хыялларын, күңелеңдә яшәп килгән “сабыйлыкны” саклап калу – һәркемнең төп бурычы, яшәешнең гүзәллегенә илтүче юл ул. Колын кебек милли-тарихи код-образ аша Автор укучыны көчле фәлсәфи фикергә, гомумиләштерүгә алып килә.

**Әдәбият**

1. Зөлфәт. Йөрәгемне былбыл чакты: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Рухият, 1999. – 415 б.
2. Зөлфәт сайты URL: https://zolfat-site.narod.ru/sh39.htm (мөрәҗәгать итү: 18.01.2024)
3. Йосыпова Н.М. XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: тардицияләр һәм яңачалык. – Казан: “Школа” редакция нәшрият үзәге, 2021 г. – 296 б.
4. Шигърият.ру URL: https://shigriyat.ru/authors/zolfat/page3 (мөрәҗәгать итү: 18.01.2024)

# ТАТАР ТЕЛЛЕ БАЛАЛАР ТАПШЫРУЛАРЫНДА СӘНГАТЬЛЕЛЕК ЧАРАСЫ БУЛАРАК ПОЭТИК-СИНТАКТИК ЧАРАЛАР

*Хәялиева Р., КФУ, II курс аспиранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нәбиуллина Г.Ә.*

Массакүләм мәгълүмат чаралары безнең тормышыбызга һәрвакыт зур йогынты ясап килде һәм ясыячак. Мәгълүматны җиткерү ысулы – яңалыкларны сөйләүдә мөһим компонент. Бүгенге көндә массакүләм мәгълүмат чараларының берничә функциясен аерып була: мәгълүмати, аңлатма һәм бәяләү, танып белү һәм тәрбия, тәэсир функциясе, гедонистик.

Гедонистик функцияне җентекләп карап чыгыйк һәм журналистларның сөйләмендә күбрәк тамашачыларның, укучыларның игътибарын җәлеп итү өчен нинди поэтик-синтаксик чаралар кулланганнарын карыйк.

Массакүләм мәгълүмат чараларының теле, аеруча телевидение теле, күп бәхәсләр тудырган һәм бүгенге көндә дә күпләр өчен кызыклы тема. Төрле публицистик жанрлар, аларның эчке стиле өчен бик катгый һәм билгеле таләпләр бар. Шуңа бәйле рәвештә, без журналистлар яңалыклар текстларын ясаганда сөйләм экспрессивлык чараларын кулланалармы, яисә мондый текстлар бары тик мәгълүмати саналамы һәм аларның сөйләмендә сүз образлары кулланыламы дигән проблема белән очраштык.

Бүгенге көн татар журналистикасында поэтик-синтаксик чаралар мул һәм иркен кулланыла. Сөйләмдә синтаксик параллелизмнар, анафора, эпифора, дәшми калу, риторик сорау, риторик өндәү, эмфаза, полисиндетон һ.б. еш очрый.

Матур әдәбиятта да, журналистикада да сөйләм йогынтысы төрле сөйләм чаралары ярдәмендә башкарыла. Психологик эффектка ирешү өчен, журналист традицион формалардан читләшергә, иске эчтәлекне белдерү өчен, яңа, экспрессив тел табарга тырыша.

Экспрессивлык хәзерге вакытта иң актив тикшерелгән лингвистик категорияләрнең берсе. Телевизион тапшыруларда журналистларның сөйләме тулы һәм ачык итеп җиткерелергә тиеш, чөнки аларның теле, билгеле булганча, күпчелек тамашачыларга тәэсир итәр өчен, аларны билгеле идеялар белән рухландырып, тәҗрибәле хис формасында эмоциональ реакция, шулай ук эш һәм гамәлләр рәвешендә реакцияләр барлыкка килүгә ярдәм итә. Бу процесста төп роль иҗади тел шәхесе буларак – алып баручылар җилкәсенә төшә.

Публицистик стиль әдәби тел стиле системасында аерым урын алып тора, чөнки күп очракта ул башка стильләр эчендә ясалган текстларны эшкәртергә тиеш. Фәнни һәм эшлекле сөйләм чынбарлыкның интеллектуаль чагылышына, сәнгать сөйләменә – аның эмоциональ чагылышына юнәлтелгән. Журналистлар сөйләме исә аерым роль уйный – ул интеллектуаль һәм эстетик ихтыяҗларны канәгатьләндерергә омтыла. Күренекле француз тел белгече Ч.Балли "фәнни тел – идеяләр теле, һәм сәнгатьчә сөйләү – хисләр теле" дип язган.

Моңа өстәп, без журналистларның сөйләме – уйлар да, хисләр дә теле дип әйтә алабыз. Массакүләм мәгълүмат чаралары яктырткан темаларның мөһимлеге җентекләп уйлануны һәм фикерне логик презентацияләүне таләп итә, һәм авторның вакыйгаларга мөнәсәбәтен белдерү телнең эмоциональ чараларын кулланмыйча мөмкин түгел.

Алып баручылар сөйләме стиленең үзенчәлеге – әдәби тел лексикасын киң яктырту: аларның сөйләмендә фәнни-техник терминнардан алып көндәлек сөйләм сүзләренә кадәр кулланыла. Кайвакыт журналист үз чыгышында сленг сүзләрен кулланып, әдәби телдән читләшә дә.

Журналистиканың мөһим функцияләренең берсе (аерым алганда, алып баручылар сөйләме) – мәгълүмати. Соңгы яңалыкларны тиз арада хәбәр итү теләге коммуникатив ситуациянең табигатендә дә, сөйләм гәүдәләнешендә дә чагыла алмады. Ләкин шуны истә тотарга кирәк: телевидениедагы сөйләм – лингвистик иҗат шартларының оригинальлеге белән аерылып тора: ул кыска вакыт эчендә барлыкка килә, кайвакыт лингвистик материалны эшкәртү идеалына китерә алмый. Шул ук вакытта, ул бер кеше тарафыннан түгел, ә еш кына үз материалларын бер-берсеннән аерып әзерләүче күп корреспондентлар тарафыннан тудырыла.

Һәр кеше дә сөйләмендә төрле экспрессия чараларын куллана. Кайсыбер очракта бу аңсыз рәвештә эшләнә, ә кайсыбер чакта кеше максатчан рәвештә сөйләменең экспрессиясен арттыру өчен теге яки бу поэтик-синтаксик чараны махсус сайлый һәм куллана. Әлбәттә, поэтик-синтаксик чараларны иркен куллану өчен кеше матур әдәбият әсәрләрен, газета-журналларны күпләп укырга, татар телендә күбрәк сөйләшергә, татарча спектакль, фильмнар, төрле тапшырулар карарга тиеш.

Сөйләм төп эш коралы булган журналистлар өчен исә поэтик-синтаксик чараларны куллану – бик әһәмиятле. Беренчедән, ул аларның белем дәрәҗәсен һәм зәвыгын күрсәтсә, икенчедән, телебезнең эталонын гәүдәләндерүче бу профессия вәкилләренең

бурычы да булып тора. Чөнки журналистларны халык көн саен тыңлый, укый, карый, димәк, аларның сөйләме кешеләргә бик зур йогынты ясый дигән сүз.

«Шаян ТВ» тапшырулары алып баручылары теленә килгәндә, анализ күрсәткәнчә, аларның сөйләме татар теленең синтаксик нормаларына туры килә. Алып баручыларның сөйләмендә анафора, эпифора, антитеза, градация, парцеляция, риторик сорау, риторик өндәү, синтаксик параллелизм, эллипсис, оксюморон, лексик кабатлау кебек синтаксик чаралар кулланыла. Шунысы игътибарга лаек, бу төр поэтик чаралар алып баручылар монологына да, диалогларга да хас.

Градация - бертөрле сүзләр яки әйтемнәр сериясеннән торган (образлар, чагыштырулар, метафоралар һ.б.) эзлекле рәвештә арту, көчәю (кульминация) яки, киресенчә, киму (антиклимакс) аркасында семантик һәм эмоциональ әһәмияткә ия булган сүзләр тезмәсе: *Без исә зур **максатлар, хыяллар** белән янып яшәүче моңлы тавыш иясенә бары тик уңышлар гына телибез! (“Шаян ТВ”, 19.04.2022); Кемнәргәдер әнә шундый **позитив сүзләр, аффирмацияләр**, чын-чынлап ярдәм итә. (“Шаян ТВ”, 20.04.2022); Балалар монда **сикереп, шаярып, уйнап, күңел ачалар** (“Шаян ТВ”, 17.03.2023); Олимпия уен төрләренә кергән спорт төрләре белән балалар **таныша, кызыксына башлый, уйный** (“Шаян ТВ”, 17.03.2023).*

Антитеза – (грекча 'bnfiyeuit – оппозиция) – бер-берсенә бәйле конкрет идеяларны һәм төшенчәләрне уртак структура яки эчке мәгънә белән чагыштырудан торган поэтик-стилистик ысулларның берсе. Чагыштырылган өлешләрнең капма-каршы үзенчәлекләрен кискен күрсәтү, антитезаның төгәллеге аркасында, бик нык инандыру көченә ия булуы белән аерылып тора (моның өчен романтиклар бу фигураны бик яраттылар). Шуңа күрә күп стилистлар антитезага тискәре мөнәсәбәт күрсәттеләр, икенче яктан, риторик пафосы булган шагыйрьләр аны бик яраталар. Антитезаның симметриясе һәм аналитик характеры аны кайбер формаларда бик ачык күрсәтүгә булышлык итә. Антитезаның кискен ачыклыгы аны тиз арада инандырырга омтылган әсәрләр стиле өчен бик уңайлы итә, мәсәлән, декларатив сәяси әсәрләрдә, социаль тенденциягә ия булган аггитацияләрдә һәм бигрәк тә, җанлы сөйләмдә һ.б.: *Табиблар **эш һәм ялга** вакытны дөрес итеп бүләргә куша (“Шаян ТВ”, 15.03.2022); Иртәнге гимнастика, икенче төрле әйткәндә – зарядка, баланың физик, уйлау һәм фикерләү сәләтен үстерә, ата-анадан соң **кәефсез** калган баланың **кәефен күтәрә**, **шук** булган баланы **дисциплинага** өйрәтә, **оялчан** балага **активрак** булырга ярдәм итә (“Шаян ТВ”,*

*17.03.2023); Дуслашу бик* ***җиңел****, аерылышу* ***авыр*** *бит.(“Шаян ТВ”, 29.08.2022).*

“Шаян ТВ” тпшыруын алып баручыларының сөйләмендә риторик сорау һәм өндәүләр кебек поэтик-синтаксик фигуралар да еш очрый. фигуралар дип Риторик сорау һәм өндәүләр экспрессивлыкны көчәйтүче үзенчәлекле сөйләм чаралары. Бу чараларның аермалы үзенчәлеге – аларның шартлылыгы, ягъни сорау бирү, өндәү һ.б. куллану.

Риторик сораулар: *Моннан да кадерлерәк әйбер бар микән дөньяда? (“Шаян ТВ”, 15.09.2022); Дөньяданиләр булып ята? Нигериядә юл хәрәкәтен бии-бии көйлиләр (“Шаян ТВ”, 17.03.2023).*

Риторик өндәүләр: *Таң калдырырлык матурлык! (“Шаян ТВ”, 22.12.2022); Сез “Яңа гасыр” каналында “Тамчы-шоу” тапшыруын карыйсыз! (“Шаян ТВ”, 19.11.2022); Яз сулышы сизелә бит дөньяда! (“Шаян ТВ”, 03.04.2022)*

Нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне билгеләп китик: “Шаян ТВ” тапшырулары бүгенге көндә татар теленең, сөйләм культурасының эталоны булып тора. Алып баручы балалар югары әдәби телне гади сөйләм теле белән аралаштырып, мәгълүматны гади телевизор караучылар өчен аңлаешлы һәм экспрессив төстә җиткерәләр. Үз сөйләмнәрендә алып баручылар төрле лексик сөйләм чараларыннан мул һәм оста кулланалар. Аларның сөйләмендә фразеологи берәмлекләр, синоним, антонимнар, эпитет, метафоралар, чагыштырулар, мәкаль-әйтемнәр бик еш очрый. Болар барысы да алып баручылар сөйләмен аһәңле һәм экспрессив итә.

**Әдәбият**

1. Гарифуллин В.З. Журналист эшчәнлегенең нигезләре. Уку ярдәмлеге. – Казан: КГУ нәшрияты, 2009. – 172 б.

2. Юсупов Р.А. Мәгълүмат чаралары теле һәм сөйләм культурасы. – Казан: ТДГПУ, 2007. – 218 б.

3. Кузнецов Г.В. ТВ-журналистика: критерии профессионализма. – М.: РИП-холдинг, 2003. – 219 с.

# АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ПЕЙЗАЖ БИРЕЛЕШЕ

*Хөсәенова Р., КФУ, II курс аспиранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гайнуллина Г.Р.*

Хәзерге әдәбиятта традицион татар хикәясен үстерүдә үз сукмагын тапкан, лирик-эмоциональ дулкынны дәвам иттерүче язучыларның берсе Айгөл Әхмәтгалиева иҗаты күпләребезгә таныш. А. Әхмәтгалиева әдәбият мәйданына XXI гасырның башында килеп кергән яшь әдибә. Аның әсәрләрендә күпмедер дәрәҗәдә XX гасырның икенче яртысында иҗат иткән авторлар тарафыннан күтәрелгән темалар да очрый. Табигатьне саклау, авылның бетүе, кеше холкының кырыслануы, эчүчелек, эшсезлек, ятимлек, тормышның үзгәрүе кебек мәсьәләләр авыл яшәешен прозада чагылдыручы язучылар иҗатында кат-кат күтәрелгән.

Айгөл Әхмәтгалиева хикәяләре беренче тапкыр укуда ук тормышчан, гади, аңлаешлы телдә язылуы белән аерылып торалар һәм үзләренә җәлеп итәләр. Бигрәк тә табигать сурәтләнеше, пейзаж лирикасы ярдәмендә автор геройларның хис-кичерешләрен дә, алга таба вакыйгалар агымының нинди булуын да оста итеп күрсәтә белә. Пейзаж – әсәрдә җанлы һәм җансыз табигатьне сурәтләү [3: 31]. Фәндә пейзажның төрле вазифалары аерылып чыгарыла:

- вакыйгаларның урынын, вакытын билгеләү;
- сюжетка катнашу яки аны үзгәртү;
- әсәрне кабул итәргә көйләү һәм геройларның психологик халәтен ачу;
- автор фикерен белдерү.

Пейзаж, хикәяләрдә иң актив һәм киң таралган деталь буларак, әсәрнең идеясен укучыга образлы һәм кыска юл белән ирештерергә мөмкинлек бирә. Хикәяләрдә пейзаж әсәрнең эчтәлеге, идеясе белән бәйләнгән булырга тиеш. “Күп очракта пейзаж – урынны күрсәтүче” дә [1: 51].

А.Әхмәтгалиеваның күп кенә әсәрләре табигать күренешен сурәтләү белән башланып китә. “Кайтаваз” хикәясенең башлам өлешендә бирелгән пейзаж ярдәмендә автор укучысын билгеле бер дулкынга көйләп куя. Сылу каеннар шавы белән инеш агышы кешенең гармониясен тәшкил итүче образлар кебек укыла. Символ булып килгән моң әлеге образларны бербөтенгә туплый, тормышның көйләнгән булуына ишарә итә: “...Колакны иркәләгән әлеге моң таң калырлык иде” [2: 160]. Шулай ук: “Урал тауның ташлы итәгендә мәгърур кыяфәтле сылу каеннар шавында идеме ул, әллә инде тау күкрәген ярып, кылтык кызлар тавышы белән челтерәгән инеш

агышында идеме...” [2: 160] дигән беренче юлларын укуга ук вакыйгаларның, алга таба булачак хәлләрнең әйбәт булачагына ышанасың, өметләнәсең. Шулай сурәтләп, автор укучыны искиткеч матур табигатьле сихри дөнья эченә алып кереп китә.

Ләкин алга таба елганың “дуамалланып, ярсып” агуы, суы “боздай салкын” [2: 161] булуы әлеге елганың куркыныч тудырырга мөмкин икәнлеген күрсәтә, сак булырга куша. Табигатьне төрлечә сурәтләп, автор вакыйгаларның үзгәрәчәгенә ишарә итә.

Пейзаж ярдәмендә автор ана кешенең бөеклеген дә ачык күрсәтә, “...болытларга түбәләре тигән мәгърур таулар...” [2: 164] кешенең халәтен сурәтләүдә катнаша, ана кешенең горурлыгын чагылдыра. “Гүя барысы да каяндыр ишетелер-ишетелмәс кенә булып агылган, колакны иркәләгән моңга, җил канатында тирбәлгән кайтавазга мөккибән иде” [2: 164] дигән юллар алда тынычлык, рәхәтлек көткәнен күрсәтә.

Пейзажның әсәрне каймалап алуы хикәянең тәэсир көчен арттыра һәм төп мәгънәсен җиткерә. “Колакны иркәләгән моң”ның кабатланып килүе укучыны да шул дулкынга көйләп куя һәм буыннардан килгән гомумбилгеле хакыйкатьнең – яхшылыкның, мәрхәмәтлелекнең һәрвакытта да кешенең үзенә кайтаваз булып әйләнеп кайтуын раслый.

“Тау итәгендә” дип исемләнгән хикәядә дә пейзаж алымнары зур урынны алып тора. Башлам өлештә бирелгән пейзаж укучыны геройның күңелендә борчу булуын, ниндидер сынау алдында калганлыгын тоюга әзерли. Тау итәге никадәр генә матур булмасын (“зәңгәр кыңгыраулар, бер-берсенә сарылган кәрешкә, күкчәчәк, тагын әллә нинди, әллә нинди чәчәкләр, үләннәр, төсләр белән чуарланган”), ир нәкъ менә сары күзле ромашкалар алдында туктап, уйланып калырга мәҗбүр була. Сары күзле ромашкалар биредә кешенең күңелен ачып бирүче, гармониясен тәшкил итүче символ буларак киләләр [2: 212].

Алга таба авторның әйтергә теләгән чираттагы фикере әсәргә килеп кергән болыт һәм кояш образлары аша җиткерелә: “...Менә бу иркә болытларның бер көчкә җыелып караңгылануы, кояшның шул болыт юрганы астына кереп югалуы, күк йөзенең мизгел эчендә яшь коя башлавы астагыларның тормышын төбе-тамыры белән үзгәртергә сәләтле икәнен аңласалармы...” [2: 215]. Шулай итеп ул кешеләрнең алны-артны күрми тормыш куулары, тормышның Аллаһ кулында икәнен онытып җибәрүләре турында искәртә.

Язучы әлеге хикәяләрендә геройларның хис-тойгыларын, эш-гамәлләрен табигать сурәтләнеше белән тыгыз бәйләнештә үреп бара

һәм төп фикерне дә шуның аркылы җиткерүгә ирешә. Табигать белән геройлар арасында бәйләнеш урнаштырыла. Бу А. Әхмәтгалиева хикәяләрендә үзенчәлекле күренеш булып тора.

Айгөл Әхмәтгалиева пейзажны ничек кенә, нинди вазифалар йөкләп тасвирламасын, аны һәрвакыт теге яки бу күренешкә үз мөнәсәбәтен белдерүнең үтемле чарасы буларак та аның иҗатына шәхеснең “күзгә күренми торган, җисемсез, предметсыз хәят – күңел дөньясы” белән тирән кызыксыну хас. Кеше күңеле хәрәкәтен дөрес сурәтләп бирү аның осталык арсеналының төп хасиятләреннән берсе.

**Әдәбият**


1. Алексеев В.А. Очерк. Спецкурс для студентов заочного отделения. – Изд. Ленингр. ун-та, 1973 – С. 84
2. Әхмәтгалиева А.Г. Таллыкүлдә былбыл бар. – Казан: Татар. кит. нәшир., 2016. – 287 б.
3. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004 – 247 б.

# ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ АЛТЫН ЛЕКСЕМАСЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

*Хуҗина З., II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гайнуллина Г.Р.*

Бүгенге лингвистиканың иң мөһим бурычларыннан берсе булып, туган (татар) тел һәм чит телнең үзара бәйләнешен өйрәнү һәм чагыштыру тора.

Чит телне өйрәнү процессында аның лексикасы һәм сүз байлыгына аерым игътибар бирелергә тиеш. Әлеге проблеманы нәтиҗәле хәл итү өчен ике телнең мәкаль-әйтемнәрен өйрәнергә мөмкин, чөнки аларда халыкның үзаңы, менталитеты, милли характеры, традицияләре, тормыш нигезләре һәм гомумән милләтнең әхлакый кыйммәтләре чагыла.

Анализ өчен татар һәм төрек мәкальләре сайлап алынды. Әлеге эштә мәкальләрдәге алтын төшенчәсенең бирелеше өйрәнелә.

Этимологик сүзлеккә мөрәҗәгать итеп, без сүзнең килеп чыгышын билгеләдек: “бер версия буенча, алтын, алтан, алтаң үзе “алсу” мәгънәсендә генә булган” [1: 94].

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә алтын лексемасының күптөрле мәгънәләре бирелә. Кайберләрен атап үтик: “1) Сары яки кызгылт сары төстә, авыр, йомшак, чүкүгә бирелүчән затлы металл, химик элемент (сәнәгатьтә, медицинада, ювелир әйберләр ясау эшендә һ.б.да киң кулланыла). 2) Шундый металлдан коелган акча. 3) Гомумән акча мәгънәсендә. 4) Гомумән байлык. 5) Шуңа манылган ефәк җеп. 6) Алтынлы яки алтын төсендәге буяу” [3: 152]. Еш кына алтын лексемасы күчерелмә мәгънәләрдә йөри. Мәсәлән: 1) Яхшы, күркәм сыйфатларга ия булган; игелекле, изге күңелле яисә коллектив өчен бик кадерле булуы белән башкалардан аерылып торган кеше. 2) Кадерле, бик кирәкле, әһәмиятле әйбергә карата кулланыла. 3) Кадерләп, иркәләп һәм яратып әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. 4) Алтын төсле, ялтырап торган ачык сары төстәге; алтынсыман. 5) Бик яхшы яклары, уңай сыйфатлары белән аерылып торган; уңган, булдыклы [3: 152].

Күчерелмә мәгънә бигрәк тә мәкаль-әйтемнәрдә кешеләргә сыйфатлама бирү өчен кулланыла. Мәсәлән:

*алтын бәһасе тору* – алтынга тиң, бик кыйммәтле, кадерле, әһәмиятле;

*алтын бәясенә йөрү* – алтын кебек югары бәяләнү, үз бәясеннән кыйммәтрәк тору, кыйммәткә төшү;

*алтын бәясенә төшү* – бик нык кыйммәткә төшү, күп акча сарыф ителү;

*алтын белән күмү* – мәкалендә яшәеш, тормыш итү өчен тудырылган барлык уңайлыклар, шартлар тудыру;

*алтынга (да) табып булмый* – 1) акча түләп тә эзләп табылмый торган, кыйммәтле, бик кирәкле (кеше, зат, һөнәр иясе турында);

*алтынга яллану* – нинди дә булса эшне күп акча алу шарты белән башкарырга алыну;

*алтын таулар вәгъдә итү* – тормышка ашмастай вәгъдәләр бирү;

*алтын төп(ле) (булу)* – керемнең бетмәс-төкәнмәс, иксез-чиксез күп табыш бирә торган чыганагы булу турында;

*алтын хәрефләр белән язу (басу)* – кемнең дә булса исемен тарихка кертү, мәңгеләштерү.

*алтын эчендә йөзү* – бик бай, мул тормышта яшәү һ.б.

Мәкальләрдә алтын акыл сүзенә антоним буларак бирелә: *акыл алтынны таба, алтын акылны табалмый; акыл булмаса, алтын ни эшкә; алтының белән мактанма, акылың белән мактан; акыл – алтын таҗ, һәркемнең дә башында булмый; акылсыз башта алтын бүрек тә файда бирмәс* һ.б.

Төрек телендә алтын *altın* дип языла. Төрек мәкальләренә игътибар итик:

*Altın çüpe düşse değerinden düşmez* мәкалендә алтын буялса да, үз бәясен югалтмый дигәнне аңлата.

*Altın küçük ama değiri fazla* мәкалендә алтын кечкенә булса да, бәясе югары дигәнне белдерә.

*Altının kıymeti azlığındadır* мәкалендә алтын үзенең аз булуы белән кыйммәт булуын белдерә.

*Bin altinin olmaktansa bir dostun olsun* мәкале антонимга корылып, күп алтының булганчы, бер дусның булуы яхшыракны белдерә.

Ике телдә дә булган, охшаш мәкальләр дә бар. Мәсәлән:

*Söz gümüş sükut altin – Сөйләвең көмеш булса да, дәшмәвең алтын.*

*Parlayan herşey altın değildir – Һәр ялтыраган алтын түгел.*

Шулай итеп, алтын лексемасы татар һәм төрек телендәге мәкаль-әйтемнәрдә кадерле, бик кыйммәтле булуны аңлата.

Татар һәм төрекләрнең мәдәниятендә күп гасырлык традицияләр, гореф-гадәтләр, гадәтләр, халыкның ышанулары, тел мәдәниятенең бай тәҗрибәсе чагылыш таба. Безнең карашка, татар һәм төрек халыкларының этномәдәниятен системалы өйрәнү лингвистика,

лингвокультурология, этика һәм культурология белән кызыксынучыларга отышлы булыр иде.

**Әдәбият**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А-Л). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543 б.

2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. 4 нче басма. – Яр Чаллы: “Идел-йорт”, 2003. – 100 б.

3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А–В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 712 б.

4. Зobanoplu Ц. Тьгк Dьnyasэ Ortak Atasleri Sцzlьрь [Dictionary of common Proverbs of the Turkish World] / Ц. Зobanoplu. – Ankara: AYK Ataterk Кькы Merkezi Baюkanlэрэ. 2004. – 511 p.

# ГРАММАТИЧЕСКАЯ ХАРАКТЕРИСТИКА ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИХ ЕДИНИЦ, НАЗЫВАЮЩИХ МУЖЧИНУ, В РУССКОМ ЯЗЫКЕ

*Чжан Сяомань, КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Чупрякова О.А.*

Фразеологизмы являются достоянием каждого языка, в процессе человеческого развития они передаются от поколения к поколению, сохраняют и воспроизводят менталитет народов каждой страны, во фразеологизмах хранится богатая культурно-национальная информация, отражается история, культурные традиции, повседневные обычаи и т.д. Именно поэтому фразеологизмы всегда привлекали большое внимание исследователей, которые, с одной стороны, описывают фразеологические материалы отдельно взятого языка, подчёркивая их специфический характер, а с другой стороны, анализируют фразеологизмы разных языков в сопоставлении.

Целью данной статьи является грамматический анализ фразеологических единиц, называющих мужчину, в русском языке. В статье предпринята попытка выявить основные структурные модели фразеологических единиц со значением лица мужского пола в русском языке.

Фразеологические единицы со значением лица мужского пола представляют собой субстантивные обороты, так как соотносятся с существительными. ФЕ дали возможность выявить основные структурные модели, установить их регулярность и продуктивность.

Ведущей является структурная модель фразеологизмов – «прилагательное+существительное», их нами выявлено 39: *соломенный вдовец, маменькин сынок, вольный казак, морской волк, бедовая голова, мышиный жеребчик, важная птица, большая рука, серая скотинка, травленый волк, канцелярская крыса, заячья душа и* т.д.

Сюда же относятся ФЕ с обратным порядком слов, их мы нашли в количестве 14 штук и один фразеологизм, представляющий собой сочетание существительного с местоимением: *шкура барабанная, раб божий, шут гороховый, бестия продувная, дубина стоеросовая, балалайка бесструнная, верста коломенская, голова еловая, голова садовая, голь перекатная, гусь лапчатый, каланча пожарная, пень березовый, Фома неверующий, наш брат.*

Данные фразеологические единицы соотносятся с существительными, большинство их них склоняется.

Все другие структурные модели в группе являются непродуктивными:

- модель «существительное в И.п. + существительное в Р.п.»: *покоритель сердец, властитель дум, искатель приключений, козел отпущения, последняя спица в колесе, волк в овечьей шкуре, отставной козы барабанщик, рыцарь печального образа, господин своего слова, птица высокого полета.*

- модель «существительное в И.п. + предложно-падежная форма существительного в В.п.»: *рыцарь на час, калиф на час.*

- модель «существительное в И.п. + Р.п. существительного с предлогом»: *саврас без узды, рыцарь без страха и упрека.*

- фразеологическая единица мешок с соломой построена по модели «существительное в И.п. + предлог + сущ. в Тв.п.».

С точки зрения гендерной характеристики проанализированные ФЕ можно разделить на следующие группы:

1) компонент мужского рода называет мужчину: *в костюме Адама, вольный казак, властитель дум, господин своего слова, заплечный мастер, искатель приключений, маг и волшебник, маменькин сынок, морской волк, мышиный жеребчик, набитый дурак, олух царя небесного, рыцарь без страха и упрека, рыцарь на час, рыцарь печального образа, сам себе хозяин, волк в овечьей шкуре, ни сват ни брат, тертый калач, пень березовый, двуликий Янус* и т.д.

2) компонент женского рода называет мужчину: *канцелярская крыса.*

3) родовая форма компонента далеко не всегда соответствует лексическому значению фразеологизма, компонент – существительное женского рода относится как к лицам мужского пола, так и женского пола: *верста коломенская, белая ворона, светлая голова, каланча пожарная, мокрая курица, дубина стоеросовая, ветреная голова, важная птица, птица высокого полета, бедовая голова, мелкая сошка* и т.д.

Субстантивные фразеологические единицы, называющие мужчину, с точки зрения категории числа представлены двумя группами:

1) фразеологизмы, имеющие значение собирательности: сильный пол, белая кость, пушечное мясо, голь перекатная;

2) фразеологизмы, которые могут употребляться как в единственном, так и во множественном числе.

С точки зрения падежной категории можно выделить следующие группы:

1) ФЕ, употребляющиеся во всей падежной парадигме: *вольный казак, властитель дум, искатель приключений, олух царя небесного,*

*шут гороховый, козел отпущения, двуликий Янус, бедовая голова, пень березовый, вольная птица, заячья душа* и т.д.

2) ФЕ, имеющие только форму Им.п. ед.ч.: *господин своего слова, ни сват ни брат, свой брат.*

Гендерный подход, представляющий собой дальнейшее развитие антропоориентированного изучения языка, позволил рассмотреть данное фразеосемантическое пространство с точки зрения гендерной референции.

**Литература**

1. Жуков А.В. Лексико-фразеологический словарь русского языка. Около 1500 фразеологических единиц. – М.: АСТ. Астрель, 2007. – 604 с.

2. Телия В.Н. Большой фразеологический словарь русского языка. Значение. Употребление. Культурологический комментарий. Ответственный редактор – доктор филологических наук В.Н. Телия (авторы-составители: И.С. Брилѐва, Д.Б. Гудков, И.В. Захаренко, И.В. Зыкова, С.В. Кабакова, М.Л. Ковшова, В.В. Красных, В.Н. Телия). 4-е изд. – М.: АСТ-ПРЕСС КНИГА, 2010. – 784с.

3. Шанский Н.М., Быстрова Е.А., Окунева А.П. Учебный фразеологический словарь русского языка: Пособие для учащихся нац. Школ. – Л.: Просвещение, 1984. – 271с.

# ЛЕКСИКО-СЕМАНТИЧЕСКОЕ ПОЛЕ ОДЕЖДЫ В РУССКОМ ЯЗЫКЕ: ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ АСПЕКТ

*Чжан Цзюнь, КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Чупрякова О.А.*

Одежда является частью культуры, а традиционная одежда – одним из основных элементов формирования нации. Формы и детали одежды, отношение к ней определяют возраст человека, его социальный и материальный статус и даже климатические условия, в которых он живет.

Целью статьи является попытка выявления особенностей семантики и функционирования единиц лексико-семантического поля «одежда» по данным словарей.

Под лексико-семантическим полем «Одежда» нами понимается совокупность лексических единиц разных частей речи, содержащих в значении компонент (гиперсему) «одежда», общее значение: *«совокупность предметов, которыми покрывают, облекают тело»*.

Семантическое структура поля «Одежда» включает следующие части:

- ядро поля представлено родовой семой (гиперсемой) – лексемой «Одежда»;
- центр поля состоит из единиц, имеющих интегральное, общее с ядром и рядоположенными единицами дифференциологическое значение – «одежда для верхней части тела», «одежда для нижней части тела», эти микрополя пересекаются с микрополями «мужская одежда», «женская одежда», «детская одежда»;
- периферия поля включает единицы, наиболее удалённые в своём значении от ядра, общее родовое понятие здесь оттеснено в разряд потенциальной или вероятностной семантики – лексемы, входящие в состав микрополей «одежда для верхней части тела», «одежда для нижней части тела». Изучение ЛСП «одежда» в составе какого-либо языка дает возможность получить представление о быте представителей этого языка в определенную эпоху, о социальной структуре, материальном положении, уровне образованности общества, говорящего на исследуемом языке.

Проанализировав определения слов в толковых словарях русского языка, включенных в названную интегральную сему, мы можем выделить центр поля. По нашему мнению, центром лексико-семантического поля «Одежда» являются лексемы *одежда, костюм,*

*туалет, платье* (в широком смысле синонимичном лексеме «одежда»).

На ближнюю периферию выносятся группы «по условиям эксплуатации» (*верхняя одежда, нижнее белье, чулочно-носочные изделия, домашняя одежда*), «по целевому назначению» (*повседневная одежда, одежда для спорта и отдыха*).

Дальнюю периферию составляют группы «по характеру опоры» (*плечевые, поясные*), «по сезону» (*летний, зимний, демисезонный, всесезонный*).

Самой многочисленной группой в данном ЛСП является группа «женская одежда» (67 ЛЕ). На наш взгляд, это свидетельствует о том, что одежда русских женщин разнообразна и приспособлена для различных целей.

При этом необходимо отметить, что и в микрополе «женская одежда» и в микрополе «мужская одежда» группа «повседневная одежда» содержит больше ЛЕ, чем группа «спортивной одежды». Из этого мы делаем вывод, что в русской культуре люди предпочитают одеваться строго и элегантно.

Принадлежность одежды к мужскому или женскому полу, ее предназначение и так далее, позволяют нам выделить общие семы: «родовая принадлежность», «домашняя одежда», «воротник», «широкая свободная одежда», «плащ», «пальто», «кафтан», «шуба», «нательное белье», «для верховой езды», «балетная одежда», «форменная одежда» «военная одежда», «специальная одежда», «юбка», «платье», «кофта», «женская одежда», «без рукавов», «без ворота», «со сборками», «мужская одежда», «верхняя одежда», «праздничная одежда», «старинная русская одежда», «у народов», «в странах».

Это, в свою очередь дает нам основание для классификации наименований предметов одежды и отнесения их к тем или иным тематическим подгруппам, таким, как: *общая носильная одежда; название предметов верхней одежды; названия предметов нижнего (нательного) белья; названия предметов специальной одежды; наименования предметов женской одежды; наименования предметов мужской одежды; наименования праздничной одежды; общие названия одежды; народная (национальная) одежда; названия одежды, входящие в несколько подгрупп; наименования предметов обуви; наименования головных уборов.*

Приведем некоторые примеры:

1. Обычная носильная одежда. В этой группе находится всего сорок названий таких, как: *балахон* – длинная одежда свободного покроя; *батник* – приталенная рубашка или кофта с отложным

воротником и застёжкой на планке;

2. Названия предметов верхней одежды. Эту тематическую подгруппу представляют сорок пять наименований одежды такие, как: *азям* – верхняя одежда крестьян в виде долгополого кафтана; *архалук* – верхняя распашная одежда в виде кафтана, поддевки; *альмавива* – широкий мужской плащ особого покроя; *болонья* – плащ из болоньевой ткани; *бурнус* – просторное пальто с широкими рукавами; *доха* – шуба на меху и с мехом из верха;

3. Название предметов нижнего (нательного) белья. В этой подгруппе находятся тринадцать наименований. В нее входят такие названия, как: *белье* – предметы одежды для ношения на теле; *бикини* – женский купальный костюм, состоящий из открытого бюстгальтера и очень узких плавок; *исподники* – кальсоны; *исподница* – нижняя юбка; нижняя женская рубашка;

4. Название предметов специальной одежды. Эту подгруппу составляют двадцать шесть наименований. Все названия в этой тематической подгруппе относятся к той или иной деятельности людей, например: *бушлат* – форменная суконная черная куртка моряков; *доломан* – гусарский мундир особого покроя, расшитый шнурами; *китель* – форменная однобортная куртка со стоячим воротником; *колет* – короткий военный мундир из белого сукна; *ливрея* – форменная, обычно расшитая галунами, одежда для швейцаров и лакеев.

Проблема семантической организации лексической системы языка является сегодня одной из сложнейших в языкознании. Говоря о структуре ЛСП, мы можем сделать вывод о национальных предпочтениях в одежде представленной нации. В русской лингвокультуре самыми многочисленными, на наш взгляд, являются поля «женская одежда» и «мужская одежда».

**Литература**

1. Большой толковый словарь русского языка / Гл.ред. С.А. Кузнецов. – С.- П.: ЛР, 2014. – 1536 с.

2. Воробьёв В.В. Лингвокультурология (теория и методы). – М.: РУДН, 2016. – 335 с.

3. Ефимова Л.В., Алешина Т.С., Самонин С.Ю. Костюм в России XV – нач. XX века – М: Арт-Родник, 2014. – 235с.

4. Земская А.А. Национально-культурная специфика картины мира и различные подходы к её исследованию // Языковое сознание и образ мира. – М., 2014. – С. 39-53.

ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ИНТЕРАКТИВНЫХ МЕТОДОВ ОБУЧЕНИЯ НА УРОКАХ АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА В УСЛОВИЯХ РЕАЛИЗАЦИИ ФГОС

*Шагиахметова А., КФУ, студент IV курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ашрапова А. Х.*

Интерактивность (от англ. interaction – «взаимодействие») – понятие, которое раскрывает характер и степень взаимодействия между объектами или субъектами. Элементами интерактивности являются все элементы взаимодействующей системы, при помощи которых происходит взаимодействиес другой системой человеком.

В педагогике и психологии «интерактивность» представляет собой морально-этическое свойство личности, проявляющееся в желании общаться, сотрудничать, находить свое место в коллективной деятельности и стремлении установить положительные отношения с членами группы.

Интерактивное обучение – это модель, которая направлена на создание таких условий, при которых все обучающиеся активно взаимодействуют друг с другом [3].

Технология интерактивного обучения на уроках иностранного языка направлена на активное взаимодействие всех учеников для достижения коммуникативных целей и развития иноязычной коммуникативной компетенции. Она также способствует расширению знаний о языке, обогащению лингвистического кругозора и лексического запаса, а также дальнейшему развитию общей речевой культуры. Педагог создает условия, в которых учащийся сам открывает, приобретает и конструирует знания [2].

Л. И. Филина считает, что «интерактивные технологии:

1) пробуждают у обучающихся интерес к учебному процессу;
2) поощряют активное участие каждого в учебном процессе;
3) воздействуют на чувства каждого обучающегося;
4) облегчают усвоение учебного материала; оказывают эмоциональное воздействие на обучающихся;
5) осуществляют рефлексию;
6) способствуют формированию у обучающихся собственного мнения иотношения;
7) развивают жизненные навыки;
8) способствуют изменению поведения» [1].

Интерактивное обучение направлено на то, чтобы все участники занятия были вовлечены в процесс обучения и активно взаимодействовали друг с другом. Преподаватель выполняет функцию помощника. Задачи интерактивных методовобучения:

— научить самостоятельному поиску, анализу информации и выработке правильного решения ситуации,

— научить работе в команде: уважать чужое мнение, проявлятьтолерантность к другой точке зрения,

— научить формировать собственноемнение, опирающееся на определенные факты.

Во время учебного процесса в учебных заведениях, преподаватели иностранных языков должны найти методы, чтобы мотивировать учеников к активному участию и пробудить в них интерес к изучению языков. Использование интерактивных технологий на занятиях способствует развитию творческого мышления и воображения учеников, усиливает их увлечение изучением иностранных языков и улучшает навыки общения [4].

При использовании интерактивных форм роль преподавателя меняется, перестает быть центральной. Он лишь регулирует процесс и занимается его общей организацией, готовит заранее необходимые задания и формулирует вопросы или темы для обсуждения в группах, дает консультации, контролирует время и порядок выполнения намеченного плана. Использование интерактивных технологий на уроках английского языка является эффективным и мотивирующим для студентов всех возрастов и уровней языковых навыков. Некоторым ученикам изначально сложно активно участвовать в дискуссиях или диалогах из-за неопытности в интерактивных методах, но они постепенно осваивают их и начинают активно участвовать в занятиях. При выполнении заданий они не сосредоточены на грамматических ошибках, а учитель не исправляет их во время разговора. Тематические исследования или проекты требуют от учеников творческого мышления, богатого воображения и логического мышления. Эти методы эффективны для достижения цели обучения – развития учеников в коммуникативной компетентности. Иными словами, современные интерактивные методы обучения позволяют перестроить учебный процесс с передачи знаний на развитие коммуникативной компетентности студентов, используя системно- деятельностный подход к обучению, ориентированный на учащегося.

Таким образом, подготовка занятия на основе интерактивных форм обучения предполагает выбор наиболее эффективных методов для изучения конкретной темы и возможность сочетать их для лучшего усвоения материала студентами.

**Литература**

1. Двуличанская Н. Н. Интерактивные методы обучения как

средство формированияключевых компетенций. – Наука и образование, 2011. – 10 с.

2. Загвязинский В.И. Теория обучения: современная интерпретация: учебное пособие для вузов. 3-еизд-е, испр. М.: Академия, 2006. – 192 с.

3. Кречетников К.Г. Проектирование креативной образовательной среды на основеинформационных технологий в вузе. – М.: Госкоорцентр, 2002. – 296 с.

4. Спирина Е.М., Чернякова Ю.С. Эффективные способы стимулирования познавательногоинтереса на уроках английского языка // Научно-методический электронный журнал Концепт. – 2019. – №5. – С.11-23.

# БАШКОРТСТАНДА ЗАМАНА ТАТАР ПРОЗАСЫ ҮСЕШ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ (Д.БУЛАТОВА МИСАЛЫНДА)

*Шакирова Ә., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Сайфуллина Ф.С.*

Географик яктан татар милләтебез шактый киң таралган. Татарстаннан читтә иҗат ителгән әдәбиятта да татар мотивлары яшәп килә. Башкортстан якларында торып, татар телендә иҗат итүче, гомумтатар әдәбияты үсешенә йогынты ясаучы милләтәшләребез, шагыйрь һәм язучыларыбыз, хәзерге заманда да мәдәниятебезгә битараф булмыйча хезмәт итә. Дөнья әдәбиятын төрле төсле, хуш исле, гүзәл чәчәкләргә күмелеп утырган ямьле болынга тиңләргә мөмкин. Татар әдәбияты шушы болындагы матур бер чәчәккә тиң булса, Башкортстандагы татар әдәбияты – шуның бер таҗы [3: 612].

Башкортстандагы татар әдәбияты 2000 елларга канатларын ныгыткан, буыннар алмашын тәэмин иткән, киләчәккә карап юл алган хәлдә килеп керә. Аның гомумтатар әдәбиятындагы урыны, үсеш тенденцияләре яңа гасыр башында кызу бәхәсләр тудыра, фән һәм әдәбият вәкилләре катнашлыгында матбугатта җанлы дискуссияләр башлануга сәбәпче була. Бу «төбәкнең географик, тарихи үзгәлеге чагылу» , «туган җир һәм туган тел тойгысына зур игътибар» бирелүне Башкортстандагы татар әдәбиятына хас үзенчәлекләр буларак аерып чыгару белән бәйле.

Башкортстандагы хәзерге татар әдәбияты – халык рухын тоеп эш иткән, аның яшәеш фәлсәфәсен, рухи ихтыяҗын чагылдырган, сәяси басымнар, мәдәни, рухи торгынлыклар, иҗтимагый үзгәрешләр аша үткән, әмма милли башлангычын югалтмаган, үткән мираска таянып, чынбарлыкны чагылдыруның яңа юлларын эзләгән, гомумтатар әдәбиятының җитди казанышы булырдай лаеклы иҗатчылар туплаган әдәбият [3: 614].

Билгеле, XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятында берничә тенденция калкып чыга: лирик-эмоциональ башлангыч алга чыга; психологизм көчәя; тәнкыйди башлангыч көчәя; публицистик башлангыч нигезләнеп тамырлана, киңәя. Алар XX-XXI гасырлар чиге татар прозасында яңа дулкынны уята [1: 14]. Бу шулай ук төбәк әдәбиятында да чагылыш таба.

Беренчедән, XX-XXI гасырлар чигендә Башкортстандагы татар прозасында чагыштырмача күтәренке рухның, хисси-лирик, романтик башлангычның өстенлек алуы чагыла; шулай ук идея-эстетик карашларның иҗтимагый яссылыктан шәхси тирәлеккә хәрәкәт итүе билгеләнә. Замана прозасы актив гражданин-шәхес образына алмашка

сызланучы-сыкранучы ялгызак геройлар килә башлавы белән билгеләнә. Шулай ук, тормышның киң панорамасын сурәтләгән иҗтимагый-тарихи әсәрләр иҗат ителә; реалистик сурәт белән беррәттән, постмодернистик алымнар чалымлана башлый. Бу үзгәрешләр, яна чорга чыккач, тагын да ныграк үсеш ала. Заманча фикер йөртүче, идеологик карашлардан чагыштырмача азат, туган телдә чикләүләрсез иҗат итү мөмкинлеге алган урта һәм яшь буын сүз сәнгатенә яңа үзенчәлекләр дә алып килә: Башкортстан җирлегендәге татар прозасы тематика, жанрлар ягыннан байый, туган телдә зур күләмле әсәрләрне бастыра алу мөмкинлеге роман, аеруча повесть жанрының үсеш алуына этәргеч бирә.

Башкортстанда яшәп татар телендә иҗат итүче язучы, публицист Дилбәр Булатова (Дилбәр Данис кызы Булатова-Сөләйманова) әсәрләре мисалында карыйк. Авторның башлангыч чорда язылган хикәяләрендә табигать гүзәллегенә мәдхия, милли гореф-гадәтләр (туй, су юлы күрсәтү, Сабантуй) бәян ителү, кеше һәм табигать арасындагы гармония, дөньяны идеалистик күзаллау һәм чынбарлык бәрелеше күзәтелә. Шулай ук хикәяләрдә геройларның тышкы тирәлек белән тартышы түгел, эчке рухи конфликтлар күбрәк урын били, психологизм алымнары һәм реалистик сурәт белән беррәттән, экзистенциализм чалымнары сиземләнә. Бу үзенчәлекләр аның әсәрләрендә геройларның хис-кичерешләрен, уй-фикерләрен җиткерү юлларында ачык чагыла.

«Соң түгел» җыентыгындагы «Көтәрмен, дигән идең...» (2017) повестенда Камил белән Камилә тарихын – Шәрык әдәбиятына хас мәхәббәт легендалары, романтизм ысулын заманча шартларга үлчәп карау тәҗрибәсе дип бәяләргә мөмкин. Ике гашыйк йөрәкнең тормыш авырлыкларына, мәхәббәт юлында очраган киртәләренә, ата-ана ризасызлыгына карамастан, бер-берсенә тугры булып калулары, шушы киртәләрне үтеп мәхәббәтләрен саклап калу тарихы романтик хис-кичерешләр белән тулыландырылган. Хәтта әсәр барышында да төп геройлар үзләрен Йосыф һәм Зөләйха белән чагыштыралар.

Төп герой Камил 11 нче сыйныф укучысыннан бишенче курс студенты булып, чын ир-егет, шәхес буларак үсә. Бу үсеш барышында ул эчке рухи конфликтлары белән көрәшә, тормышындагы һәр вакыйганы үзе аша үткәрә, анализлый, дөрес юл табарга тырыша: *«Әлеге сүзләр Камилнең хәтеренә уелып калды. Чынлап та, бер генә яшибезме? Бу дөнья, син үзең, башкалар, ярына дулкыннарын каккан шушы Аслыкүл – алар башкача кабатланмаячак, үлү белән синең өчен болар барысы да юкка чыгачакмы?».*

Авторның әсәрне мифологик яктан баетуы да игътибарга лаек. Башкортстанда урнашкан Асылыкүл, Агыйдел пейзажлары, Заятүләк

белән Сусылу легендасына киная әсәргә җирле колорит өсти. Повестьның башыннан ахырына кадәр каен символын урынлы куллану да үзенчәлекле. Автор тарихның барышында өй алдында утырган каенның үзгәрүчән халәтен сурәтли: *«Каенны кайгы агачы, диләр... Әллә шуңа сагалый микән аларны каеннар?».*

Алда әйтелгәннәрне төгәлләп, шуны әйтергә мөмкин: бу төбәктә иҗат ителгән әсәрләргә хас булганча, теле матур, ачык, бай булуы; татар әдәбияты традицияләрендә укучыга әхлакый фикер, мөһим идея җиткерелүе белән беррәттән бүгенге заман турында бәян итеп әйтелүе, идея-эстетик карашлар ягыннан шәхес терминының калкып чыгуы әсәрдә замана прозасы үзенчәлекләре буларак чагылыш таба.

**Әдәбият**

1. Закирова Г.Р., Гыйззәтуллина Л.Ә. Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – 452 б.

2. Булатова Д. Соң түгел...: повестьлар, хикәяләр. – Уфа: Китап, 2019. – 221 с.

3. Рахмани Р.Ф. Татар әдәбияты тарихы сигез томда = История татарской литературы в восьми томах / Татарстан Республикасы Фәннәр акад., Галимҗан Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014-2021. Т. 8: 2001-2020 еллар = Т. 8 : 2001-2020 годы. – 2021 (Казань). – 739 с.

# «АК ЮЛ» (1913 – 1916 ЕЛЛАР) БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫНЫҢ ТЕЛЕ

*Шәвәлиева З., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Юсупова Ә.Ш.*

“Ак юл” – татар телендә балалар өчен рәсемле журнал. Казанда “Сабах” типографиясендә 1913 нче елдан алып 1916 нчы елга хәтле бастырыла. Нәшере һәм мөхәррире балалар язучысы, танылган журналист, тәрҗемәче Фәхрелислам Агиев (1887-1938) була.

Журнал айга ике тапкыр бастырыла. Барлыгы 74 саны дөнья күргән. Ул “Татар милләтенең киләчәге тәрбияле балалар кулында” девизы астында эшли.

Эчтәлеге буенча журнал энциклопедик характерда була. Анда фәнни- популяр, сәнгатьи, публицистик һәм мавыктыргыч материаллар бастырыла. Шулай ук геграфия, тарих, биология кебек фәннәрдән кызыклы мәкаләләр языла. Ләкин күбрәк балалар өчен хикәяләргә, шигырьләргә урын бирелә.

